Каләм изгегә тартыр

Мәдәни Җомга

MӘDӘNİ COMĞA

4 февраль
2000 ел

№5
(238)

1995 елның
июленнән
башлап
чыга

Атналык гәзит

بسم الله الرحمن الرحيم

Бүгенге санда:

2 Мәрди РАФИКОВ. Газиз илне күкрәге белән саклаган данлы ветераннар безнең тормыштан рәнҗеп китмәсеннәр иде.

8 Мөхәммәт МИНАЧЕВ. Без бөтен проблемаларны да үзебез чишәрлек халык, тик бер-беребезгә ышанып эш итәргә, бер-беребезне алдамаска, сатмаска, киресенчә, якларга кирәк.

14 Фәнис ЯРУЛЛИН. Җырлардагы, шигырьдәге һәр образ күп уйланулар, әзләнүләр нәтиҗәсендә туа, шуңа шигырьнең бер генә юлын үзләштерсәләр дә җан әрни.

15 Суфия ГАЛИЕВА. Соңгы вакытта милли үзаңыбызны күтәрү, ата-бабаларыбыз гасырлар буе саклап килгән гореф-гадәтләребезне саклауның ни дәрәҗәдә мөһим икәнен аңладык инде.

Кеше китә, җыры кала, диеп
Җырладык без яшәү хакында...

Әйткән сүз – аткан ук

Бислан ГАНТАМИРОВ, РФ Президентының Чечнядагы вәкиле урынбасары, чечен милиционерлары ополчениесе командиры:

"Чечен боевикларының үз милләттәшләрем булуы белән мин еш кына горурланып та куям. Алар фидакарьләрчә сугышалар..."

("КП").

Сынамышлар

● Февральдә каен ботагында карлар алка-алка булып асылынып торса, ул елда иген уңар. ● Яңа айның бер башы югарырак күренсә, бу ел һәркемгә яхшы булыр. ● Февраль аенда күк күкрәсә, бу ел һәр җимеш уңар, яз яхшы килер, һәрбер ашлык булыр. ● Февраль карга бай, апрель суга бай.

Кояш сәгате

Бүген кояш 7 сәгать 34 минутта чыкты, һәм ул 16 сәгать 22 минутта офык артына күмеләчәк. Көн озынлыгы - 8 сәгать 48 минут. Алдагы җиде көнлек дәвамында тәүлекнең якты вакыты 30 минутка артачак, һәм киләсе җомгада, ягъни **11 февральдә** ул 9 сәгать 18 минут тәшкил итәчәк.

Белеп торыгыз

5 февраль - әдәбият галиме Хәсән Хәйринең тууына 90 ел.

6 февраль - Русиядә Григориан календаре гамәлгә кертелде.

7 февраль - ТССР Татарстан Республикасы итеп үзгәртелде (1992).

Татарстан Республикасының Дәүләт гербы кабул ителде (1992).

Тарихчы, җәмәгать-сәясәт эшлеклесе Марат Мөлековның тууына 70 ел.

10 февраль - Татарстанның атказанган артисты Рабига Шакированың тууына 90 ел.

Сәламәтлек көн дә кирәк

Февральнең авыр көннәрендә хезмәттәшләрегез, якыннарыгыз сәламәтлегенә һәм, әлбәттә, үз-үзегезгә аеруча игътибарлы булыгыз. Андый көннәрне исегезә төшерәбез: 5, шимбә **(7.00-9.00),** 8, сишәмбе **(8.00-10.00),** 10, пәнҗешәмбе **(9.00-11.00).**

* * *

Гадәттә, 5 февральдән 10 апрельгә **кадәр бавыр һәм үт куыгы актив булучан. Аларны нәкъ менә шушы көннәрдә чистартырга, ныгытырга һәм савыктырырга кирәк.**

XXI гасырга 331 көн калды

Мин әйттем

Җиңүчене нигә рәнҗетәләр?

Мәрди РАФИКОВ,
Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре, Х.Ямашев бүләге иясе

Буш вакыт табып, ни гамәлдәндер, кулыма байтактан кузгалмыйча яткан ак тышлы папкамны алган идем. Күптән инде архив төсе кергән кәгазьләр, хатлар икән анда. Һәркайсы күз алдында гүя җанланып киттеләр һәм дә бихисап фикерләр уяттылар. Берсен 1979 елның 9 июлендә хезмәттәшем Фәргать Борһан улы Нуруллин язып җибәргән. Аның белән бер гәзиттә хәбәрчеләр булып эшли идек: ул - Кама аръягы районнарында, мин - Идел ягында. Фәргать дустым сугышта ятып калган авылдашларының бәхетсез язмышын ачыклау, данлы исемнәрен кайтару кебек изге эшкә алынган, бу гамәле белән бөтен илгә танылган, хәтта үзәк матбугатта үзе очерк каһарманы булган тынгысыз зат иде. Аның фронт үткән җирләрдәге эзләнүләре гаҗәп уңышлы, без шуңа да бергә сөенә идек.

Миңа килгән хатын укыйм. "Мәрди дускай, - дип яза ул, сәламен тапшырганнан соң, - бу агайэне каян мине исенә төшерде соң әле дип аптырап та калырсың. Ә сәбәбе менә нәрсә. Мин әле яңа гына Свирь елгасы буендагы җиңүнең һәм Карелиянең кайбер шәһәрләрен азат итүнең 35 еллыгын бәйрәм итүдә катнаштым, зур сәфәр кылып кайттым (зурлап, олылап, чакырып, шулай кыландырып йөртүләре өчен, әлбәттә, зур рәхмәт! Мин бит анда сугышып, кан койдым, инвалид булдым...) Ленинград өлкәсенең Лодейное поле шәһәрендәге (Свирь елгасы буе) туганнар каберлегендәге бер язма мине бик нык җәлеп итте (Анда бик күп татарлар күмелгән). Менә ул: "Рафиков Мардыган, кр-ц, 9 стр. полк, погиб 24 марта 1942 г. Похоронен на кладбище у дороги Шамокша. Перезахоронен в военное кладбище города Лодейное поле (ягъни, сугыштан соң аерым каберләрдән җыеп бирегә күмгәннәр). Мәрди дускай, ихтимал, моның исеме, бәлки, төгәл түгелдер, урыслар ашыгып язганда хата җибәргән булулары да мөмкин. Әмма бик яхшы аңлашыла - бу татар кешесе булырга тиеш. Үзем белән дә бик күп татарлар сугышты бирердә. Бераз соңрак (юл йөреп авырдым әле) бу сугышлар, анда катнашучы татарлар һәм хәзерге очрашулар турында "Социалистик Татарстан"га берәр истәлек язу нияте дә юк түгел үземдә..."

Ул чагында, әлеге хат минем тарафка килеп ирешкәч, кызыксынудан бигрәк, уйланып калган идем. Автор хаклы, безнең тирән мәгънәле, әмма әйтергә авыррак исем-фамилиябезне урыслар һәр очракта "җиңеләйтеп", ямьсез бозып яза торганнар иде. Мин дә сугыш елларында шундый тупас "операциядән" соң Мәрди Рафиков кына булып калдым. Хәрби документларда "туксан төрле" яздылар. Фәргать туган да шуңа кинаяли. Үземне урыслар авызыннан хәзер дә, кабер ташындагы исемгә якынайткан сыман, Мардын Галам ишеткәлим. Колак күнегә ич. Исем хакында, очрашкач, Фәргатьнең үзе белән дә гәпләшеп алдык. Кабер ташын күргәч гаҗәпләнеп, уйланып калган ул. Бәлки?.. Юк, мин һәм яшьтәшләрем - ул чагында үсмерләр - Ленинград фронтына өлгермәдек. Бәлки, туганнар? Юк, юк, әти дә, абыйлар һәм кардәш-туганнар да ул якта сугышмадылар. Әмма сәер бер ихтималлык бар: фронтка хатлар "Полевая почта" адресы белән йөри иде ич. Хатларны үзем дә күп яза идем, күршеләр хатыннар да сорап яздыра иде. Ә конвертка исем-фамилияне язу гадәте бар иде. Шундый хатларның берсе һәлак булган сугышчының кесәсеннән табылуы һәм кабер ташына күчүе мөмкин. Ни булса да, еракта, Ленинград җирендә, Свирь ярындагы салкын туфракта минем исем белән Ватаны өчен рәхимсез сугышта шәһит киткән газиз кеше ята - татар кешесе. Мөкатдәс канын кайнар күз яше белән юучы, батырлыгына дога кылучы да булмагандыр. Шул тарафка барырга да, аның рухына кабер ташындагы исемемә баш иярга да теләгән идем. Ләкин...

Әй, бу дөнья! Хәзер кемнәр соң без синдә? Гәрчә, Бөек Ватан сугышы ветераннары дип аталсак та, кемнәр, нинди кешеләр без? Хәтәр дошманга каршы чыккан һәм җиңгән солдатын танымаган, төгәлрәге - куралмаган, еллар үткән саен тирәнрәк мохтаҗлыкта тоткан, авыр фәкыйрьлегенә битараф яшәгән хәзерге дәүләт үзе нинди? Карт солдатын бәхетсезлектә интектергән дәүләтнең хакимияте үзе бәхетле буламы? Юк, юк!

Солдат солдатны үстерә, өлкән буынның батырлыгы матур тәрбияви үрнәк булып яшьләргә күчә. Шулай язган. Сугыштан соңгы елларда бу кагыйдә ныгып та бара иде. Ветераннарның кулында дәүләт транспортында бушлай йөрү өчен махсус документлар бар, алар сугыш җирләренә, полкташлар белән очрашуларга, башка җыеннарга йөриләр, һәлак булган батырларны искә алалар, ә кайткач яшьләр алдында гаҗәп йогынтылы чыгышлар ясыйлар, гомуми белем мәктәпләрендә батырлык дәресләре үткәрәләр иде. Хәтердә, андый ихлас очрашулар малайлар күңеленә батырлык, кыюлык орлыкларын сала иде. Шундый зур тәрбияви чараны югалттык. Хәзер инде сугыш ветераны урам башыннан ары китә алмый, йомылып яши. Бүгенге дәүләт, аның хөкүмәте бармак белән генә санарлык калган Бөек Ватан сугышы ветераннарын бушлай билет белән сөендерергә теләми. Бүгенге юлда самолетлар да, поездлар да буш, шалтырап йөри, югыйсә. Илнең мөстәкыйльлеген канлы сугышта саклап калган карт солдатлар авыр йөк булмаслар иде дип уйлавым. Элек тә ул юлга бер генә мәртәбә чыга иде. Ә хәзер кайбер урыннарда район авыллары арасында сузылган автобус юлында да түләп йөрүне таләп итәләр. Ил азатлыгы һәм бәйсезлеге өчен көчен биргән, сәламәтлеген югалткан сугышчыга дәвалану, бушлай дарулар алу да кыенлашты. Сугыш ветераннарыннан хак сорыйлар. Белмим, хәзерге дәүләт аның белән күпме отадыр, әмма карт солдатын шулай рәнҗетеп киләчәген ничек күрер, яшьләр каршында шөһрәте нинди булыр икән? Картлыгында шөкер итеп яшәрлек пенсиясе дә юк ләбаса пенсионер аганың. Архивтагы сары суккан хатны укыганда шулай бәргәләнәсең. Теге кабергә дә бит шуңа күрә бара алмадым, кесәмдә юл йөрү өчен билет та, меңнәр дә юк иде. Кабере өстендә шытып чыккан табигать гөле булгандыр бүләгем. Үземне шулай юаттым.

Ләкин күңелне тырнаган нәрсәләр байтак. Каратун базарындагы бер вакыйга хәтергә сеңеп калган. Идел аръягы төбәкләрендәге иң эре базарларның берсе иде ул. Тирә-як шул җыен белән көн күрә иде. Һөнәрчеләр оста куллары белән эшләгән көнкүреш әйберләрен сатуга китерәләр, колхозчылар - ашлык, терлек, балыкчылар - балык, сунарчылар ау әйберләре белән сәүдә итәләр иде. Анда кәҗәңә - печән, мичеңә утынга кадәр юнәтергә була торган иде. Базар авыр сугыш елларында да таркалмады. Ә бервакыт, 1941 елның декабрендә бугай, сугыш хәсрәте белән буланып яшәгән халыкны айныткан тамаша булды. Каратун базарына фронттан яраланып кайткан сугышчы килгән иде. Бер аягына аксый. Ә артыннан базарчылар өере йөри. Бу кызылармеец күкрәгенә, тупас сукнолы шинель өстенә медаль таккан икән ләбаса! Талир тәңкәдән дә зуррак, ялтырап торган металл, 4 чатлы планкага беркетелгән. Түгәрәк эчендә - уелган танк сурәте һәм "За отвагу" дип язылган сүзләр. Базар халкы шуңа шашынган, сугышчан медальне һәм аның батыр хуҗасын беренче мәртәбә күрә икән. Артыннан ияреп йөриләр, җае килгәндә кулын кысарга, сүзен ишетергә телиләр, кыюраклары: "Анда безнекеләрне күрмәдеңме, исәннәрме икән?" - дип, сорауларын да биреп маташалар. Ә бала-чага, без - яшүсмерләр яралы сугышчының алдына чыга-чыга медаленә кызыгып карыйбыз. Бөек Ватан сугышының дәрәҗәле орденнары, хәтта асылташлар белән бизәлгән "Победа" кебекләре дә булды, үсеп җиткәч, кайбер орден-медальләрне үзебез дә күкрәккә тактык, ләкин беренче мәртәбә яралы сугышчы күкрәгендә күргән "Батырлык өчен" медале минем алда иң олысы, иң затлысы булып калды. Бүген дә аны таккан ветераннарга сокланып карыйм, чөнки ул кайсыдыр фронтта, ниндидер җирдә гап-гади, хәрбиләр телендә рядовой дип аталган сугышчыга тиңдәшсез батырлыгы өчен бирелгән.

Әй, гел шулай сөенеп кенә яшисе иде дә бит. Ни әйтерсең, сугыш ветераннарының кайберләре бүген бик сирәк була торган үз тантаналарына сугышчан орден-медальләр тагып чыгарга кыенсыналар. Хәзерге җәмгыятебезнең берише тәрбиясез яшьләре, карт солдатның горурлыгын сындырырга теләгәндәй, аңа мыскыллы сүзләрен әйтеп кенә торалар. Йөрәккә тия бу хәл. Солдат күкрәгендәге батырлык билгеләрен кимсеттереп, хөрмәт, дан, олылау дигән төшенчәләрне югалтабыз лабаса! Моның белән бергә армия үзе сула, чөнки аның сафларына тәрбиясезләр килү ихтималы арта. Ә батырлыкка омтылмаган, яшьтән бик яхшы әзерләнмәгән солдат дәүләтнең гаярь сакчысы була алмый. Без - ветераннар шуның өчен гарьләнәбез, яшьләр армиядән кача, ил-җир саклау, бетмәс сугышлар алып бару өчен солдат сатып алалар, хөкүмәт салым, ялланган армия исәбенә бәхетле һәм тыныч яшәргә тели. Юк инде, әфәнделәр, андый тайгак юлны үр менәргә теләүче яратмый. Солдат башына алтын билгеләгәнче, үсмерләребез, яшьләребез белән ихлас эшләүгә кайтасы, билгесез солдат каберләреннән башлыйсы, мәктәпләргә, яшьләр оешмаларына сукмакларны яңадан саласы, гап-гади солдатның гап-гади орден-медале, шуның белән бергә батырлыгы турында әңгәмәләр оештырасы иде бит. Бүген, Бөек Җиңүнең 55 еллыгына әзерләнгәндә, бик санаулы гына булса да, исән ветераннарыбыз бар, аларның сүзен яшьләргә ишеттерәсе, хәер-фатихаларын аласы иде. Чөнки мондый тормышта 60 еллыкка бик сирәкләр барып ирешер. Бу сүзем белән дәүләт һәм аның хөкүмәтенә дә кинаялим. Газиз илне күкрәге белән саклаган данлы ветераннар безнең тормыштан рәнҗеп китмәсеннәр, гомерләренең соңгы елларын иркен сулап, элеккеге ташламаларын кайтарып, муллыкта яшәсеннәр иде. Без авыз суын китереп сөйләгән орден-медальләр өчен дә түләнә иде. Элеккегеләр батырлыкны шулай санладылар. Әйе!

ВАКЫЙГАЛАР ХӘБӘРЛӘР ЯҢАЛЫКЛАР

Җидегән 5 6 7 1 2 3 4

Мөнәсәбәт

НЕ УБИЙ, яки Патриарх сугышны яклый

Инде ничә ай дәвамында телевизорны кабызган саен Төньяк Кавказдагы йөрәк әрнеткеч хәлләрнең шаһиты буласың. Самолетлар авыл-шәһәрләрне бомбага тота. Артиллерия ут яудыра. Танклар, бронетранспортерлар юлларында очраган бар нәрсәне җиргә сеңдереп, тигезләп үтә. Үлем, җимерү. Кыямәт көне диярсең. Картлар, карчыклар, балаларын иярткән аналар, гомер иткән җирләрен ташлап, сыену урыны эзләп чыгып китәләр.

Ә менә Русия хөкүмәте, телевидениесе, матбугаты шул гарасатны тудыручыларны милли каһарман дип атый. Президент вазифаларын башкаручы В.Путин Яңа елны каршылаганда Чечнягә барып, аларга орденнар өләште.

Бу сугышта солдатлар гына түгел, полковник һәм генераллар да һәлак була. Моны да батырлык дип бәялиләр. Әле ике атна элек кенә генерал Малофеевны сугыш җимерекләре арасыннан табып алып кайтып җирләделәр, үзенә Русия Каһарманы исеме бирделәр. Әле яңа гына Советлар Союзы Каһарманы, очучы полковник Николай Майдановныңгомере вертолетта ук өзелде. Аның да мәетен Санкт-Петербургка озаттылар.

Урысның кеме генә үлмәсен - ул батыр. Тагын шунысы да мәгълүм булды: чичәннәрне кыручылар - христианнар икән бит. Нәкъ "тәре сугышы"ндагыча. Өстәвенә, патриарх Алексей II дә Православие дине исеменнән аларга орденнар өләште. Бу носарилар кемгә каршы көрәшә дисезме? Мөселманнарга каршы. Тик Русия мәгълүмат чаралары аларны йә боевик, йә бандит дип атый, террористлар дип халыкны куркыта. Террорчылар яки бандитлар меңнәрчә була алмый. Бу очракта иң яхшы хәрби техника белән баштанаяк коралланган урыс гаскәрләренә танксыз, самолетсыз каршы тора алучы мөселман яугирләренең тиңдәшсез батырлыгы турында да сөйләргә булыр иде. Аларга икеләтә каһарман исеме дә биреп булыр иде! Алар үз җире, үз Ватаны, аның мөстәкыйльлеге өчен көрәшә. Бу сугыш - чичәннәр өчен изге сугыш. Тик мөселман кардәшләребезнең батырлыгын әлегә телевизор экраннарыннан күрсәтмиләр. Әмма сугыш гарасаты тынгач, аларның каһарманлыгы барыбер дөньяга мәгълүм булыр, ул хакта калын-калын томнар язылыр.

Русия чичән каһарманнарын гадәти солдатлар көче белән генә җиңә алмаячагын аңлады булса кирәк, ул хәзер Төньяк Кавказга яллы гаскәрләр җибәрә. Ялланучылар Татарстаннан да байтак. Әле шушы атнада гына Татарстаннан тиз хәрәкәт итүче 20 кешелек төркем җибәрелүе хәбәр ителде. Араларында мөселманнар да бардыр, әлбәттә. Кызганыч, акча хакына мөселман туганына төзәп атучылар Аллаһы Тәгаләнең каһәренә дучар булмасмы?! Кайсы - бүген, кайсылары - кыямәт көнендә...

Заһид ШӘФИГЫЙ.

Хезмәтенә күрә хөрмәте

Сәнгать өлкәсендәге хезмәтләре өчен Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры артисты **ГАЛИЕВА Асия Әмир кызы** Татарстан Республикасының **Мактау грамотасы** белән бүләкләнде.

Яшь буынга белем, тәрбия бирү өлкәсендәге уңышлары өчен Казан шәһәренең 56 нчы коррекцияләү гомуми урта белем мәктәбе хезмәт укытучысы **ЗАРУБИН Анатолий Ивановичка**, Сарман районы, Илексаз гомуми урта белем мәктәбе директоры **НУРИӘХМӘТОВ Риф Нурмөхәммәт улына**, Казан шәһәренең Идел буе районы хакимияте мәгариф бүлеге башлыгы **ПЕРМЯКОВ Николай Павловичка "Татарстан Республикасының атказанган мәктәп укытучысы"** дигән мактаулы исем бирелде.

Идарә карар итте

Узган атнада Татарстан Язучылар берлеге идарәсенең чираттагы утырышы булды. Анда оешманың соңгы вакытта башкарган эшләренә йомгак ясалды, язучыларыбызның юбилейларын үткәрү белән бәйле мәсьәләләр каралды. Утырышта шулай ук 2000 ел өчен Татарстанның Г.Тукай исемендәге Дәүләт бүләгенә кандидатлар тәкъдим ителде. Алар - шагыйрь Зөлфәт ("Ике урман арасы", (1995) һәм "Йөрәгемне былбыл чакты" китаплары (1999) һәм язучы Марсель Галиев ("Догалы еллар" китабы (1999).

Ә инде Татарстан Язучылар берлегенең 2000 ел өчен Г.Исхакый һәм Ф.Хөсни бүләкләре шагыйрь Газинур Моратка ("Түбә", (1998) китабы өчен) һәм язучы Солтан Шәмсигә ("Еллар эзе", (1998) китабы өчен) бирелде.

Идарә утырышында Дамир Шәрәфетдинов, Марианна Вәлишева, Нәкыйп Каштан һәм Вазыйх Фатыйхов Татарстан Язучылар берлегенә кабул ителде.

Ә бүген язучыларның Г.Тукай исемендәге клубында әдәби ел йомгакларына багышланган җыен була.

Җомгадан — җомгага

ҖӨМҺҮРИЯТ ЕЛЪЯЗМАСЫНА ҖӨМЛӘЛӘР

- **Казан Кремлендә Президент М.Шәймиев рәислегендә Татарстан Республикасы Иминлек Советының беренче утырышы булды.**
- Президент М.Шәймиев Берләшкән Гарәп Әмирлекләре Президенты киңәшчесе доктор А.Әбделхаликне кабул итте.
- **Президент М.Шәймиев Ф.Комаровны Әлмәт районы һәм шәһәре хакимияте башлыгы итеп билгеләү турында Указ чыгарды.**
- Татарстан Президент иминлеге хезмәтенең 8 еллыгы билгеләп үтелде.
- **Татарстанда Русия Федерациясе Президентына кандидат В.Путинны яклау штабы оештырылды.**
- Казанда авыл хуҗалыгы мәсьәләләренә багышланган "Нива Татарстана" исемле публицистик журналның беренче саны дөнья күрде.
- **Премьер-министр Р.Миңнеханов үткәргән киңәшмәдә агымдагы елда республика газлаштыру фондының эшенә һәм юл хуҗалыгына кагылышлы мәсьәләләр тикшерелде.**
- Башкалабызга өч көнлек визит белән Финляндия тышкы сәүдә ассоциациясе делегациясе килде.
- **"Казан" милли мәдәният үзәгендә "Хезмәт базарын җайга салуда бүгенге көн проблемалары" дип исемләнгән төбәкара фәнни-гамәли конференция узды.**
- Казанда РФнең "Зур Идел" ассоциациясенә керүче 11 субъектының салым органнары җитәкчеләре очрашуында 2000 елда Идел буе төбәкләрендә салым җыюның планда каралган саны килештерелде.
- **"Татэнерго" җитештерү-энергетика берләшмәсендә 2000 елда кулланучылар белән килешү кампаниясен үткәрү мәсьәләләре буенча киңәшмә булды.**
- Министрлар Кабинетында 2000-2001 елга Хөкүмәт, профсоюзлар, республиканың промышленность предприятиеләре ассоциациясе һәм Сәүдә-сәнәгать палатасы арасындагы генераль килешүгә унынчы тапкыр кул куелды.
- **Шахмат буенча республика беренчелегендә гроссмейстерлар Р.Хәсәнгатин һәм Ю.Машинская җиңү яулады.**
- Казанга Һиндстанның Русиядәге Гадәттән тыш һәм вәкаләтле илчесе киңәшчесе А.Саджанхар килде.
- **Чаллыда милиция оешуга 82 ел тулуга багышлап мәктәп агитбригадалары арасында смотр-конкурс узды.**
- "Казан" халыкара аэропортыннан атнага бер тапкыр ТУ-134 самолетында Прагага бару мөмкинлеге ачылды.
- **Татарстан Диния нәзарәте рәисе Госман хәзрәт Исхакый Бөтендөнья мөселманнары форумында катнашу өчен Чад Республикасына китте.**
- Татарстан профсоюзларының яңа җитәкчесе итеп Т.Водопьянова сайланды.
- **"Казан" милли мәдәният үзәгендә "Татарстанда милли мәдәниятләрнең үсеше һәм үзара йогынтысы" дигән семинар булып узды.**

Сәхифәдә редакция журналистлары, авторларыбыз, "Татар-информ" һәм башка чыганаклар хәбәрләре файдаланылды.

1 нче биттә – күренекле әдип Мөхәммәт Мәһдиев.
З.Бәширов фотосы.

Кайтырсың шикелле тоела...

Бу көннәрдә Башкортстан җәмәгатьчелеге Башкортстанның халык артисты, аккордеончы, композитор Бәхти Гайсинның тууына 70 ел тулуны билгеләп үтә. Гыйнвар азагында күренекле шәхесебезне искә алу чаралары аның туган ягы - Авыргазы районы Кешәнне авылында үтте.

Бәхти Гайсин, чын татар җанлы кеше буларак, татар халык көйләрен эшкәртүгә, аларны пропагандалауга күп көч салды. Җыр сәнгатебезне композитор Бәхти Гайсин язган "Торналар киткәндә", "Ике аккош", "Бөгелә каен", "Кайтырсың шикелле тоела", "Сындырма шомырт агачын", "Кара мыек", "Яратам мин синең көлүеңне" кебек җырлардан башка күз алдына китерүе дә авыр. Аның инструменталь әсәрләре, вальслары, маршлары - үзләре зур хәзинә.

Бәхти Гайсинның иҗаты мәшһүр җырчыбыз Фәридә апа Кудашева белән берлектә аеруча чәчәк атты. Гаилә тормышында да, иҗатта да аларның дуслыгы күпләр өчен үрнәк булып тора.

Суомида безнең вәкил бар

Татарстанның чит илдә уналтынчы вәкиллеге барлыкка килде. Бу юлы - Финляндиядә. Татарстан белән Финляндияне күптәнге дуслык җепләре бәйли. 1999 елда алар арасында тауар әйләнеше 100 миллион доллардан артып китте.

Министрлар Кабинеты карары нигезендә, Татарстанның Финляндиядәге сәүдә-икътисадый вәкиле итеп Әбүбәкер Магҗанов билгеләнде. Вәкиллек Һельсинкида урнаша.

Алхәбәр

8 февральдә унсигез сәгатьтә консерваториянең кече залында Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе, композитор Рафаэль Билалов истәлегенә багышланган камера концерты булачак.

Концертта консерватория педагоглары, студентлар, аспирантлар катнаша. Керү ирекле.

20 гыйнвардан 31 мартка кадәр "Мәдәни җомга" гәзитенә

шушы елның икенче яртысы өчен льготалы язылу бара. Унай форсаттан файдаланып калырга ашыгыгыз: апрель башында, элемтә һәм типография чыгымнары арту сәбәпле, гәзитебезнең бәясе дә кыйммәтләнергә мөмкин.

Кичекмичә

почта бүлекләренә барыгыз - отарсыз!

Әдипне олылау үрнәге

Баулы районының Кызылъяр авылында туып-үскән танылган шагыйрь, прозаик, драматург , Г.Тукай бүләге иясе Фәнис Яруллин үзенең туган ягы белән элемтәләрен өзми. Ул ел саен җәйге айларны бирелә үткәрә. Җәмәгатьчелек, мәктәп укучылары белән очраша, иҗат белән шөгыльләнүчеләргә үзенең киңәшләрен бирә.

Фәнис Яруллинның 60 яшьлек юбилее да туган төбәгендә зурлап үткәрелгән иде. Баулылар әдипнең туган төбәгендә якташлары белән очрашу урыны булсын дип, аңа фатир да бүләк иттеләр. Күптән түгел әлеге фатир урнашкан йорт диварына Ф.Яруллинның барельефы куелды. Аның авторы - Уфа шәһәрендә яшәп иҗат итүче Денис Йосыпов. Барельефны ачу тантанасында Татарстан мәдәният министры урынбасары Лилия Имаева, район һәм шәһәр хакимияте вәкилләре, мәдәният хезмәткәрләре, укытучылар, укучылар, әдипнең иҗатын яратучылар катнашты. Барельефны ачу хокукы Фәнис Яруллинның авылдашы, чордашы, аның иҗатын өйрәнүче һәм киң җәмәгатьчелеккә җиткерүче, Кызылъяр урта мәктәбенең татар теле һәм әдәбияты укытучысы Мәдинә Гыйләҗевага бирелде. Әлеге тантанада чыгыш ясаучылар күренекле якташыбызның тормышына, иҗатына соклануларын белдерделәр, аның туган ягына багышланган шигырьләрен укыдылар.

Факил ЗӘЙНАГЫТДИНОВ.
Баулы.

Таныклык алынды, вәкаләт бетерелде

Татарстан Юстиция министрлыгы каршындагы Дәүләт теркәү палатасының 2000 елның 27 гыйнварындагы карары белән Чичән Республикасы - Ичкериянең Татарстандагы вәкаләтле вәкиллегенә элек бирелгән таныклыгы гамәлдән чыгарылды.

Вәкиллекләр һәм халыкара оешмалар департаменты секторы мөдире С.Мигачева сүзләренә караганда, киләчәктә, ихтимал, вәкиллекнең статусы сәүдә вәкиллеге итеп үзгәртелер.

Күрше хакы – Тәңре хакы

"Ислам конференциясе" оешмасы Русияне кичекмәстән Чечнядагы сугыш хәрәкәтләрен туктатырга һәм низагны сәяси көйләү турында сөйләшүләр башларга чакыра. Ә "Нимес дулкыны" радиостанциясе хәбәр иткәнчә, Ичкериягә Дагыстаннан йөзләрчә ирекләләр агыла, алар, чичәннәр ягында торып, Русиягә каршы азатлык сугышында Дагыстандагы бөтен тарафдарларын күтәрергә вәгъдә итәләр.

Караш

Ичкерия - Катын

Русия чекистлары кайчандыр совет чекистлары Катында кулланган эксгумация ысулын Йчкериянең федераль гаскәрләр басып алган төбәкләрендә бүген дә кулланалар шикелле. Катын вакыйгаларын күпләребез онытты инде, ә кайберәүләрнең ул хакта хәтта ишетәсе дә килми. Бу инде Русиядә күп тапкырлар сыналган ысул: ул үзең кылган җинаятьне башкалар өстенә аудару дип атала.

Гитлер белән Польшаны бүлгәләгәч, Сталин белән Берия 5 мең поляк офицерын аттырып, аларны Белоруссиянең Катын урманында үтә яшерен туганнар каберлегенә күмдерәләр. Көнбатыш бу турыда белеп алып шаулый башлагач, партия ҮК политбюросы гаепне гаепсез немесләр өстенә аудара, янәсе, поляк офицерларын немесләр атып үтерде. Бу пычрак эштә берьюлы ике куянның койрыгын тотар өчен Политбюро совет армиясенең баш хирургы Бурденко җитәкчелегендә яшерен эксгумация уздырып, ялган суд экспертизасы ярдәмендә тарихны ялган юлга кертә: поляк офицерлары күмелгән канауларны ачып, сөякләргә кереп калган совет ядрәләрен немес ядрәләре белән алыштыралар, шул заманда чыккан немес гәзит-журналларын, тәмәке төпчекләрен ташлап, чокырны яңадан күмәләр, шул рәвешле, дөнья җәмәгатьчелегенең күзен буалар. Шулай булмаганда, чекистларның ерткычлыгы теге елларда ук фашистлар ерткычлыгы кебек үк, тарихка кереп калган булыр иде. Ләкин хакыйкать барыбер калкып чыкты: Горбачев перестройкасы вакытында икенче мәртәбә (инде бу юлы бәйсез) эксгумация үткәрелеп, полякларның кем корбаны булуы ачыкланды.

Бәлки, дөнья җәмәгатьчелеген икенче чичән сугышы мәсьәләсендә дә алдап булыр: каберләрне актарып фальсификация ясау хәзер хирург Бурденко заманыннан караганда күпкә "фәнниләште". Әлегә "чичәннәр явызлыгын" эксгумацияләп күрсәткән ялганнарны без чит ил журналистлары катнашыннан башка гына, алардан мең хәйлә белән яшерелгән ялган экран кадрлары аша күрәбез. 1999 елның азагында Моздокта чит ил журналистларын юкка гына кулга алмадылар... 8 сәгать буе энәсеннән җебенә кадәр тикшереп җәфалагач кына аларны, чичәннәр үтермәгәе, дигән булып илләренә мәҗбүри рәвештә кайтарып җибәрделәр: димәк, чит ил журналистлары федераль гаскәрләрнең Ичкериядә ниләр кылуын йозак тишегеннән карарга базганнар? Ләкин без алдан ук белеп торабыз: тиздән бу журналистларны генераллар кабат чакыртып алырлар. Ул чакта инде, ихтимал, федераль гаскәрләрнең гөнаһлары чичәннәр өстенә аударылган булыр...

Локман ЗАКИР.

Премьера

Җан биргәнгә җүнен бирә

Шушы болгавыр бер чорда "Зәңгәр шәл" мелодрамасы буенча куелган яңа премьерабызның гөрләп, шаулап узуы әлеге гыйбарәгә бер мисал дип әйтәсе килә. Театр бу спектакльне

бөек композиторыбыз Салих Сәйдәшевнең 100 еллыгына багышлап куйды. 1938 елны НКВД палачлары тарафыннан һәлак ителгән Кәрим Тинчуринның халык яратып карый торган сәхнә әсәрләре шактый. Әмма арадан берсе дә "Зәңгәр шәл" белән ярыша алмый. 1926 елны язылып, инде авторы халык дошманы дип кулга алынгач һәм бер елдан соң атып та үтерелгәч, 20 елга якын тыелып торган һәм Сталин үлеп берникадәр вакыт үткәч кенә кабат сәхнәгә кайткан бу үлемсез мелодрама менә 64 ел инде тулы заллар җыеп килә. Шушы дәвердә ул кайда гына куелса да һәм әлеге спектакльләрдә нинди генә артист-артисткалар уйнаса да, Советлар Союзының кайсы гына төбәгенә барып чыкса да, тамашачылар тарафыннан шатланып каршы алына, алкышлана килде. Иң беренче куелышларда "Зәңгәр шәл" Тинчурин һәм Сөләйман Вәлиев-Сульвалар тарафыннан сәхнәләштерелсә, 1956 елны аны Ширияздан Сарымсаков куя. 1970 һәм 1986 елларда исә әсәр Марсель Сәлимҗанов режиссурасында дөнья күрде. Әлеге соңгы премьераның авторы да М.Сәлимҗанов. Бу юлы да режиссер үзенә тугры калды, ягъни чор таләпләрен күз уңында тотып эш итте. Дингә тиктомал бәйләнгән урыннарны гына түгел, диннең халыкка әфьюн кебек тәэсир итүен күрсәтү нияте белән махсус язылган күренешне, ягъни ишанның халыктан ямьсез итеп сәдака җыю күренешен дә бөтенләй алып ташлады. Спектакль өчен өр-яңа биюләр куйдырды. Балетмейстер Сәлимә Әминова берничә ай буе артистлар, мәдәният һәм сәнгать академиясенең 1 нче курс студентлары белән репетицияләр үткәрде. Шундый ук өстәмә репетицияләр хормейстер Марат Яхъяев тарафыннан да алып барылды. Талантлы рәссам Рәшит Газиевның сәхнәне бизәүдәге алымнары да, театрның баш рәссамы Сергей Скоморохов костюмнары да режиссерның эзләнүләренә бик тәңгәл киләләр, табышларын көчәйтәләр. Тегү цехының Роза Байбикова җитәкчелегендәге уңган тегүчеләре "Зәңгәр шәл"дә катнашучы һәрбер артистка (кайберләре спектакль барышында икешәр-өчәр кием алыштыра) көне-төне костюмнар тектеләр. Әйтергә генә ансат: 5-6 тегүче бик кыска вакыт эчендә 150 костюм тегеп бирә алды. Әмма бу рекорд түгел, әйтик, алдарак премьерасы уйналган "Җирән чичән белән Карачәч сылу" спектакленә 170 костюм теккәннәр иде алар. Уйлап карасаң, бу бит үзе генә дә искитмәле хезмәт. Әйе, театр арзанлы сәнгать түгел шул. Хәер, су өсте тыныч чакта аннан-моннан эшләнгән салда да йөзәргә, ягъни акчасын табарга була. Ә инде давыл чыкса... Ишан әйтмешли, Алла сакласын. Ишан дигәннән, бу спектакльдә Ишанны Әзһәр Шакиров һәм Фәнис Җиһаншин башкара. Аның хезмәтчесе Гәләвине Рәшит Шамкай уйный. Спектакльдә шулай ук хәлиткеч рольләрнең берсе булган Җиһаншаны Наил Дунаев белән Идрис Мәсгуди уйный. Төп рольләрдә Рамил һәм Илсөя Төхфәтуллалар.

Юныс САФИУЛЛА,
театрның әдәби бүлек мөдире.

● Спектакльдән күренешләр.
Ф.ГАРИФУЛЛИН фотолары.

Чаллы язучылары бәйрәме

Чаллы каласының Сара Садыйкова исемендәге концерт залында Чаллы Язучылар оешмасы төзелүгә 20 ел тулу уңаеннан тантаналы кичә булды.

Анда Татарстан Язучылар берлеге идарәсе рәисе Ф.Галимуллин, танылган әдипләребез Т.Миңнуллин, Р.Вәлиев, Р.Миңнуллин, Ш.Җиһангирова, күрше тирә-як районнарда яшәп иҗат итүче язучылар һәм шагыйрьләр катнашты.

Кичә барышында Чаллы Язучылар оешмасы җитәкчесе Вахит Имамовка һәм барлык әдипләргә котлау сүзләре әйтелде, бүләкләр тапшырылды, аларның эшчәнлегенә югары бәя бирелде.

Шәһәр хакимияте башлыгы Р.Хәмәдиев исеменнән аның мәдәният эшләре буенча урынбасары Ф.Мостафина Язучылар оешмасына котлау юлламасы тапшырды һәм хакимиятнең телләрне һәм мәдәниятне үстерү фондыннан ай саен 5 мең сум акча күчерелеп торачагын белдерде. Ә үзешчән композитор һәм җырчы, шәһәр Советы депутаты В.Агапов әдипләребезгә 22 мең сум акча бүләк итәчәген әйтте.

Әнә шундый ярдәмчеләр булганда Чаллы Язучылар оешмасы яшәр, үсәр һәм үзенең эшчәнлеген тагын да киңәйтеп җибәрер дигән өмет бар.

Яшьләр сынатмыйлар

26-29 гыйнварда Түбән Новгород шәһәрендә театр училищеларының Бөтенрусия фестивале булып узды. Казан театр училищесы студентлары анда Юныс Сафиуллинның "Йөзек һәм хәнҗәр", Хәбир Ибраһимның "Җырлап керәбез, җырлап чыгабыз", Теннеси Уильямсның "Сүтелергә хөкем ителгән" әсәрләре буенча куелган спектакльләр белән катнашты. Иң яхшы хатын-кыз роле һәм иң яхшы ирләр роле өчен беренче призны шушы училище студентлары Айсылу Федотова, Илшат Мәрдәнов һәм Алексей Болязов алды.

"Җырлап керәбез, җырлап чыгабыз" спектакле Түбән Новгородта яшәүче милләттәшләребез өчен тимерьюлчыларның мәдәният сараенда кабатлап күрсәтелде.

Чиккән сөлге булсын бүләгем

Татарстан Мәдәният министрлыгы, Республика халык иҗаты һәм мәдәни-агарту эшләре буенча фәнни-методик үзәк, "Мәдәни җомга" гәзите Бөек Җиңүнең 55 еллыгына багышлап ***"Чиккән сөлге - күңелем көзгесе, кулъяулыгым - сөюем билгесе"*** дип исемләнгән республика бәйгесе игълан итте.

Бәйгенең максаты - борынгыдан килгән кул эшләре аша бүгенге яшьләргә һәм киләчәк буыннарга татар халкының тарихын, гореф-гадәтләрен, йолаларын җиткерү. Шул рәвешле, бәйгедә катнашучылар жюри хөкеменә тарихи сөлгеләрнең төсле фоторәсемен һәм аның кыскача тарихы язылган альбом әзерли, һәр район бишәр кулъяулык тапшыра. Моннан тыш, жюри тарафыннан кәләшләр, киленнәр, әниләр һәм оныклар сөлгесе дә аерым билгеләп үтеләчәк. Шулай ук борынгы кул эшләрен яңарту һәм өйрәтү максатыннан районда, авылда, шәһәрдә оештырылган чаралар, түгәрәк һәм клуб берләшмәләре эшчәнлеге турында кызыклы һәм тулы мәгълүмат та җибәрүегез сорала.

Бәйге 2000 елның март ахырына кадәр дәвам итә. Җиңүчеләрнең эшләре исә 1 апрельдән 15енә кадәр Республика халык иҗаты һәм мәдәни-агарту эшләре буенча фәнни-методик үзәгендә кабул ителә.

Февральдә һава торышы нинди булыр?

Февральгә дә аяк бастык. Ә бу ай - кышның соңгы аккорды. Шулай да февральдә әле бураннар һәм суыклар еш булгалый. Шул ук вакытта февраль кыш һәм яз арасында межа ролен үти. Ай ахырында күктә кояш ешрак балкый: көн яктысы гыйнвардагыга караганда күпкә арта, кояш икеләтә яктырак яктырта. Февральдә халык юрамышлары да елның җылы, эссе, йә явымлы чорын алдан сиземләү белән бәйле, чөнки февральдә инде яз чалымнары ачыграк тоемлана. Аеруча 6 февраль игътибарга лаек: урысларда ул "Аксинья Полузимница" дип атала һәм көн нинди булса, яз да шулай килә, дип уйланыла.

Русия гидромедүзәге фаразы буенча, Татарстанда быел февраль аенда һава торышы һәр елдагы күрсәткечләргә якын. Ай башында һәм азагында төннәрен 5-10 градус салкын булса, икенче ункөнлектә салкыннар 20-25 градуска җитәргә мөмкин. Февральдә явым-төшем 30 миллиметр чамасы булыр, дип көтелә. Ә бу - күпьеллык норма дәрәҗәсендә.

Роза ШАФИКОВА,
Татарстан метеопрогнозлар бүлеге башлыгы.

Җиһан шаһит

✓ ***Русиядә 2 миллион наркоман исәпләнә.***

✓ Төньяк Кореядән Приморье өлкәсенә законсыз качып чыгучылар саны арта бара; качаклар моны илдә яшәү мөмкинлекләре булмау белән аңлаталар һәм Русиядә калырга телиләр яки Көньяк Кореяга җибәрүләрен үтенәләр.

✓ ***Свердловски өлкәсендә пластик карточкалар ярдәмендә банктан 11 миллион сум акча урлаган җинаятьчел төркем тотылды.***

✓ Воронеж тикшерү изоляторында улын үтерүдә гаепләнеп 108 яшьлек Кавказ карты, ике ОМОНчыны үтерүдә гаепләнгән 72 яшьлек бабай утыра.

✓ ***Могилев өлкәсенең Чериков шәһәрендә яшәүче 100 яшьлек А.Вертинскаяны кампитр пенсия алучылар исемлегеннән төшереп калдырып, яңа туган балалар сафына кертеп, әбине пенсиясез калдыра язган.***

✓ Башкортстанда автобусларда бушлай йөрү бетерелде: хәзер билет бәясе - 2 сум, ә экспресста йөрү 3 сум тора.

✓ ***Мәскәүдә 40 кешедән торган хакерлар төркеме кампитр челтәренә үтеп кереп, чит ил һәм Русия сәүдә биржаларыннан алдан мәгълүмат алып, үзләренә бик күп миллион доллар "файда" эшләгәннәр.***

ВАКЫЙГАЛАР, ЯҢАЛЫКЛАР турында хәбәр итү өчен телефон: 92-30-11

Җәһәт әңгәмә

Соңгы вакытта Русиядә дә, республикабызда да сәяси вазгыять шактый үзгәрде. Аерым алганда, Русиядә Президент сайлаулары көн тәртибенә килеп басты, Русия-Беларусь килешүе гамәлгә керде. Болар хакында милләтпәрвәрләребез ни уйлый? Бу җәһәттән, без ТИҮ рәисе Рәшит ЯГЪФӘРОВка берничә сорау белән мөрәҗәгать иттек.

Рәшит ЯГЪФӘРОВ:

МӨСТӘКЫЙЛЬЛЕК ЮЛЫ такыр түгел

- Рәшит әфәнде, соңгы вакытта Татар иҗтимагый үзәге Русия Президентын сайлауларда катнашмаска чакырып халыкка мөрәҗәгать итте. Моның сәбәпләрен аңлатсагыз иде?

- Бу искәрмәстән генә хакимияткә килгән һәм әле эшчәнлеге белән үзен күрсәтеп өлгермәгән (әлбәттә, чичән сугышын көчәйтеп җибәрү һәм чичән халкына карата чын-чынлап геноцид сәясәтен урнаштырудан тыш) В.Путин кандидатурасына мөнәсәбәттән килеп чыккан нәрсә генә түгел. Бу - принцип. Безнең парламент дәүләт мөстәкыйльлеге турында Декларация һәм Конституция кабул итеп, республика үзен халыкара хокук субъекты дип игълан иткән һәм республикада Русиянең беренче Президентын сайлау үтмәгән икән (ул вакытта сайлауларга халыкның нибары 12 проценты гына катнашкан иде) - хәзер дә шул юлдан тайпылмыйча баруыбыз кирәк. Әгәр инде Русиядәге көн-ай саен хакимият алмашынуга, төрле кризислы хәлләргә карап, төп мәслəгебезне туктаусыз үзгәртә башласак, без бервакытта да Русия белән дәүләтара килешүләргә нигезләнеп эш итә торган мөстәкыйль дәүләт дәрәҗәсенә күтәрелә алмабыз. Билгеле инде, империячел Русия һәрчак үзенең "баш" икәнен белдереп, сайлауларын да, башкасын да безгә көчләп тагарга, безне үзенең "субъекты булуыбызны" хокукый яктан нигезләргә тырышыр. Әмма без нык торырга тиеш. Сәяси һәм хокукый мәсьәләләрдә принципиальлек күрсәтеп, Русия сәясәте белән оппозициядә торганда гына безнең өчен алгарыш булырга мөмкин. Русиянең империячел хакимияте милли республикаларның, милләтләрнең хокукларын үз теләге белән арттырыр, хөрлек бирер, дип ышану ул - хыял. Моны аның кул астында дүрт гасыр яшәгән халыклар яхшы аңладылар инде.

Әмма Русиядә вазгыять кая таба гына үзгәрсә дә, республикада эзлекле рәвештә мөстәкыйльләшү сәясәтен алып барырга теләүче көчләр бар һәм булачак. Җитәкчелеккә дә аларның барлыгын онытып җибәрмичә эш итү мөһим. Юкса, бу мәсьәләдә үз республикабыз эчендә дә фикер каршылыгы, таркаулыкка китерүче сәяси дебатлар көчәеп китүе мөмкин.

- Шушы көннәрдә кайбер милләтпәрвәрләр оешмалары да катнашкан "Түгәрәк өстәл" дигән берләшмә Татарстанда Русиянең вәкаләтле вәкилен булдыру кирәклеге турындагы белдерү белән чыкты. Бу - милли оешмалар арасында таркаулык башлану галәмәте түгелме?

- Юк, моны бертөркем милләтпәрвәрләрнең сайлау һәм башка төрле сәяси чаралар вакытында кайбер гаделсез гамәлләргә протест йөзеннән, кызу канлылык белән "ничарадан бичара" эшләгән гамәле дип аңларга кирәк. Русия "наместнигы"ның Татарстанда ни кыласы алдан ук билгеле инде, һәм бу "беткә ачу итеп тунны утка ягу" кебегрәк бер хәлдер. Тунның чыннан да "бетле" булуын без беләбез, әмма аны чит кешеләр ярдәме белән түгел, үз өебездә, бергәләшеп, үз кулларыбыз белән хәшәрәтләрдән арындыруыбыз мәслихәт. Бу юлда без бердәм булырга тиеш.

- Бу атнада Русия-Беларусь арасындагы союз килешүе гамәлгә керде. Бу мәсьәләдә Президентыбызның да фикере билгеле: ул Татарстанны да Беларусь дәрәҗәсендәге союздаш республика итү ягында тора.

- Без бу мәсьәләдә Президентыбызны тулысынча яклыйбыз һәм "Нигә әле бу мәсьәләне иң беренче булып ТИҮ күтәреп чыкмады", дип уңайсызлык та кичерәбез. Мөгаен, якын көннәрдә бу идеяне алга этәрү, республика халкының фикерен Русия хакимиятенә җиткерү өчен, имза җыю эшен башларга керешербез.

Кыскасы, мөстәкыйльлеккә юл такыр түгел. Ул юлда әле беребез, әле икенчебез абыныр. Әмма аңа карап, алга хәрәкәт итүдән туктамыйк.

Телевизорны ничә кеше карый?

Телевизор безнең тормышта мөһим урын били. Аның әһәмияте сайлау вакытларында аеруча арта. Озакламый Русиянең яңа Президенты сайланачак. Русиянең үзәк телевидение каналлары нинди территорияләрне били икән?

Х.САДРИЕВ. Казан.

Бөтенрусия дәүләт телерадиокомпаниясе (ВГТРК), кайбер бик ерак районнарны искә алмаганда, РТР каналы аша Русиянең барлык төбәкләрен биләп ала. Бу канальны илдәге 96,7 процент халык карый (142 млн. кеше).

ОРТ (Русиянең җәмәгать телевидениесе) - Русиянең барлык районнарына барып җитә: димәк, аны барлык халыкның 98,8 проценты яки 146 млн. кеше карый. НТВ каналының аудиториясе бераз таррак - аны 102 млн. кеше карый. НТВ каналы сигналлары Себер һәм Ерак Көнчыгышның кайбер төбәкләренә барып җитми.

ОРТ һәм ВГТРКдан Мәскәүнең бәйсез телекорпорациясе - "ТВ-6 Мәскәү" тагын да күпкә калыша. Бу канал тапшыруларын 79 млн. 644 мең (71 Русия төбәге) тамашачы карый.

Ә инде "ТВ Центр-Мәскәү" телекомпаниясе тапшыруларын 61 млн. чамасы кеше карый. Ул Русиянең 61 төбәгенә хезмәт күрсәтә.

Хәрби хезмәт бәясе

Чечняда сугыш хәрәкәтендә катнашкан солдат һәм офицерларга күпме "хезмәт хакы" түләнә? Һәлак булган уллары өчен әти-әнисе нинди күләмдә компенсация ала? Әгәр солдат сугышта яраланса, аңа күпме түлиләр?

Д.САЛИХОВ. Казан.

Оборона Министрлыгы матбугат үзәге мәгълүматларына караганда, сугышта катнашкан һәр көн өчен армия хезмәтендә саналган солдатлар һәм матрослар 810 сум, сержантлар һәм старшиналар 830, прапорщиклар һәм мичманнар - 850, офицерлар 950 сум акча алырга тиеш.

Яраланган очракта, армия хезмәтенә чакырылган хәрбиләргә 60 минималь хезмәт хакы күләмендә компенсация түләнә. Алар сугышта һәлак булган очракта, әти-әниләре һәм якыннарына (гаиләсе) 120 минималь хезмәт хакы күләмендә компенсация түләнергә тиеш. Әгәр инде офицерлар һәм прапорщиклар сугышта һәлак булса (яки яраланса), аларга яки туганнарына (минималь хезмәт хакы түгел!) 60 һәм 120 "должностной оклад" түләнә.

("Труд").

Җавап - савап

Байлар-байлар бал эчә...

Уйлы да уйла!

Әй, бездә мактанышырга яраталар да соң инде. Янәсе, без зур дәүләт, без көчле, телибез икән, Американы да куып җитеп узып китәбез. Тик теләмибез генә. Теләр идек тә, хәлдән килми шул. Таудан аска таба тәгәрәргә оста без, моның өчен көч куясы да, тырышасы да юк ич. Элекке Президент Борис Ельцин да үзен АКШ Президенты дәрәҗәсенә куеп сөйләшергә ярата иде. Ничек кенә мактанма, ахыр чиктә бөтенесен көч-куәт хәл итә. Көч-куәтне исә, кемнең кулында атом-төш коралы булу түгел, ә күпме байлык җитештерә алу дәрәҗәсе билгели. Күптән түгел "Мировая экономика и международные отношения" (N 10, 1999) журналын актарганда, кызыклы бер таблицага тап булдым. Дөньякүләм тулай продукция җитештерүдә кайсы илнең өлеше күпме булуын чагылдырган көзге бу.

Аерым илләр һәм бертөркем илләрнең өлеше (процентларда)

	1950	1990	2000	2015
Көнбатышның алга киткән илләре	62,8	57,1	52,4	44,6
АКШ	29,8	21,5	20,7	18,0
Япония	3,0	8,9	7,7	6,3
Көнбатыш Аурупа	26,7	23,2	20,7	17,3
Үсеп килүче илләр	22,0	27,7	30,8	34,5
Латин Америкасы	7,1	7,9	8,1	8,5
Һиндстан	3,0	3,2	4,1	5,2
Кытай	4,8	7	12,6	16,3
Элекке СССР	6,7	5,6	–	–
Русия	4,2	3,4	1,5	1,8

Күрәсез, Русия койрыкта сөйрәлә. Югыйсә, ул һәрвакыт империя саналса да, колониаль бәйлелектән күптән түгел котылган Индонезия һәм Бразилия белән икътисадый яктан бер дәрәҗәдәрәк икән. Икътисадчылар аларны тәңгәлләштерәләр.

Чит илләрдә җитештерелгәннәрне сатып алып сәүдә итүебез генә тормышыбызны яхшыртмый. Хакимияткә В.Путинмы, башкасы киләме, икътисадый хәлебез тиз генә яхшырмастыр. Әле безгә 1990 елгы дәрәҗәгә ирешү өчен генә дә күп тырышырга туры киләчәк. Акыллы, зирәк җитәкче килгәндә, халык байлыгын кирәксез сугышларга сарыф итмәгәндә, бәлки, тагын 10-20 елдан моңа ирешербез. Әмма экспертлар, дөньякүләм тулай продукция җитештерүдә Русия 2015 елда 0,3 процент кына үсеш бирер, дигән фикердә тора. Хәлебез мөшкел, туганнар!

Өстәвенә, булганы да тигез бүленми. Байлыкның зур өлеше халыкның 3-5 процентын тәшкил иткән байлар кулында, яртысыннан кимрәге генә халыкның 40 процентын тәшкил итүче урта хәлләләр һәм 40 процентын тәшкил итүче ярлылар карамагында. Ярлыларның кереме айга 50 долларга да тулмый. Байларныкы - 2000 доллардан арта. Бу аерма аларның азык-төлекне куллануында да чагыла. Ярлылар азык-төлекне айга җан башына түбәндәгечә кулланалар: сөт продуктлары - 13,8 литр, йомырка - 9 данә, ит - 2,9 кг балык ашамлыклары - 0,5 кг, җиләк-җимеш - 2,0 кг. Байлар: сөт продуктларын - 23 литр, йомырка - 15 данә, ит - 5,8 кг, балык - 13 кг, җиләк-җимеш - 4,7 кг.

Элекке заманнарда болай җырлыйлар иде:

Байлар-байлар бал эчә,
Урта хәлле - сыра эчә,
Безнеңише ярлылары
Ярга ятып су эчә.

Бу җыр бүгенге тормышыбызны да чагылдыра кебек. Яхшырак яшәргә теләсәк, үзебез җаен эзлик, җирне дә яхшырак файдаланыйк, терлекләрне дә күбрәк үрчетик, җитештерү белән дә шөгыльләник. Алып-сату белән генә байый алмаячагыбыз көн кебек ачык.

Заһид ШӘФИГЫЙ.

Татарстан Дәүләт Советында

Әгъзам **ФӘЙЗРАХМАНОВ,** парламент хәбәрчебез

Вакыт үтә тора

Озын тәнәфес

XIV чакырылыш Татарстан халык депутатлары беренче пленар сессиядән соң өйләренә таралды. Күпчелеге көндәлек вазифаларын башкарырга керешге. Ә менә парламентка даими эшкә килергә ризалык биргән депутатларның мәшәкатьләре җитәрлек бүген. Алар төп эш урыннарында исәп-хисап ясыйлар, Казанга күченеп килергә җыеналар. Күбесенә гаиләләрен дә күчерергә туры киләчәк бит әле. Кыскасы, ташынасы, күченәсе, фатирга урнашасы, аны тиешле тәртипкә китерәсе, гаилә әгъзаларын урнаштырасы, тормыш-көнкүрешне көйләп җибәрәсе бар. Шул мәшәкатьләрдән арынганчы нинди депутат тыныч күңел белән закон язарга утырсын ди. Сер түгел, яңа сайланган депутатларның шактый өлеше закон эшләүнең нәрсә икәнен белеп бетерми әле. Депутат икәнсең, ничек кенә авыр булмасын, бу һөнәрне дә үзләштерергә туры киләчәк. Суга кермичә, йөзәргә өйрәнеп булмавы да көн кебек ачык.

Ә вакыт үтә тора. Суверенлык юлына аяк баскан республика өчен үз законнары кирәк. Әйтер идем, яхшы законнар кирәк. Үткән XIII чакырылыш депутатлары декабрь сайлаулары алдыннан законнар эшләү белән шөгыльләнмәделәр дисәк тә, хакыйкатькә әллә ни хилафлык кылмабыз кебек. Чөнки берәүдә дә закон кайгысы калмады. Һәркем, нинди генә юллар белән булса да, депутатлык мандатын саклап калырга тырышты. Бу - һәр депутат өчен алгы планга чыкты. Ни хәл итәсең, бу фани дөньяда үзең турында да уйламый булмый бит инде. Үзең кайгыртмасаң, синең турыда кем кайгыртыр? Күпме тырышлык куеп та әле үткән чакырылышта актив эшләгән депутатларның шактый өлеше мандатларын саклап кала алмады.

Шулай итеп, менә берничә ай инде Татарстан парламентында законнар эшләнми. Мондый хәлне Дәүләт Советы аппараты объектив сәбәпләр белән аңлатырга тырыша. Янәсе, шунсыз булмый, күчеш чоры.

Законнар эшләүдәге "тәнәфес"не булдырмый калырга яки нык кыскартырга мөмкинме соң? Мөмкин, дип саныйм. Моның өчен кайбер демократик илләрнең тәҗрибәсен өйрәнергә, шулар үрнәгендә кайбер законнарга үзгәрешләр кертергә, ачыграк әйткәндә, сайлау системасын үзгәртергә кирәк.

АКШ Конституциясенә игътибар итегез. Аның сайлау системасына багышланган 1 нче маддәсенең 3 нче бүлегеннән шундый сүзләрне укыйбыз: "Кушма Штатлар Сенаты составына һәр штаттан икешәр сенатор керә. Алар шул штатларның закон чыгару җыелышлары тарафыннан 6 елга сайлана. Һәр сенатор бер тавышка ия. Беренче сайлаулардан соң җыелгач, сенаторлар мөмкин кадәр тигез 3 төркемгә бүленәләр. 2 ел үткәч беренче төркем сенаторлар урыны вакантлы кала (бушый), икенче төркемдә - 4, өченче төркемдә 6 ел үткәч. Шулай итеп, һәр 2 ел саен сенаторларның өчтән бере яңадан сайланып тора".

Димәк, Америка сенаторларының барысы да бер үк вакытта сайланмый. Аның бары өчтән бере генә яңартыла, ә өчтән ике өлеше кала бирә. Әлегә тәҗрибәсе булмаган, яңа сайланган сенаторларны өйрәтә. Аларга да рәхәт. Белмәгән нәрсәләрен сорашырга, тәҗрибә алырга янәшәдә башка сенаторлар бар. Иң мөһиме - законнар чыгару процессы тукталмый. Ул өзлексез дәвам итә.

Яңадан үзебезнең парламентка әйләнеп кайтыйк. Парламентка даими эшкә килергә ризалык биргән 28 депутатның 11е үткән чакырылышта да депутат буларак Дәүләт Советында законнар эшләү белән турыдан-туры шөгыльләнгәннәр иде. Ә башкаларының - 17 депутатның мондый тәҗрибәсе юк. Тагын шунысын да искәртик, бу 17 кешенең берсе дә бүгенге көндә юрист яки икътисадчы булып эшләми, әлеге тармаклардан шактый ерак тора. Юридик яки икътисадый белемнең булмавы аларга законнар эшләүдә өстәмә кыенлыклар тудырачак.

Әлбәттә, бүген килеп туган авыр хәлдән чыгуның юллары эзләнә, төрле вариантлар тәкъдим ителә. Иң кулае - Дәүләт Советы аппаратындагы юристлар санын арттыру. Башка хезмәткәрләр санын киметү исәбенә, билгеле. Һәр даими комиссиягә махсус юристлар төркемен беркетмичә сыйфатлы законнар эшләргә омтылуның буш хыял гына булып калуы бар.

Дәүләт Советының элеккеге спикеры В.Лихачев үз вакытында Татарстан Фәннәр академиясе каршында закон проектлары әзерләү өчен фәнни-тикшеренү институты тибындагы бер структура оештыру турында хыялланып йөргән иде. Ул хыялын тормышка ашыра алмыйча, Русия Федерациясенең Аурупа берлегендәге даими вәкиле буларак Брюссельгә китеп барды. Ул киткәч, әлеге идеяне дә онытгылар. Югыйсә, В.Лихачев тәкъдимендә дә уйлану өчен җирлек бар. Әгәр бу структура проектларны сыйфатлы итеп әзерләп бирсә, парламентка аларны закон кыяфәтенә китерү бик үк авыр булмас та иде.

Кануннар яраклаштырыла

Дәүләт Советының XIV чакырылыш беренче пленар сессиясендә тагын берьюлы 2 законга төзәтмәләр һәм өстәмәләр кертелде. Аларның беренчесе - "Татарстан Республикасы халык депутатларын сайлаулар турында", икенчесе - "Татарстан Республикасы халык депутатларының җирле Советлары халык депутатларын сайлаулар турында". Бу төзәтмәләр нигездә бер үк нәрсәгә - кабат сайлаулар уздыруның срокларына кагыла.

Гамәлдәге законнар нигезендә, әгәр сайлау округы буенча депутатлыкка икедән артык кандидат чыкмаса һәм аларның берсе дә сайланмаса яки сайлау округы буенча сайлаулар йә уздырылмаган дип табылса, яки кабат тавыш бирү сайланган депутатны ачыклый алмаса, Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе бу очракта кабат сайлаулар билгели. Әлеге очракта сайлауларны яңа составтагы участок комиссияләре тарафыннан уздыру кирәклеге турында карар кабул ителергә мөмкин. Тавыш бирү шул ук сайлау участокларында һәм гомуми сайлаулар уздыру өчен төзелгән шул ук сайлаулар исемлекләре буенча уздырыла.

Кабат сайлаулар уздырганда әлеге сайлау округында сайлаулар дөрес түгел, яисә узмаган дип танылган округлардан гайре, гомуми сайлаулар вакытында җитәрлек санда тавыш җыя алмаган гражданнар депутатлыкка кандидат булып яңадан чыга алмыйлар. Законнарга кертелгән төзәтмәләр нигезендә кабат сайлаулар гомуми сайлаулардан соң 4 айдан да соңга калмыйча уздырыла. Элек бу срок ике айга тиң иде.

Сәбәп нәрсәдә соң? Нигә законнарга мондый төзәтмә кертергә кирәк булды? Күрәсең, Татарстанда кабат сайлауларны Русия Президентын сайлаулар белән бер үк көнне үткәрергә ниятлиләр. Ә Президент сайлаулары март аенда билгеләнде. Билгеле булганча, Татарстанда сайлаулар узган елның 19 декабрендә уздырылды. Димәк, кабат сайлауга кадәрге вакыт аралыгы 2 айдан артып китә. Әлбәттә, закон чыгарганда ук мондый хәлләрне алдан күрергә, резерв вакытны ике генә түгел 4-5 яки 6 ай итеп калдырырга мөмкин иде. Күрмәгәннәр. Менә шунлыктан җибәрелгән хатаны соңарып булса да төзәтергә туры килә.

Республика буенча сайланылмый калган депутатлар шактый күп җыела. Татарстан Дәүләт Советына тагын 7 округ буенча сайлаулар үткәрәсе бар. Чөнки аларда декабрь сайлаулары көтелгән нәтиҗәне бирмәде. Үткән пленар сессиядә Яңа Чишмә административ-территориаль округыннан сайланган депутат та вәкаләтләрен вакытыннан алда туктатуын белдерде. Җирле Советларга депутатлар сайланмаган округлар республикабыз шәһәр һәм районнарында да шактый җыела.

Шәһәр төзелеше кодексы

Татарстан Республикасының Шәһәр төзелеше кодексы проекты эшләнде. Әлеге кодекс шәһәр төзелеше өлкәсендә республика халкына көн итү өчен уңай шартлар тудыру максатларында торак урыннарына кешеләрне урнаштыру, төзекләндерү системасын булдырудагы, торак урыннарының инженер, транспорт, социаль инфраструктурасын үстерүдәге, табигатьтән нәтиҗәле файдаланудагы, тарихи-мәдәни мирас объектларын саклап калудагы һәм әйләнә-тирә табигать мохитен саклаудагы мөнәсәбәтләрне җайга сала. Кодексны якын араларда эшләү зарурлыгы 1998 елда Русия Федерациясенең Шәһәр төзелеше кодексын кабул итүгә дә бәйле иде.

Федераль закон структурасы һәм эчтәлеге шәһәр төзелеше мәсьәләләрен җайга салуның тулы бер комплексын федерация субъектлары һәм җирле үзидарә органнары дәрәҗәсендә бүлешү принцибына корылган. Шуңа күрә кодексның төп максаты Татарстан дәүләт хакимияте органнары, шәһәр һәм район хакимиятләре, җирле үзидарә органнары арасында шәһәр төзелеше өлкәсендәге вәкаләтләрне алмашу һәм эшләр бүлешүдән гыйбарәт.

Татарстанда Җир кодексы инде күптән кабул ителгәнлектән, республиканың Шәһәр төзелеше кодексының федераль законнардан үзенчәлеге җиргә кагылышлы мөнәсәбәтләрне җайга салуга, җирле үзидарә органнары вәкаләтләре өлкәсендә принципиаль аермалыкка ия булган гамәлдәге закон чыгару базасына бәйле. Республика дәрәҗәсендә шәһәр төзелеше эшчәнлегенең хокукый нормаларын билгеләүче законнарның булмавы бу өлкәдә башбаштаклыкка юл куя иде. Шунлыктан республикада шәһәр төзелеше эшчәнлеген гамәлгә ашыру барышында килеп туган иҗтимагый мөнәсәбәтләрне җайга салучы норматив-хокукый база булдыру зарурлыгы бәхәссез бүген. Кодекс кабул ителгәч тә, анда салынган хокукый нормаларны гамәлгә ашыру өчен өстәмә рәвештә тагын кайбер законнар, шәһәр төзелеше нормаларын, кагыйдәләрен эшләргә туры киләчәк.

Кодекс проекты Татарстан Архитекторлар берлеге тарафыннан Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгы заказы белән әзерләнде. Проект Татарстан Конституциясенә, Җир кодексына, Русиянең Гражданлык һәм Шәһәр төзелеше кодексларына, башка хокукый-норматив актларга таянып эшләнде. Финанс, Эчке эшләр, Икътисад һәм сәнәгать, Юстиция, Әйләнә-тирә мохитне саклау һәм табигый ресурслар, Гражданлык оборонасы эшләре һәм Гадәттән тыш хәлләр министрлыклары, Җир эшләре, Санитария-эпидемиология күзәтчелеге дәүләт комитетлары, Казан шәһәр хакимияте закон проекты буенча үзләренең бәяләмәләрен һәм тәкъдимнәрен бирделәр.

Шәһәр төзелеше эшчәнлеген башкарганда торак пунктларының үзенчәлекләре, шул исәптән халык саны, фәнни-җитештерү мөмкинлекләре, шулай ук торак пунктларының халыкны урнаштыру системасындагы роле исәпкә алынырга тиеш. Торак пунктларының типларына карап, шәһәр төзелеше документларының төре һәм эчтәлеге, аларны әзерләү тәртибе, гамәлдәге норматив-хокукый актлар нигезендә килештерү һәм раслау тәртибе билгеләнә.

Конституция нигезендә һәр граждан шәһәр төзелеше турындагы законнар бозылу нәтиҗәсендә сәламәтлегенә һәм мөлкәтенә китерелгән зарарны түләттерүгә, гаепләләрне җавапка тарттыруга хокуклы. Шәһәр төзелеш эшчәнлеген башкарганда гражданнарның яшәү урыны сайлап алуга, сәламәт әйләнә-тирә табигать мохитенә карата конституциячел хокукларын гамәлгә ашыру өчен кирәкле шартлар тәэмин ителергә тиеш. Предприятиеләр, учреждениеләр, оешмалар дәүләт шәһәр төзелеше нормаларына һәм кагыйдәләренә, халыкның яшәве өчен уңай шартлар тудыру таләпләренә туры китереп урнаштырыла. Шәһәр төзелеш эшчәнлеген башкарганда гражданнарның ялга булган хокукларын тәэмин итү максатларында уңайлы табигый-климатик, дәвалау, санитария һәм гигиена шартлары, башка төрле уңайлыклар исәпкә алына, сәламәтләндерү әһәмиятенә ия булган объектларны урнаштыру өчен территорияләр бүлеп бирелә.

Тарих, мәдәният, археология ядкарьләре, махсус саклаучы табигать территорияләре булган торак пунктларында саклау зоналарының чикләре билгеләнә, анда хуҗалык эшчәнлеге тыела.

Архитектура һәм шәһәр төзелеше буенча республика органына зур бурычлар йөкләнә. Ул бу тармак буенча дәүләт сәясәтен эшләүне һәм гамәлгә ашыруны оештыра, шәһәр төзелеше өлкәсендә фәнни-тикшеренү, проект оешмалары эшчәнлеген җайга сала, топограф-геодезия, картография эшләрен лицензияләүне гамәлгә ашыра, инженерлык эзләнүләрен башкару этапларын билгеләнгән тәртиптә терки.

Шәһәр төзелеше документларының закон таләпләренә туры килүен билгеләү максатларында, шулай ук территорияләрнең, инженерлык, транспорт һәм социаль инфраструктура үсеше схемаларына һәм проектларына дәүләт экспертизасы ясала. Шәһәр төзелешенең төп документы булган генераль планда социаль-икътисадый үсеш үзенчәлекләре, табигать-климат шартлары, халык саны, территорияне үстерүнең юнәлешләре, инженерлык, транспорт һәм социаль инфраструктураны үстерү чаралары искә алына.

Шәһәр төзелеше эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен территорияләр зоналаштырыла. Зоналаштыру тормыш эшчәнлегенең уңай мохитен тәэмин итүгә, территорияләрне гадәттән тыш хәлләр йогынтысыннан яклауга, әйләнә-тирә мохитнең пычрануын булдырмауга, авыл хуҗалыгы җирләрен, урманнарны саклауга юнәлдерелә. Шәһәр төзелеше нормалары һәм кагыйдәләре республиканың табигать-климат, социаль-демографик, милли һәм башка үзенчәлекләрен исәпкә алып әзерләнә. Бу таләпләрне шәһәр төзелешендә катнашучыларның барысы да, һичшиксез, үтәргә тиеш.

Тәуфикъ КАМАЛИЕВның тууына 60 ел

"Шигырьләрем кайчак кирәгеннән артык озын булсалар да, үтелгән юллар бик-бик кыска әле", - дип яза Тәуфикъ Камалиев үзенең 1967 елда чыккан беренче китабында. Ул үзе, 1940 елны Буа районының Ташкичү авылында туган. Җиденче сыйныфны Казанда тәмамлап, һөнәр училищесында белем алып, заводта слесарь булып эшли башлаган егет кулында - каләм, йөрәгендә илһам йөрткән. Зур иҗатка Тәуфикъ Камалиев нәкъ менә 60 нчы елларда аяк баса. 1966 елда Казан дәүләт университетын тәмамлаганнан соң, ул "Ялкын", "Социалистик Татарстан" кебек журнал-газет редакцияләрендә, Татарстан телевидениесендә эшли. Шагыйрьнең төп хезмәте, әлбәттә, әдәбиятта. Аның "Ромашкалар эзлим" (1967), "Сабыр канатлары сынмый" (1968), "Адымнар" (1969), "Сезгә генә сөйлим" (1970), "Хәләл көчем белән" (1972), "Яшьлеккә кайту" (1978), "Ак өметләр" (1986) кебек җыентыклары дөнья күрде. Кызганыч, талантлы каләмдәшебез бу соңгы җыентыгын үзе күреп өлгермәде, 1980 елның 13 февралендә көтмәгәндә арабыздан китеп барды. Күрәсез, аның җирдәге гомер юлы алай ук озын булмады...

Ә бу шигырьләрне без шагыйрьнең гаиләсендә сакланган архивыннан алдык.

САГЫНУ САГЫШЫ

Без яшибез, эти, синнән башка,
Синең язмыш - солдат язмышы.
Язмыш гадел, тугры дисәләр дә,
Ул бу юлы тагын ялгышты...

Истәлеккә иске шинелең дә,
Хатларың да килеп калмаган.
Дога итеп көн дә ятлар идек,
Шул шинельгә сыенып яңадан.

Әтиләләр нурда коенган күк,
Яшь ага да ага нигәдер;

"Әти!" - дигәч, шундый рәхәт микән,
Әйтеп карыйм сиңа мин дә бер...

Эти кирәк - эти булгачтын да,
Синнән безгә күчте яралар.
Яралардан җылы кулы белән
Синнән башка кемнәр аралар?!

Без яшибез, эти, синнән башка,
Синең сүзгә сусап яшибез.
Кырык бердә туган балалар без,
Кырыкта да, шуңа, ятим без...

* * *

Йолдыз булып ялтыраучылар - ялтырасын,
Булмасмы, дим, дөнья бераз яктырак соң?!

Булыр идем мин тегермән ташы гына,
Ак оннарны капчык белән ташы гына.

Әйләнергә иде бергә заман белән,
Булышмыйча һаман да үз ярaң белән.

Ачлар әле дөнья тулы Җир шарында,
Тегермәннәр гөрләп торсын син барында.

Мин тегермән ташы гына булыр идем,
Әй син, дөнья! Ак он белән тулыр идең...

* * *

Бу дөньяда һәркем үзенең хакын сорар,
Алладан - бай уч тутырып алтын сорар.
Акыллылар - әле тагын акыл сорар,
Юләр - гүзәл вә сылу хатын сорар.

И Ходаем, диваналар, димә инде,
Бай кешегә уч-уч алтын нигә инде?
Акыллыга тагын акыл нигә инде,
Шыр тилегә матур хатын нигә инде?

Чү, ашыкма, байның нәфсе юк, дисеңме,
Акыллыга хәким булу чүп, дисеңме?
Тилеләрнең эчтә җаны юк, дисеңме,
Ә матурлар әллә шулай күп, дисеңме?

Тик калачак... алтын-көмеш бүтәннәргә,
Һәм акыллы хәким өлеше - бүтәннәргә,
Син яраткан сылулар да калачак бит,
Иң сөймәгән дошманыңа - бүтәннәргә...

ӨМЕТ

Әрни күңел, ямансу,
Ярга кага агымсу.
Нишләр тагы бу йөрәк,
Таянырга юк терәк.

Әй, өмет, өмет, өмет,
Син миңа җаным кебек,
Син миңа ярым кебек,
Син генә калдың, өмет...

* * *

Су төбендә йолдыз җемелди,
Соңгы өмет кебек - төптә үк.
Ә камышлар тынып калганнар,
Камышларның тыны беткән күк.

Су төбендә йолдыз җемелди,
Нәни маяк кебек - еракта.
Охшыйдыр ул ятим кызларга,
Гүя аны берсе елаткан.

Су төбендә йолдыз җемелди,
Соңгы өмет кебек - төптә үк:
Ә яңадан күккә ашарга,
Кодрәт көче тәмам беткән күк.

Җемелдәми инде йолдыз да,
Сулкылдар да йөрәк сулкылдар.
...Агып китте якты йолдызым,
Алып китте зәңгәр дулкыннар...

КЛИНДЕР

Кәшәкә уйныйлар малайлар,
Ни карап торадыр агайлар!

Уйныйлар ду килеп тыз да быз,
Тирләгән малайлар, "кызган" боз.

Тик шайба дигәнең - клиндер,
Ыргыткан малае кемнеңдер.

Таш булган клиндер салкыннан,
Язганнар, ахыры, акылдан.

Гол санап кылана абыйлар,
Дәшми дә сакаллы сабыйлар.

Болар бит оныткан узганны -
Күңелгә утырган тузаны.

Клиндер... Суксалар тагын бер,
Ул түгел, йөрәгем ярылыр.

Икмәктән зур булып кыланган -
Соңыннан гел хәер соранган!

Кәшәкә уйныйлар малайлар.
Ни карап торадыр агайлар!..

* * *

Кыйблаларның кайсы якта
Икәнлеген белсәм дә,
Ай-кояшка кереп, көн-төн
Кай җирләрдә йөрсәм дә,
Мин көткән сылу фәрештә
Килер, дим, бүтән төштән...
Көенеч шуннан артмас, дим,
Кимер, дим, көтәм эчтән.

Кайгылар бар, шатлыклар бар,
Бу дөньяда син дә бар;
Синнән кала, сине көткән,
Сагынып беткән мин дә бар.

Шуларның барын бергә куш,
Күңелдән кат-кат ятла;
Кыйбла син киткән якта ул,
Кыйбла син кайтыр якта.

Гүзәллекне эзләп узды гомер, Гүзәллекне эзләп югалдым...

РӘШӘЛӘРЕМ ДӘШӘЛӘР ДӘ...

Дөньяга мин юкка туганмындыр
(Ул шулай да була, туганым).
Гүзәллекне эзләп узды гомер,
Гүзәллекне эзләп югалдым.

Ялан тәпи куган, мин сокланган,
Еракта ук калган рәшәләр,
Яңадан бер яшәп бак әле, дип,
Үзләренә кире дәшәләр.

Дәшәләр дә, дәшмәс иделәр дә,
Кайгыларым кайный бәгырьдә.
Ераклаша бара рәшәләрем,
Якынлаша барам кабергә.

Өркү юк та... булсын соңгы өтер,
Соңгы нокта... бар да бер көндә.
Тарлавыгы тарткач тар дөньяның,
Тар кабердән нигә өркергә?!

Уйлар кала ташка уелмыйча,
Үксез бала кебек үртәлеп.
Ояларын җуйган кошлар сыман,
Алар мине мәңге эзләр күк.

Уйлар кала, шул җәл. Туганмын да,
Ялгызларга юлдаш булганмын.
Гүзәллекне эзләп узды гомер,
Гүзәллекне эзләп югалдым...

шигырь нечкәлек билгесе белән языла

Эй, служивый!..

Мөхәммәт **МИНАЧЕВ**,
"ВАТАН" партиясе рәисе

Милләт, милләт, дип күпме генә тәкрарласак та икърар итәргә туры килә: халыкның зур күпчелеге үз язмышына карата барыбер дә битараф булып кала бирә.

Ә ул битарафлык чиреннән ничек дәваланырга соң? Бу мәсьәлә Тукайны да борчыган, Исхакыйны да, башкаларны да. Тукай, уян татар, уйлан татар, дип оран салган. Исхакый, әгәр шулай йоклап ятсаң, син, татар, 200 елдан соң бетәчәксең, тарих арбасыннан төшеп калачаксың, дип кисәткән. Инде бу әйтелгән сүзләрдән соң бер гасырга якын вакыт үтеп тә китте, ә татар шул килеш йокысын дәвам итә бирә.

Татарга, урыс дәүләте кул астына кергәннән бирле, бер иркенләп сулыш алырга туры килгәне юк, гасырлар буе басым астында яшәдек, дәүләт сәясәте безне үз юлыбыздан, гореф-гадәтләребездән, динебездән аерып, урыслаштыруга юнәлтелгән иде. Бу дәүләт әле дә шул ук юл белән бара, чөнки ул бүтән юлны белми.

Дөрес, инкыйлаплар, реформалар була тора. Менә соңгы реформа вакыты 1989 елдан 1993 елга чаклы сузылды. Бер күтәрелгән булдык та, әмма бик тиз шиңдек. Без үз батырлыгыбыздан үзебез шүрләп калдык шикелле. Югыйсә, хаким дәүләтнең басымына каршы торырга өйрәнгән дә кебек идек инде, чөнки ике гасыр буе Н.Булавин, С.Разин, Е.Пугачев фетнәләрендә төп катнашучылар без - татар-башкорт, чуаш, мордва булдык. Шушы күтәрелешләрнең ни өчендер Псков, Новгород яки Смоленски, Киев тирәләрендә түгел, ә Идел-Урал-Дон буйларында булулары шул хакта сөйли. Урыс халкы катнашмады анда, баш күтәрмәде, боларның барысы да яңа урыслашкан татарлар иде. Билгеле, аларны тарихчылар урыс дип язды.

Татар соңгы тапкыр әле моннан 120 ел элек кенә (?) күтәрелде: 1879 елда Әтнә татарлары, Батырша восстаниесе - моның ачык дәлиле. Димәк ки, татар тышкы басымга, тышкы дошманга каршы кулына корал алып көрәште, әмма җиңә алмады, азатлык ала алмады.

Милләтне эчтән җимерә торган көчләр дә бар бит әле, аларга каршы әлегә кадәр берәр чара табылганы юк. **Шуңа күрә хаким дәүләт татарны татар кулы белән эчтән җимерә. Бу эштә ул "йомышчы татарлар"ны бик оста файдаланды.** XVI-XVII гасырларда киң таралган шушы атама бер төркем татарга гына караса, безнең чорда тулы бер милләтнең милли сыйфатына әверелә бара. Бу очракта "йомышчы татар" термины урыс дәүләтенә хезмәт иткән һәр татарга карата түгел, ә шул дәүләткә җаны-тәне белән бирелеп, үз милләтпәрвәрләренә каршы эшләгәне өчен, үз милләтенең киләчәгенә балта чапканнарына карата кулланыла. Андый кешеләр бер татар милләтенә генә карамыйча, төрле милләт әһелләренә дә кагылышлы булып чыкты. Әйтик, шул ук Д.Завгаев, У.Автурханов, Б.Гантимеров һәм башкалар "йомышчылар" түгелмени?

Без "йомышчы татар"ны матбугатта, телевизор экраннарында да еш очратабыз, аларның эшләренә, алар исеменә нинди генә мактау сүзләре яңгырамый.

Мәсәлән, Түбән Новгород өлкәсендә чыга торган "Туган як" гәзите менә нилләр яза: *"Үткән шимбә көнне "Һилял" хәйрия фонды җитәкчесе Рәшит Баязитов Түбән Новгород өлкәсе администрациясендә губернатор Иван Скляров белән очрашты. Өлкә җитәкчесе инициативасы белән оештырылган бу чарада Түбән Новгород һәм Арзамас митрополиты Николай атакай (?)... катнашты... Очрашуда Уварова чиркәвен яңадан файдалануга тапшыру турында сүз барды... Рәшит Җаббарович җитәкләгән оешмалар катнашында өлкәбездә дистәләгән мәчетләр төзелде... Әлбәттә, болар Рәшит Җаббарович башкарган олы эшләрнең тик берничәсе генә. Аларга тиешле бәя биреп, Погорелка чиркәвен ачканда, губернатор исеменнән академик Рәшит Баязитовка "Түбән Новгород өлкәсенең хөрмәтле меценаты" дигән таныклык тапшырылган иде. Митрополит Николай атакай танылган якташыбызны изге орден белән бүләкләде... Рәшит Баязитов халыкның рухи мирасын саклап калырга тырыша, киләчәк буыннар турында кайгырта... Очрашуда сүз кайбер колхозларда Канада дуңгызларын үрчетү, мәктәпләрне яңа уку елына әзерләү һәм бушлай дәреслекләр белән тәэмин итү турында барды. "Һилял" фонды 1-11 класслар өчен дәреслекләр бастыра икән" ("Туган як", N29, 30.07.99 ел).*

Гәзиттән шундый зур өзек китергән өчен укучым гафу итсен мине, чиркәүләр төзеп йөргән татар баласыннан ничек итеп татарның киләчәген кайгыртучы чыгар икән? Аның тырышлыгы урыслашу процессын тагын да көчәйтмәсме икән? Бик борчылам, борчылмый хәлем юк, аның эшләренә милли юнәлеш биреп тә, һич булмаса туктатып та булмый. Менә бүгенге йомышчы татарның гамәле шундый, ул үз милләтенә бер тиенлек файда кылса, артыннан ук мең сумлык зарар эшли. Кайдан килгән безгә бу бәла? Әлеге мәсьәләне ачыклау өчен чал тарихка бер әйләнеп карыйк әле.

Урыс дәүләте гасырлар буе изелеп килгән милләт өстендә төрле тәҗрибәләр үткәрә килеп, күндәм "яңа татар" милләтен барлыкка китерде. Хәзерге вакытта милләтне тулаем диярлек йомышчы татар төркеменә кертергә була.

Йә, хуш, безгә нинди юл сайларга кирәк соң? Кем безгә ул юлны күрсәтер? Хәзерге вакытта Татарстан Республикасы татар халкының киләчәген тиешенчә кайгырта алмый әле. Татарлар XX гасыр буе урыслашып барды. Моңа каршы әлегә бер генә дә механизм эшләнгәне юк - монысын барчабыз күреп тора. Ә татарның Татарстаннан гайре башка дәүләтчелеге юк. Татарның бөтен бәласе аның ирекле юклыкта, чит-ят дәүләт аңа үз ихтыярын көчләп тага, шушы йогынты безнең үсешкә киртә булып тора.

Русия матбугатында дәүләтләрнең, урыс халкының киләчәге турында шактый гына материаллар басыла, ә анда татарларның киләчәге һәм Русиядәге башка милләтләр язмышы турында бер сүз язылмый. Әйтелмәгән сүз арасында шушындый фикер ярылып ята: киләчәктә татарлар, үз дәүләте булмаган татарлар, әкренләп башка милләтләр арасында эреп бетәчәк. Әлбәттә, моның белән килешергә бер дә теләк юк, татар халкы эреп бетмәс, сакланыр әле, дип кул селтәргә дә урын юк, чөнки чынлап та хәлләр әйбәттән түгел, монысы барыбызга да билгеле. Кемдер безнең язмышны хәл итәргә тырыша, киләчәгебезне чикләмәк була, тарих битеннән сызып ташларга омтыла. Ул кем генә булмасын, аны ачыклау бу мәкаләдә максат итеп куелмый. Ничә мең ел яшәп килгән халык, ничек инде бернинди сәбәпсез (кемнәрнеңдер ихтыяры белән), якын елларда бетәргә тиеш? Моның белән берничек тә, беркайчан да килешеп булмый һәм булмаячак.

Димәк ки, татар буларак тарихтан төшеп калмау өчен юлларын эзләргә керешергә кирәк, һаман көтеп тору үлем белән тиң булачак.

Безләр өчен бердәнбер юл кала: тышкы йогынтыдан арыну! Аны ничек эшләргә? Без, чичәннәр шикелле, азатлык өчен сугышырга әзер түгелбез.

Без, татарлар, инде иң кимендә ике мең ел элек дәүләтләр төзеп, бөтен эреле-ваклы түрәләр системасын булдырып, җирле административ бүлекләр төзеп эш итәргә күнегеп беткәнбез. Бездә түрә бөтенесен хәл итә - бу система каныбызга сеңгән. Кемгә хезмәт итәргә: татар дәүләтенәме, урыс дәүләтенәме? Акча гына булсын. Татар дәүләте системасы җимерелгәч, халык урыс дәүләтенә хезмәт итә башлый. Җитмәсә, урыс дәүләте бөтен көчен, сәләтен туплый, акчасын җәлләми, кайсын сатып, кайсын куркытып, гасырлар буе үз сәясәтен үткәрә. **Әкренләп татар йомышчы рәтенә күчә килә.**

Татар дәүләт системасы турында сүз чыккан икән, без йомышчы татарлар икәнлегебезне танырга мәҗбүрбез һәм ничек иттереп түрәләребезне яңадан үз милләтебез ягына бору турында уйларга тиешбез. Шулай эшләмәгәндә безнең киләчәк чынлап та куркыныч астында. **Танырга тиешбез: милләт киләчәге тулысынча татар җитәкчесе кулында, ул аны хәл итә, ә без аңа юлларын күрсәтергә тырышыйк.**

Икенче юнәлеш - үз эчебезгә, үз кабыгыбызга ябылу, урыс дәүләте эчендә мөмкин кадәр урыстан ераклашу юлларын табу, эчке эмиграциядә милли мохитне барлыкка китерү булырга мөмкин. Эчке эмиграция дигәннән, ул татарны бер җирдән икенче җиргә күчерүне түгел, ә үз эчебезгә йомылуны, ягъни, самоизоляцияне аңлата. Дөрес, урыс-яһүд галимнәре самоизоляциягә кергәннәрне регресс көтә дип куркытып килә. Әйтерсең, татар урыс белән бергә 447 ел эчендә бик югарыга үрмәләде?! Анналары, хәтерләсәгез, Балтыйк буе халыкларын, әгәр СССРдан чыксагыз, ачка үләчәксез, сезләрне Русия ашата, дип кисәттеләр. Хәзер инде бөтенебез күрә: бар да киресенчә булып чыкты, анда прогресс, ә бездә регресс чәчәк ата. Эчке эмиграция белән дә шундыйрак хәлләр көтәргә мөмкин. **Самоизоляция һич тә бөтен дөнья белән араны өзү дигән сүз түгел; күршедә яшәгән урыс агае, хезмәттәшләр, сабакташлар белән аралашмау, фәнни-техник яңалыклардан баш тарту, яисә аларны өйрәнмәү дигән сүз түгел; шулай ук Русия Федерациясеннән дә чыктым дигән сүз түгел ул, монда милли мохитне булдыру турында гына сүз бара.** Әлбәттә, милли мохит бер Татарстанда гына булырга тиеш түгел, башка төбәкләрдә дә барлыкка килергә тиешле ул. Милли мохиткә бар да керә, бөтен татар халкы сыя, анда милли тәрбия, милли мәгариф системалары, милли икътисад керә, ягъни тормышта алыш-биреш, көнкүреш, сәүдә эшләрен үзара уртак итү шарт.

Кеше, әйбер алганда, үз кешесе аңарга арзанрак бирсен иде, дип өметләнә. Бу - дөрес түгел, сатучыга да табыш кирәк, ә аңа башкасы да бушлай бирми. Син үз кешеңнән сатып алмыйча, ятлардан аласың икән, ул чакта синең милләттәшең табышсыз кала, милләттә йөри торган акча юкка чыга. Әгәр шулай эшләсә, бөтен татар, димәк ки, милләткә керәчәк табыш чит милләткә күчеп бетә. Елдан-ел шулай кабатланган чакта, милләт хәерчелеккә төшә, милләттәшләр үзара эш алып барудан туктый, алыш-биреш бетә, милләттәшләр арасында якынлык югала, арага чит-ят милләт кешеләре кереп тула. Хәзерге татар милләте нәкъ шушы хәлдә. Шуңа күрә милләттә бердәмлек тә юк, әлегә берләшергә теләге дә юк.

Күрәсең, безгә кыюрак адымнар ясарга кирәктер. Мәсәлән, 1990-92 елларда Татарстан азатлык даулый башлагач, аңа үзенең нефтеннән күп булмаса да өлеш чыгарылды, Татарстанда халык бүтән төбәкләр белән чагыштырганда яхшырак яши башлаган иде. Тулаем диярлек Русия законнары нигезендә яшәүгә күчкәч, киресенчә, тормыш башка төбәкләрдәге шикелле авыраеп китте. Турысын гына әйткәндә, без бөтен проблемаларны үзебез чишәрдәй халык, тик бер-беребезгә ышанып эш итәргә, бер-беребезне алдамаска, сатмаска, бер-беребезне якларга, сакларга гына кирәк. Бигрәк тә түрәләребез бер якта, милләтчеләребез икенче якта булмаска тиеш. Карашларны ничек тә якынлаштыру кирәк. Югыйсә, милләт эчендә урыслашу процессы туктаусыз дәвам итәчәк.

Мәскәү.

Мамадышларны Шәйхи Маннур берләштерә

Безнең бәрәкәтле җиребез талантларга гаять бай. Аерым төбәкләрдән нинди генә иҗат әһелләре чыкмый: язучылар, композиторлар, рәссамнар, артистлар, галимнәр... Гадәттә, теге яки бу районда туып үскән талант ияләрен ниндидер бер олы шәхес үз тирәсендә туплап тота кебек. Мамадыш яклары өчен мондый рухи үзәк, мөгаен, күренекле әдип Шәйхи Маннурдан гыйбарәттер. Әлеге районның талантларын нәкъ менә ул үзара берләштереп яши. Моның шулай булуы биредә үткәрелгән үзенчәлекле бәйрәм - Ш.Маннурның тууына 95 ел тулуга багышланган тантаналарда да ачык күренде.



● Мамадыш үзәгендә Шәйхи Маннурның яңартылган һәйкәле (Б.Урманче эше).

● Район хакимияте башлыгы Ф.Идиатуллин шигърият бәйрәмендә Л.Могтәсимовага Ш.Маннур исемендәге бүләкнең дипломын тапшыра.

Бәйрәмдә катнашу өчен Казан һәм Чаллыдан бер төркем әдәбият һәм сәнгать әһелләре кайтты. Алар арасында Татарстанның халык шагыйре Илдар Юзеев, язучы Вакыйф Нуруллин, Язучылар берлеге рәисе урынбасарлары Шаһинур Мостафин, Галимҗан Гыйльман, "Мәдәни җомга" гәзитенең баш мөхәррире, шагыйрь Зиннур Мансуров, Татарстанның халык артисты Мингол Галиев, "Идел" журналының баш мөхәррире, язучы Рашат Низами, язучылар Ләбиб Лерон, Мансур Сафин, Марат Закир, Рәис Апуш һ.б.лар бар иде. Бәйрәмдә шушы төбәктә яшәп иҗат итүче шагыйрьләр Рафаил Газизов, Вахит Галиев, Вәрис Гали, Сәяф Шәйхи дә катнашты.

● Әдипнең туган җирендә кунакларны каршылау.

● Ш.Маннурның музей-китапханәсендә.

Юбилей тантаналары Мамадыш шәһәре үзәгендә Шәйхи Маннурның яңартылган һәйкәле каршындагы мәйданда шигърият бәйрәме белән башланып китте. Аны кереш сүз белән район хакимияте башлыгы Фарук Ислам улы Идиатуллин ачты. Аннары ул Ш.Маннур исемендәге бүләкнең быелгы ияләре - Көмеш Күл мәктәбенең VI нчы сыйныф укучысы, инде үзенең беренче китапчыгын чыгарырга өлгергән Ләйсән Могтәсимова белән Мамадышта туып үскән шагыйрь һәм тәрҗемәче Мансур Сафинга (Чаллы) истәлек дипломнарын тапшырды. Район хакиме мондый шигъри бәйрәмнең киләчәктә күркәм гадәткә әвереләчәгенә ышандырды.



● Язучы Г.Гыйльман Ш.Маннур рухына дога багышлады.

● "Чулпан" күмәк хуҗалыгының хезмәт алдынгылары Р.Вәлиев, Г.Мусин һәм Х.Шәнгәрәева якташлары исемен йөртүче бүләкнең быелгы ияләре булдылар.

Соңыннан бәйрәм кунаклары әдипнең туган авылына юнәлделәр. Иң әүвәл Тулбай авылы зиратында Ш.Маннур каберенә чәчәкләр салынды. Аннары әдәбият һәм сәнгать әһелләре шагыйрьнең музей-китапханәсенә уздылар, бакча-мәктәп комплексы балалары башкаруында Ш.Маннурның "Каз көтүче малай" исемле әкияте буенча куелган спектакль карадылар, Дусай авылында әдип укыган элекке мәдрәсәнең яңартылган бинасы (хәзер анда башлангыч мәктәп) белән таныштылар, Олыяз авыл хуҗалыгы лицеенда булдылар.

● Әдипнең туган көне - безнең туй көне.

Кичен Олыяз авылы мәдәният сараенда Шәйхи Маннур юбилеена багышланган әдәби-музыкаль кичә булды. Аның беренче өлешендә "Чулпан" күмәк хуҗалыгының хезмәт алдынгылары - сыер савучы Хәдичәбикә Шәнгәрәева, механизатор Габделхәй Мусин һәм шофер Равил Вәлиевкә якташлары исемен йөртүче бүләкләр тапшырылды. Казаннан килгән каләм әһелләренең чыгышларын авыл үзешчәннәренең җыр-моң, биюләре дәвам иттерде.

Мамадыш якларында Шәйхи Маннур рухы чын мәгънәсендә яши. Якташлары аның белән хаклы рәвештә горурланалар. Бу бәрәкәтле төбәктә әледән-әле яшь талантлар ачыла. Гомумән, районда мәдәният тормышы гөрләп тора. Мамадышлар хезмәттә дә сынатмыйлар. Бу җәһәттән "Чулпан" авыл хуҗалыгы кооперативлары ассоциациясе рәисе Револь Гыйззәтуллин, җирле үзидарә рәисе Азат Һадиев, шулай ук район хакимияте башлыгы урынбасары Шамил Хәсәнов кебек фидакарь затларга Шәйхи Маннур мәдәният учагын балкытып тотулары өчен аерым рәвештә рәхмәт белдерер иде шикелле.

● Тулбай бакча-мәктәбенең I-III нче сыйныф укучылары Ш.Маннурның әкиятен уйнап күрсәттеләр.

Мидхәт ШАКИРҖАНОВ фотолары.

Хикәяләр бәйгесе

Гасыр башы — гасыр азагы

Әнкәем - Шәйхетдин кызы Закирәнең якты рухына багышлыйм.
Автор.

Закирә тирәге

Эльмира ШӘРИФУЛЛИНА

Йә Хода! Нинди Алла каргаган төн булды соң бу? Сиринә ишек алларында әтисе белән тагын очрашты. Ул, күрәсең, яңа гына кайтып кергән, ындыр капкасы буенда басып тора иде. Әтисе аңа дөньядагы иң әшәке, иң намуссыз кеше, иң явыз кеше булып күренде. Зөләйха чиннегендә мышный-мышный сөю сүзләре яудырып ятуы, хәзер исә берни булмагандай, шат-кәефле тавыш белән:

- Киноданмы, кызым? - дип эндәшүе Сиринәне бөтенләй чыгырыннан чыгарды. Ул, бугазына таш булып утырган нәфрәт сүзләрен йотып, атылган ядрә кебек, өйгә томырылды. Мендәренә капланды. Әле генә булган вакыйга күз алдыннан йөгереп үтте.

Алар Айдар белән иде. Артларыннан җырлап килеп чыккан Тәкыйның күзенә чалынмас өчен, бәрәңге бакчасына сикерделәр, каралты ышыгына сыендылар. Шулчак Сиринә өчен "җир упты". Ул, әтисенең тавышын ишетеп, иманеп китте. Исәнгерәп, ниндидер караңгылыкка чумды.

- Кума, зинһар... яратам мин сине...

Кыз колакларына ышанмаска теләде, сәерсенеп, тавыш килгән якка сөзеп карады. Сөйләшү чиннек эчендә иде. Ярым пышылдап, ярым югалып, өзек-өзек ишетелгән тавышлар аның бөтен көчен, хәлен алды.

- Балалар үсә бит...алардан оят... - диде хатын-кыз тавышы.

- Яратам... килмичә түзә алмыйм, Зөләйха!.. Синең белән очрашмасам... Балалар өчен дә... кеше түгел мин...

Сиринә тәмам коелып төште. Аны кимсенү, әрнү, көнләшү, тагын әллә нинди хисләр биләде. Кочагына алып басып торган егете янында үзен гаепле сизде.

Айдар бирeдән тизрәк китәргә кирәклеген аңлады булса кирәк, ашыгып ишарә ясады. Кыз, тере мәет кебек, аңа буйсынды. Аларның аяк асларында шартлап сынган агач чиннек тәрәзәсен шакыды. Кулларын кычыткан өтте. Кайдадыр эт өрде.- Алар, коймадан ничек керсәләр шулай чыгып, тыкрык буйлап киттеләр.

Сиринәнең аяклары таш таккандай авыр, ә гәүдәсе, әйтерсең, үзенеке түгел. Ул Айдарның сүзләрен ишетми, аңа җавап та кайтармый, үзе һичбернәрсә уйлый алмый бара да бара. Айдар да Сиринәне ничек итеп юатырга, сүзне кай тарафка борып җибәрергә белми аптырый.

Дөресен генә әйткәндә, бу тойгыларның, бу вакыйганың чын асылын ул үзе дә аңламый. Билгеле, авыл гайбәтчеләреннән төрлесен ишеткәне бар аның, Сиринә әтисенең "чирттерүе" турында. Әмма Зөләйха ханымның һәркемгә кирәкле табибә булуы, Сиринә әнисенең үзен бик тыныч, көләч тотуы - гайбәтләргә үрчеп китәргә җирлек бирми иде.

Шулчак кыз, тыела алмыйча, эчке бер сулкылдау белән такмаклый башлады:

- Ичмасам, үз колакларым белән ишетмәсәм... Каян гына килеп чыкты соң шул тәбәнәк Тәкый?..

- Кич җиттисә, Зөләйха тыкрыгында бит инде ул, - диде Айдар. - Мулла бабай димләп тә караган үзләрен. Тегесе һаман ялындыра, имеш.

Айдар Сиринәне күкрәгенә кысты, тынычландырырга теләде. Әмма Сиринә һаман үксепүксеп елый, үзен кая куярга белми бәргәләнә иде. Бервакыт үзалдына туңа, дерелди үк башлады.

- Сиринә, - диде Айдар, кинәт кенә нидер исенә төшкәндәй, кызны җилкәсеннән кагып. - Мин сине бер җиргә алып барам.

- Кая?

- Изге урынга. Яңа гына кавышканнар да, мәхәббәттә уңышсызлыкка очраганнар да элек гел шунда йөргән. Һәркайсы үзенә саф, тигез мәхәббәт сораган. Яхшы кешеләрнең теләге кабул булган.

- Теләк белән генә булса икән? Әнием биш вакыт намазын калдырмыйча Аллага сыгына да бит...

- Әйткән иде диярсең, синең теләгең кабул булачак, Сиринә.

Алар кайту ягына борылдылар.

Шул көннән башлап, Сиринә беркая чыкмады. Әтисе белән бер табынга утырып ашамады. Аның белән очрашмаска тырышты. Хәтта киләчәктә аңа "әти" дип эндәшә алуына шикләнде.

Сиринәнең эчке дөньясын актарып ташлаган сәбәпне әтисе дә, әнисе дә сизенде. Солтания ханым, кызының ашаудан калуын күреп, чирләп китмәсен, дип курыкты. Серне уртага салып сөйләшергә һаман җае табылмый. Тик торганда гына сүз башласа, ишекне шакымый кергән сөмсез кеше кебек, кызының күңелен кырырмын дип тыелды. Ә бер көнне сәбәп үзеннән-үзе килеп чыкты.

Баскыч башында гөрләшеп уйнап утырган балалар кинәт шаулаша башлады. Солтания, ни булды икән, дип ашыгып килеп чыкканда Сиринә Зөләйханың кызын куып капкадан чыгып бара, үзе:

- Әле син шулаймы? Безнең әти сезнең туганыгызмы? - дип сөрән сала. Кулындагы таягы белән кизәнә.

Ул кызын куып җитмәкче, эндәшеп туктатмакчы булып карады. Тик кая ул?! Чыгымлап чапкан тайдай ак-караны күрми йөгергән Сиринәне туктатырлык көч юк иде. Шул вакытта ул, нәрсәгәдер абынып, шапылдап җиргә ауды. Ах Аллам, күрәчәгенә җилкенгән икән, бөтен йөзен җимергәндер, дип уйлады ана, җирдән тормый яткан кызы янына иелеп. Ләкин, ни хикмәт, сыдырылмаган да иде Сиринә. Әмма җаны канга баткан булып чыкты кызның. Ул чәбәләнә, әнисен мәсхәрәләүчеләрдән үч ала алмавына хурлана иде.

Башы иелеп, җилкәләре төшеп басып торган кызы канаты каерылган кошны хәтерләтте Солтаниягә. Ана, үз ярасының бала күңелендә бермә-бер тирәнрәк җәрәхәткә әйләнүен күреп, өнсез калды. Ул бүген үк, менә хәзер үк кызын бу газаплардан арындырырга кирәклеген аңлады.

- Тынычлан, кызым, өйгә кайтып юын да, утырып сөйләшик, - диде.

Сиринә кайтып җиткәнне көтмәде:

- Әни, нигә дип ияләндерәсең шул Зөләйха балаларын? - дип сорау бирде.

- Алар синең туганнарың янына килә бит, кызым. Бергә укыйлар, бергә уйныйлар, - диде Солтания.

- Башкалар белән уйнасыннар. Ә безнең ихатага аяк басмасыннар, - диде Сиринә ачу белән.

- Алай ярамый, кызым. Ишек алды зур бит, уйнасыннар.

- Аларга әллә нинди "ярамыйлар" ярый. Икенче килсәләр, үзен дә, энесен дә кыйныйм! - диде Сиринә, катгый итеп.

- Үксезләргә кул күтәрә күрмә. Болай да әтисез үсәләр. Дөньялары китек.

- Бер дә китек түгел, безнең әтине үзләренең туганнары дип саныйлар. Әти дә, алар килсә, шатлыгыннан нишләргә белми, туктаусыз башларыннан сыйпап йөри. Алар әтисез калганга без гаеплеме әллә?..

Солтания бер мәлгә сүзсез калды. Аннан:

- Без дә гаепле, - диде тавышын әкренәйтеп. - Зөләйха иренең үлемендә әтиеңнең абыйсы гаепле. Төрмәгә утыртса да була иде. Әмма, әтиең һаман барып, булышып йөргәч, судка бирмәде, - дип өстәде.

Сиринә Зөләйха иренең, трактор арбасы авып, йөк астында калуын ишетте. Әмма бу фаҗигадә кем гаепле - нечкәләп белми. Әтисе күңелендәге мәхәббәт хисенең дә нәк шул "булышып" йөрүләр вакытында кабынуы аның өчен караңгы иде. Ләкин бер нәрсә ачык - "мәхәббәт геройлары" әнисенең сабырлыгыннан усалларча файдалана.

Шулай итеп, әтисенең "уҗымга чыгуын" әнисе никадәр генә яшерергә тырышса да - без капчыкта ятмады. Дөресен генә әйткәндә, Солтания бу хәл белән үзе дә озак кына килешә алмады. Иренең Зөләйхага ярдәмләшеп кенә йөрмәвен белгәч, күңелендә туган өермә әллә нинди каршылыклы фикерләр уятты. Үзен Зөләйха урынына куеп карады. Яшь, чибәр хатынның иң дәртле еллары ялгыз үтүен күреп кызганды, аны аклады. Икенче караганда, бүген өйләнергә әзер торган буйдак Тәкый сораткан чагында кеше иренә алданып, гомерен зая үткәрүе өчен гаепләде. Тәкый яратмаслык егет түгел. Эшчән, күндәм. Хуҗалыгын гөл итеп тотар, үзе дә ирле хатын булып яшәр иде, дип уйлады. Аннан тагын: "Җаны теләгән - елан ите ашаган", - диләр шул, күңеле тартмыйдыр, дип, бу фаразларын да эченә йотты. Айлар гына түгел, еллар үтте. Тора-бара Солтания ачы язмышы белән килеште. Ирен үз иркенә куйды. Бөтенләй үк юлдан язган бәндә түгел бит әле, акылына килер, дип өметләнде.

Ире дә җәмәгатенең йөрәге урынында түгеллеген сизә, ләкин сер бирмәвен, алай гына да түгел, кеше алдында, киресенчә, күңеллерәк булырга, үзен бәхетле итеп күрсәтергә тырышуын күреп сөенә иде. Шуңа күрә дә ул хатынына тагын да мәрхәмәтлерәк, игътибарлырак була барды. Тик мондый "яхшылыклар"ның балалары күңелендә нинди гарасат кузгатасын, керсез йөрәкләрен челпәрәмә китереп чәрдәклисен алдан күрә белмәде.

Ана белән кыз өйләренә якынлашып килгәндә, җир астыннан үсеп чыккандай, Айдар пәйда булды.

- Исәнмесез, - диде ул, атна буе күрешалмаган кадерлесен очратуына шатланып. Аннан бер - Сиринәгә, бер - аның әнисенә карап, тотлыгып калды. Солтания, яшьләрне аңлап, алга атлады.

- Сиринә, теге изге тирәк турында әбиемнән тагын бер кат җентекләп сөйләттем, - диде ул, ашыгыч хәбәр җиткергәндәй. Айдарның күзләре очкынланып яна. Гүя ул аны бу газаплардан бүген үк коткарырга тели.

- Мин ышанмыйм андый әкиятләргә, - диде Сиринә, салкын гына.

- Син нәрсә, Сиринә? Нинди әкият булсын? Кеше күңелендә иман беткәнгә күрә генә онытканнар ул тирәкләрне! Кыз егетенең хәтерен калдырганын тойды. Тизрәк сорап куйды:

- Кайда дидең әле син аларны?

- Суның аргы ягында. Иске авыл урынында, - диде Айдар, җанланып китеп. - Әбием яхшы хәтерли ул турыда. Теләсәң, әбием янына үзеңне дә алып барам. Закир бабайга бишенче буын онык та тиеш әле ул. Шәҗәрәбез дә бар.

Айдар әбисе сөйләгән истәлекләргә күчте.

...Әнием дә тумаган бер вакытта, авылларында пәһлуандай батыр егет белән сусылудай матур кыз яшәгән. Батыр егетнең исеме - Закир, сылу кызның исеме - Закирә икән. Закир белән Закирә кавышып бергә тора башлаганнар. Һәм, беренче көнне үк, түр бакчаларына чыгып, пар тирәк утыртканнар. Ир белән хатын картая барган саен, агачлар яшәрә, югарырак үрмәли, ныгый икән. Алай гына да түгел, егет утырткан тирәк кыз утырткан тирәкне бер ботагы белән әйләндереп алып - кочаклап үсә башлаган. Халык бу тамашага хәйран калган. Гомер буе тату, үрнәк булып чөкердәшеп яшәгән Закир белән Закирәнең чын мәхәббәтләре чагылышы дип бәяләгән. Үзләре исән чагында ук олы мәхәббәтләренә Табигать һәйкәл куйды, изге кеше булганнар икән, дип нәтиҗә ясаган.

Җилләр искән, еллар үткән. Авыл кечерәйгән. Закир белән Закирә яшәгән урам да беткән. Ә алар утырткан тирәкләр кочаклашып һаман яши. Кешеләр ул урынга олылап карый башлаган. Мәхәббәттә бәлагә юлыксалар, куш тирәк янына килеп хәсрәтләрен сөйлиләр, Ходайга ялваралар, ярдәм итүен үтенәләр икән.

Тагын еллар үткән. Вакыт елгасы авылда берничә генә булып калган өйләрне дә алып киткән. Закир-Закирә тирәген дә кыскартып, "Закирә тирәге", "Закирә аланы" дип кенә йөри башлаганнар. Тора-бара бөтенләй онытканнар.

- Ходайның хикмәте, ул тирәдәге үлән көз көне дә саргаймый иде, бер-бер сере бар инде аның! - дип йомгаклаган әбисе үзенең сүзен.

Сөйләп бетергәч, Айдар Сиринәгә сораулы караш ташлады. Кыз күңелендә сәер бер битарафлык хөкем сөрә иде.

- Әнигә әйтеп карыйк, рөхсәт итсә, барырбыз, - диде ул, бигүк сикереп төшмичә генә.

Алар, өйгә кереп, Солтания ханымга серләрен ачтылар. Үз кичерешләренә бирелгән ана бер тын эндәшә алмый торды. Якты хыяллар белән башланган яшьлегенең сизелмичә дә узып китүе, кайчандыр дөрләп кабынган кайнар мәхәббәтенең бүгенге көндә, пыскып утырган кисәү кебек, берсенә дә җылы бирмәве бәгырен телгәләде. Инде менә балалары ярдәменә мохтаҗ булып, алар алдында мескенләнеп, җебеп басып тору - аны ничектер түбәнсетте. Эчендәге бөтен үкенечләрен чыгарып ташлар өчен иңрәп-иңрәп кычкырасы килде. Ирен вакытында кулга ала алмавы өчен үзен үзе гаепләде. Шулай да, текәлеп карап торган кызы белән Айдарга:

- Юынып, чистарынып барыгыз, - дип фатихасын бирде.

Менә, алар алдында - Закирә аланы. Алан - тирән йокыда. Бөтен тирә-юньгә таралган тәмле дә, татлы да бөтнек исенә чумып, изрәп ята. Кайдадыр кошмы, җәнлекме кычкыра. Елга аръягында беренче әтәчләр тавыш бирә.

Таң сызыла. Дымык та, тыныч та төнне ямьләп, яктылык нуры күтәрелә. Закирә тирәге янында ак намазлык өстенә чүккән пар гәүдә күренә. Ботакта ике тәкыя эленеп тора. Әйләнә-тирәнең иң матур чәчәкләрен җыеп үрелгән бу пар балдаклар Сиринә белән Айдарның теләк-үтенечен дәвам итә. Аларның әти-әнисенә күркәм мәхәббәт сорап дога укый иде!

Сәхнә биеклегендә калу

"Кәмитче"дән Галилейга кадәр

Татарстанның халык артисты, Әлмәт театрының күренекле, олы шәхесе Әгъзам Кәрим улы ГАЛИУЛЛИНга, әгәр исән булса, 75 яшь тулыр иде.

Бөтен гомерен театр сәнгатенә багышлаган артист үзенең истәлекләрен болай дип башлый: "Мин 1924 елда Казан шәһәрендә тудым. Театр - балачактан ук минем уемда, хыялымда иде. Мин Академия театры урамында үстем. Көндезләрен театрга качып кереп, урындык астына посып утыра идем дә, кичке спектакльләр башлануын көтә идем. Чөнки әти-әнисез, әби белән генә үстем, акча табар урын юк иде".

Соңыннан, ул Казанның 18 нче мәктәбендә укыганда Татар дәүләт академия театры, бу мәктәпне шефлыкка алып, спектакльләр күрсәтергә еш килә торган була. Шул вакытларда караган спектакльләр яшүсмер малайда зур кызыксыну уята.

1945 елдан 1947 елга кадәр Әгъзам Галиуллин Яшел Үзән шәһәрендәге 3 нче фанер заводында эшли. Шунда Серго исемендәге мәдәният сараена, Д.Гомәров җитәкчелек иткән драмтүгәрәккә йөри башлый. Анда М.Әмирнең "Көнлекче Әхмәт һәм аның матур хатыны Мәрьям"дә Мулла, М.Әблиевнең "Шәмсекамәр"ендә Сукыр Суфый рольләрен башкара. 1947 елның маенда Яшел Үзән шәһәренең мәдәният йорты үзешчәннәре Казанга смотрга килә. Фанера заводы эшчесе Әгъзам Галиуллин берүзе "Чаткылар"да урядник, староста һәм карчык рольләрен башкара. Шунда аны Мамадыш театрының директоры Юныс Фарсин күреп, Мамадыш колхоз-совхоз театрына эшкә чакыра. Ике ел (1947-1949) ул шунда эшли. Анда башкарган иң беренче роле Риза Ишморатның "Якты юл" исемле әсәрендә 70 яшьлек Рәхимҗан карт образы була. 22 яшьлек артист картлар ролендә уңышлы чыгыш ясый, һәм аңа У.Гаҗибәковның "Аршин мал алан" музыкаль әсәреннән хезмәтче *Вәли образын ышанып тапшыралар.* Монда аңа музыкаль сәләте дә, вокал мөмкинлекләре дә, биюгә һәвәслеге дә, хәрәкәтчәнлеге, актерлык осталыгы да - барлык сыйфатлары да ярдәмгә килә. Аның комиклык сәләте ачыла. 1949 елны Мамадыш колхоз-совхоз драма театры ябылганнан соң, Ә.Галиуллинны яңа оешып килә торган Әлмәт драма театрына чакыралар һәм ул гомеренең соңгы көннәренә - 1976 елга кадәр шул театрда хезмәт итә, аның иң күренекле, иң талантлы артистларыннан берсенә әверелә.

"Актерлык осталыгын үстерергә ярдәм иткән рольләремне язып китмичә булдыра алмыйм, - дип дәвам итә Ә.Галиуллин. - Комик рольләр уйнарга һәвәс идем. 1950 елны "Тальян гармун" музыкаль комедиясендә хисапчы Куян Галәви образын тудырдым. Ул образны әлеге көндә дә искә алалар һәм мине бик озак Куян Галәви дип атап йөрттеләр. 1952 елны безнең театрга Сәет ага Булатов килде. Ул А.Арбузовның "Яшьлек белән очрашу" пьесасын куйды. Миңа анда иң җаваплы роль - Максим Голубкин роле тапшырылды. Миңа, театр мәктәбен үтмәгән кешегә, Сәет ага белән эшләве башта бик авыр тоелды. Хәзер инде күп еллар үткәч: "Менә кая икән ул чын режиссер-педагог! Алтын кеше!" - дип аны искә төшерәм. Максим Голубкин образын халык бик яратып кабул итте. Репетиция вакытында Максим белән Мушкинаның аңлашу, элеккеләрне искә алу күренешендә күземнән яшь чыкканын һәм җылап җибәргәнемне хәтерлим. Сәет ага мине тынычландырып: "Менә шул кирәк тә миңа, йөрәге кузгалмаган кеше артист буламыни?!" - дип куйды. 1953 елны А.Афиногеновның "Машенька"сын Т.Кичүбаев куйды. Академик Окаемов образын зур авырлык белән тудырганым истә. Миңа 28 яшь, ә Окаемов 70тә. Җитмәсә, академик. Миңа, андый зур кешеләр белән аралашмаган артистка, башта аны аңлау авыр иде. Мин әле бу рольгә риза да булмыйча йөрдем. Ләкин китаплар укыштыргалап, китапханәләрдә энциклопедияләрдән танылган кешеләрне укыштырып, тартып-сузып "академик" булдым. Мәскәүдән килгән тәнкыйтьче Фридка бу образ бик ошады. Тамашачы да яратты аны. Дулкынлансам да спектакльне уңышлы башкарып чыктым".

Артистның сәхнә таланты ачылу табигый сәләтен чарлау белән бергә бара. Беренче рольләренең берсе - Ф.Бурнашның "Яшь йөрәкләр" драмасында ул гади авыл егете Сәйфулланың шәхес буларак формалашуын, холкын ача - йөгерек фикерле, зирәк, уенчак, хисчән, җор күңелле егетне артист бик оста тасвирлый. Режиссерлар аның табигый сәләтен, комик рольләргә хирыслыгын сиземләп, аңа бер-бер артлы шушы жанрдагы образларны ышанып тапшыра башлыйлар. "Җиңел сөякле" артист рольне дә җиңел башкара, әсәрнең эчке ритмын тоя, әйткән бер сүзе мәзәк булып яңгырый, һәр репликасы тамашачы күңеленә үтемле, тапкыр сүз булып килеп җитә, халык рәхәтләнеп көлә, ял итә. Шул ук вакытта образның мәгънәсенә дә хилафлык кылынмыйча, фикер ачыклыгы саклана. Ә.Галиуллинны халык яратып, "кәмитче" дип йөртә. Т.Гыйззәтнең "Чаткылар"ындагы Староста Дәүли, Г.Хугаевның "Хатынымның ире"ндәге Казбек, Т.Миңнуллинның "Диләфрүзгә дүрт кияү" комедиясендәге Хафиз, Ш.Камалның музыкаль водевиль жанрында куелган "Хаҗи әфәнде өйләнә" спектаклендәге Юныс хаҗи образлары Ә.Галиуллин башкаруында сәхнә шедеврлары буларак кабул ителә. Артист уенындагы темперамент, югары дәрәҗәдәге осталык, җиңеллек, уен-көлкедән тәм табып, җырлап, биеп, жонглерлык осталыгы күрсәтүе дә җәлеп итә, сокландыра тамашачыны. Аның Хаҗие да, Старостасы да үзенчәлекле бизәкләргә бай. Артистның тулы канлы образ тудыруда нинди алымнар кулланганлыгы турында бер язма бар: "... Бүлмәгә килеп керүләре, килеп кергәч, ни өчен чакырттылар икән, дип шүрләбрәк, бер үк вакытта нәрсәгәдер өметләнеп тирә-якка караулары, тырпайган мыеклы урядникны күргәч, кинәт сискәнеп китүләре, ашык-пошык мескен бүреген салып, алъяпкыч күкрәкчәсенә яшерүләре тамашачыны сагайта да, көлдерә дә.

Дәүли абзагызны дәрәҗәле кеше итәргә чакырганнар икән ләбаса. Дәүли, чамалап кына боргалангач, кирәгенчә генә кыстаткач, аякны аякка сугып староста булырга ризалык бирә. Кулай староста булырдай күренә Дәүли, күңелен күрергә, "кулга ияләштерергә" кирәк картлачны. Өстәлдәге шешәдән аңа да салып бирәләр. Мөселман кешегә хәмер эчүләре килешеп бетә торган нәрсә түгел дә, түрәләр шулай якын иткәч, ни чараң бар? "Әйләндереп каплый" Дәүли стаканны, закуска урынына мескен бүрек эчен исни. Янә салып биргәч, сагаеп каласың: туктале, артист әлеге мескен бүрекне тагын иснәрме икән? Юк, сәнгать бер үк нәрсәнең кабатлануын кичерми. Ә.Галиуллинның актерлык арсеналында башка, бер-берсенә охшамаган алымнар җитәрлек - бу юлы ул, хәмер йоткач, авызын алъяпкыч чабуы белән җиллэтә.

Юныс хаҗи исә бүтәнчәрәк чишелә. Монда да импровизация хакимлек итә. Аның Хаҗие, хаҗга барган динле сәүдәгәр, яшьләрдән калышмаска тырыша, яшь укытучы кызга өйләнергә карар кыла һәм заманча булам дип, аларча кыланырга тырыша һәм шуның белән бик нык көлкегә кала. Бу юлы инде базык гәүдәле, үз-үзенә нык ышанган, кирәк икән динен дә, денен дә сатарга әзер татар бае пәйда була".

Ул һәр рольдә диярлек чынлап "йөзә" иде. Шуклану, шаяру аңа бик килешә, ятышып тора иде. Аның Сафиулла карты сәхнәгә килеп керүгә тамашачылар ләззәтле елмая иде. Ферма кызларын "юлдан яздыручы" нефтьче егетләр хафасыннан дулый-дулый, сәхнәдән тамаша залына төшеп китүе мәзәк буларак кабул ителә, әмма артист шул чакны халык белән бер булып яши башлый кебек.

Драматург Риза Ишморат "Совет Татарстаны" гәзитендә (25/XI-1960 ел) Ә.Галиуллинның "Тальян моңы" комедиясендәге (Ш.Бикчурин) уены турында болай дип яза: "Театр артистлары пьесаның эчтәлеген тамашачыларга тулы җиткерү өчен зур иҗат көче куйганнар. Төп геройларның берсе булган Сафиулла карт ролен Әлмәт театрында инде күп еллар буе эшләп килә торган артист Әгъзам Галиуллин башкара. Бөтен йөрәге белән музыкага гашыйк булып та, үзенең тальян гармуны була торып та, иске дөньяның Котлы Әхмәт муллалар эзәрлекләве аркасында, гармун уйнарга өйрәнә алмый калган, хезмәт сөючән, намуслы һәм үзенә генә хас бик күп сыйфатлары булган бу карт образын ул оста иҗат иткән".

Комик пландагы рольләр арасында иң усаллары сатира жанрына карыйлар. Бу очракта да артист үзенең кыюлыгы белән аерылып тора, ул үзенең персонажларын үткен һәм зирәк итеп тасвирлый. Үзбәк драматургы Х.Ниязиның "Бай һәм хезмәтче" драмасында һәм Г.Мөсреповның казакъ халкы эпосына нигезләнеп язылган "Козы-Көрпеш һәм Баян-Сылу" романтик трагедиясендәге Салих бай һәм Карабай образлары бу нәүбәттән ачык мисал була алалар. Салих байның характерын артист каршылыклы алымнар аша үсештә күрсәтә. Аның бу герое сәхнәгә килеп керүгә үзенең тышкы чибәрлеге, буй-сыны белән күзнең явын ала. Аңа бер карауда ук гашыйк булырга да мөмкин. Тик вакыйгалар куера башлагач, аның каты бәгырьле, хәйләкәр, усал кеше икәнлеге ачыклана. Икенче образ Карабай да шулай ук ачык буяулар белән тасвирлана һәм фаҗигане тудыручыларның берсе буларак аерылып тора.

Шул ук вакытта Ә.Галиуллинга "җитди" рольләрдә дә чыгыш ясарга туры килә, аларда да ул үзен спектакльнең "кайнарлыгын", аның фикер куәтен иң югары ноктага күтәрә ала торган артист итеп таныта. А.Афиногеновның "Машенька"сында психологик нечкәлек белән чишелгән профессор Окаемовы, А.Островскийның "Гаепсездән гаеплеләр"ендәге меценат Дудкин, Т.Гыйззәтнең "Бишбүләк" әсәрендәге штабс-капитан Чингизов, "Утта янмас" бөек галим Галилео Галилей образлары Әлмәт, гомумән, татар театры тарихын бизи торган образлар. Соңгысы исә трагик югарылыкка күтәрелгән романтик рухлы җан иясенең йолдызлар дөньясына омтылуында нинди фаҗигале юл үтүен шигърият киңлегенә чыгарып тасвирлый алды.

Татарстанның халык артисты Әгъзам Галиуллин 1976 елда Әлмәт театры Башкортстанда гастрольләрдә йөргәндә вафат булды. Ул илаһи сәхнә җырчысы иде, аның җыры ярты тавышта өзелеп калды.

Дания ГЫЙМРАНОВА,
театр белгече.

Татарны моң яшәтә

Эзләнүләр, табышлар

Казанның Зур концерт залында Анатолий Шутиков җитәкчелегендәге Татарстан дәүләт халык уен кораллары оркестрының чыгышы булды.

Концерт ике премьерадан гыйбарәт иде. Анда Шамил Шәрифуллинның "Татар туй җырлары" кантатасы һәм Зөфәр Хәйруллинның курай өчен концерты оркестр башкаруында яңгырады.

Дөрес, Ш.Шәрифуллинның "Татар туй җырлары" кантатасы беренче тапкыр 1999 елның апрелендә мәдәният һәм сәнгать академиясенең Марат Яхъяев җитәкчелегендәге татар хоры тарафыннан башкарылган иде. Бу юлы әсәр беренче тапкыр оркестр белән уйналды. Шуңа күрә бу башкаруны премьера дип тә атарга мөмкин. Авторның кантатага нәкъ менә шул теманы сайлавы очраклы түгел. Композиторның иҗаты милли рухы, халыкчан төсмерләре белән сөендерә. Ул татар фольклорын бик тирәнтен өйрәнә һәм аның бу өлкәдәге эзләнүләре һәм табышлары байтак. Композитор балалар музыка мәктәпләре өчен махсус программа да төзеде.

Кантатаның тәэсирле хисе, шаян "Чикамыш", шагыйранә нәфис "Айни-кәрәм" һәм тантаналы "Яр-яр" өлешләре туй йоласының бәйрәмчә күтәренке халәтен ачык күрсәтәләр. Беренче өлештә композитор бөтен төрки халыкларга хас, борынгыдан килә торган җырлау традициясен чагылдыра. Мәсәлән, "Чикамыш" - керәшен татарларының туй җыры. Кантатаның икенче өлешендә якты һәм күңелне нечкәртә торган "Айни-кәрәм" - кәләшне озатканда кияү ягыннан ирләр җырлый торган җыр. Өченче өлешнең нигезе исә бөтен төрки халыкларының туй йолаларында очрый торган "Яр-яр" исемле олылау-данлау җыры тәшкил итә. Шул җыр бөтен циклны төгәлли. Кантата күтәренке рухлы, кайчакта гади һәм самими, ә иң мөһиме, оптимистик характерлы булуы белән күңелдә җылы, якты хисләр уята һәм үзенең тематикасы һәм көйләнеше белән аерылып тора.

Үзен "композитор-һәвәскәр" дип атаган Зөфәр Хәйруллинның оркестр башкаруында курай өчен язылган концерты Ш.Шәрифуллин кантатасына аваздаш. Автор - бүгенге көндә Татарстанда консерватория дипломы алган бердәнбер курайчы. Курай өчен оркестр белән башкарылган концерты исә - татар музыкасы тарихында әлегә бердәнбер. Курайның гаҗәеп аһәңнәрен, виртуоз мөмкинлекләрен күрсәтү теләге З.Хәйруллинны иҗатка илһамландырган. Яшьлек дәрте ташып торган бу әсәрне тыңлаучылар бик җылы кабул иттеләр. А.Луппов, Ш.Шәрифуллин кебек тәҗрибәле иҗатташ дусларының хуплавы да яшь композиторга канат куйды.

Наталья ТИТОВА.

Тамаша заллары чакыра

Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры

4 февраль - "Килә ява, килә ява" (З.Хәким).

5 февраль - "Җанкисәккәем" (Т.Миңнуллин).

6 февраль (көндез) - "Сөембикә егет сайлый" (Ф.Яруллин).

6 февраль (кич) - "Күрәзәче" (З.Хәким).

8 февраль - "Кылый Кирам балдагы" (Аманулла).

9 февраль - "Йөрәк маем" (Т.Миңнуллин).

10 февраль - "Гаугалы гаилә" (Э.Филиппо).

11 февраль - "Зәңгәр шәл" (К.Тинчурин).

12 февраль - "Биюче" (Л.Вега).

13 февраль (көндез) - "Беренче театр" (Г.Камал).

13 февраль (кич)) - "Шәҗәрә" (Т.Миңнуллин).

Кече зал

12 февраль - "Шомбай эшләпәсе" (Х.Җәләй).

13 февраль - "Карак песи" (Х.Фатыйхова, С.Латыйпов).

К.Тинчурин исемендәге Татар дәүләт драма һәм комедия театры

4 февраль - "Башмагым" (Т.Гыйззәт).

6 февраль (көндез) - "Син бит минем бергенәм" (И.Мәхмүтова).

6 февраль (кич) - "Гайфи бабай, өйләнә давай" (Г.Зәйнашева).

9 февраль - "Ак тәүбә, кара тәүбә" (Т.Миңнуллин).

10 февраль - "Карт гашыйк" (С.Шәкүров).

11 февраль - "Яңадан мәхәббәт турында" (Х.Бахит).

12 февраль - "Сүнгән йолдызлар" (К.Тинчурин).

13 февраль (көндез) - "Кияүләр" (Х.Вахит).

13 февраль (кич) - "Сынган беләзек" (Р.Сәгъди).

Г.Тукай исемендәге Татар дәүләт филармониясе (Зур концерт залы)

4 февраль - ТР дәүләт халык уен кораллары оркестры концерты. Борынгы романслар һәм халык җырлары кичәсе. Солистлар: Л.Иванова, В.Бака, М.Гужов, Л.Петрова.

5 февраль - ТР дәүләт симфоник оркестры концерты. Солист: Э.Моносзон. Дирижер Р.Җәләй.

6 февраль - Балалар абонементы N 2. Симфоник оркестр уйный. Яшь талантлар концерты.

6 февраль - Балалар абонементы N 4. Симфоник оркестр уйный. Яшь талантлар концерты.

11 февраль - Модерн-дуэт. Солистлар В.Мациевская (скрипка), Т.Печкаева (фортепиано).

12 февраль - ТР дәүләт симфоник оркестры концерты. Солист: А.Анчевская. Дирижер Ф.Мансуров.

13 февраль - Балалар абонементы N 6. ТР дәүләт симфоник оркестры уйный.

13 февраль - Балалар абонементы N 8. ТР дәүләт симфоник оркестры уйный.

13 февраль - Балалар абонементы N 17. Опера һәм камера музыкасы.

Татар дәүләт яшь тамашачы театры

4 февраль - "Дөреслекме бу?" (И.Булатова). Казандагы 3 нче гимназия.

9 февраль - "Дөреслекме бу?" (И.Булатова). Ленин исемендәге мәдәният сарае.

15 февраль - "Босния хатыннарына мәрсия" (Н.Араз). Сәетгалиев исемендәге мәдәният сарае.

22 февраль - "Сандугачлар килгән безгә" (И.Юзеев).

23 февраль - "Сандугачлар килгән безгә" (И.Юзеев).

Татар дәүләт "Әкият" курчак театры

4 февраль - "Кошкин дом" (С.Маршак).

5 февраль - "Пушок волшебник" (А.Попеску).

6 февраль - "Маленькая баба яга" (О.Прайслер).

11 февраль - "Кошкин дом" (С.Маршак).

13 февраль - "Невеста падишаха" (М.Гыйләҗев).

Цирк

4-13 февраль - Т.Дурова циркы артистлары Һиндстан филләре белән тамаша күрсәтә.

Әдипне юксыну

Кеше китә, әмма җыры кала...

Аңа быел 70 яшь тулган булыр иде... Йөзләгән студентларын галим һәм укытучы буларак сокландырып, меңләгән-миллионлаган укучыларын "Без - кырык беренче ел балалары", "Фронтовиклар", "Торналар төшкән җирдә", "Кеше китә, җыры кала", "Ут чәчәге", "Бәхилләшү", "Ачы тәҗрибә" кебек әсәрләре-китаплары белән куандырып һәм сискәндереп яшәде ул.

Хәтерлим әле, бервакыт (мин ул чакта "Казан утлары" журналында эшли идем) бүлмәмә Мөхәммәт абый килеп керде.

- Нияз, син университетта минем лекцияләргә йөрмәдең бугай, шулай бит? - диде.

- Шулай шул, Мөхәммәт абый, сезнең дәресләрне тыңлау насыйп булмады. Тик мин сезнең студентлар белән аралаша идем, алардан мин сез дәрестә әйткән һәр сүзне диярлек ишетеп-белеп тордым. Сез әйткәннәрне алар яттан беләләр иде, - кебегрәк сүз әйттем мин.

- Алай икән... - диде Мөхәммәт абый һәм шул чакта, ишектән-тәрәзәгә, тәрәзәдән ишеккә әрле-бирле йөреп, әдәбият хәлләре турында гыйбрәтле хәлләр сөйләде. Юк, сөйләмәде, мине тыңлаучы гына түгел, әңгәмәдәше итеп сөйләште ул. Игътибар иттем: төп-төгәл 80 минут чамасы барды бу сөйләшү (университетта, лекцияләр 80 минут бара). Мөхәммәт абый телдә мәгънәле усал, төртмәле һәм гадел. Тәнкыйтьне турыдан, ярып әйтә. Көнчелекне һәм наданлыкны җене сөйми. Урыс әдәбиятының "көмеш һәм алтын" чорларындагы һәм аннан соң туган иң яхшы әсәрләрен укымаган һәм белмәгән язучыларны-галимнәрне өнәми, эрудицияләре булмавы шуннан да килә, дип исәпли. Шул ук вакытта, талантлы-фикерле каләмдәшләренә, үзенең геройларына чын-чынлап мөкиббән киткән, гашыйк кеше иде ул. Үзенең тискәре геройларын да яратып сурәтли алган язучы иде. Моңа бары тик формаль логиканы гына түгел, ә тормыш логикасын тирән белгән, аңлаган-тойган язучы гына ирешә ала.

Сталин режимы вакытында кулга алынган әтисе өчен, ятимлек еллары өчен әрнүе-рәнҗүе зур иде Мөхәммәт абыйның. Шул "халык дошманы" улы булып күпме михнәтләр кичергәнен үз әсәрләрендә кат-кат сурәтләде ул. Әмма әдип бу михнәтләрен үзенеке итеп кенә түгел, халык бәгыренә, халык җанына төшкән афәт итеп сурәтләде.

Әнә шул рәнҗү, әнә шул әрнү аның уй сөрешен дә, телен-стилен дә шактый усал-саллы иткәндер. Юк, әдәби телдә Мөхәммәт абый - каләм остасы. Аның үз теле, язма һәм сөйләм теле гаҗәеп дәрәҗәдә бай, үзенчәлекле, халыкчан. Ә инде геройларының сөйләме - искиткеч. Характерларына ябышып-ятып тора.

Ул, әле үзе исән чакта, мондыйрак тәнкыйть сүзен ишетә килде: Мәһдиевнең әсәрләрендә сюжет юк, ул аерым-аерым вакыйгаларны тезеп кенә бара. Бу тәнкыйтьне "йомшартыбрак" кую өчен (чөнки Мөхәммәт абыйның әсәрләрендә ниндидер бер өр-яңа үзенчәлек төсмерен сизмичә кала алмыйлар иде), гадәттә, аның әсәрләрендәге катлаулы язмышларны, характерларны мактарга тырыштылар. Әмма бүген инде, аның әсәрләрен тулаем күзалласаң, аларда нәкъ менә киеренке сюжет җебе барлыгын, ул җепне авторның үз язмышы, якташлары һәм чордашларының катлаулы язмышы ялгап үреп торганын аңлыйсың. Аның язганнары документаль әсәр кебек. Әмма шушы документальлекне чын мәгънәсендә әдәби югарылыкка күтәргән, хәтта автобиографик әсәрләрендә дә шул әдәби сурәтләү югарылыгыннан төшмәгән, психологик кичерешләрне тирәнтен тойган, үз каләмен үз геройлары характеры, холкы-фигыле эзеннән "ияртә" белгән зур язучы, зур талант иясе иде Мөхәммәт абый Мәһдиев.

Ә теге вакытта, миңа 80 минутлык лекция укыган чагында, Мөхәммәт абый соңыннан ирен чите белән генә көрсенеп-көлебрәк әйткән иде:

- Менә, энем, миңа да мемуарлар язар вакыт җитте бугай, - дигән иде. "Ачы тәҗрибә" дигән әсәреннән өзекләрне өстәлемә шул сүзләрен әйтеп салган иде ул. Миңа Мөхәммәт абыйның "Бәхилләшү" повестен да укып-редакцияләргә насыйп булган иде. Ул үз әсәрен редакцияләгән кешеләргә бик таләпчән булды, "минминлеге" белән түгел, үзе язганнарга таләпчән булуы белән бәйле иде аның бу "сәер" холкы. Әмма, минем бәхетемдер, без Мөхәммәт абый белән һичбер "үпкәләшүсез" эшләдек. Ул миңа "лекцияләрне" үз әсәрләре аша да бирде.

Шулай да, Мөхәммәт абыйга минем бер үпкәм бар. Гел көтмәгәндә-уйламаганда дигәндәй, безне калдырды да китеп барды ул. Күпме язылмаган һәм язачак әсәрләрен үзе белән алып китте. "Кеше китә, җыры кала", дип әйтте дә, япь-яшь килеш китте дә барды. Шуңа үпкәләвем... Аның сарказм һәм юмор белән тулы, рәнҗү һәм әрнү белән тулы әсәрләрен кат-кат кайтып укыйм да, татар әдәбиятында бүген нәкъ менә Мөхәммәт Мәһдиев каләме җитенкерәмәвен тагын бер кат тоям.

"Ачы тәҗрибә", дигәннән. Нәкъ менә шул хакта без Мөхәммәт абыйның гаиләсенә мөрәҗәгать иттек. Аның кызы Гәүһәр ханым шул әсәрдән - язылып төгәлләнмәгән әсәрдән безгә бер өзек алып килде. Мөхәммәт абый бу язмасын-кулъязмасын - "Кырык беренче ел балалары елый..." дип атаган. Нигә алай дип язды икән?..

Нияз АКМАЛ.

● М.Мәһдиев Алабуга педагогия институтының актлар залында чыгыш ясый. 1971 ел.

Кырык беренче ел балалары елый...

...Аңа кадәр минем "Без - кырык беренче ел балалары" повестенең русча тәрҗемәсе чыгу тарихын сөйлисем бар әле. Бу - шулай ук гыйбрәтле хәл.

Бу эш болай булды. Рус телендәге "Чаян"ны алып карасам, анда минем юмористик хикәяне басканнар. "Перевод Э.С." дип куелган. Көтелмәгән хәл. Безнең эштә татарча ник тетралогия чыгармыйсың шунда, белүче юк, ә русча бармак башы кадәр әсәрең чыкса, киләләр, күрешәләр, кул кысалар. Университеттагы рус галимнәренең мин шул сыйфатын ихтирам итәм. Безнең татар, берәр әсәрең чыкканны күрсә, кара яна, дошман була. Мин шат идем һәм Э.С.ны эзләп таптым. Нәшриятта редактор икән. Аңа "Атадан бала яшь кала" дигән китапчыгымны бүләк иттем. Ул андагы повесть - "Без - кырык беренче ел балалары" белән кызыксынды.

- Мин моны тәрҗемә итә алам, - диде.

- Чыгаруы кыен булыр бит, - дидем.

- Анысын да үз өстемә алам. Шамил Рәкыйпов белән сөйләшәм.

Миңа нәрсә! Чыгаруын үз өстемә алам, ди бит. Тәрҗемә процессы башланды. Бер укыйм тәрҗемәне, ике укыйм, өч укыйм - юк, барып чыкмый. Гел төзәтәм. Ниһаять, "әйдә, ярар инде, черт с ним" дигән бөек принциптан чыгып риза булам. Ләкин соңгы вариантны миңа укытмыйча нәшриятка тапшырмыйсың, дидем.

Бер көнне өйдә телефон шалтырый. Марс Шабаев.

- Срочно нәшриятка килеп чык әле, - ди.

Килсәм - өстәлендә Э.С.ның тәрҗемәсе. Әзер.

- Моны кем тәрҗемә итте? - ди Марс Шабай.

- Э.С.

- Ә монысы кем?

Кулъязмага "перевод с татарского Р.И. и Э.С." дип куелган иде.

- Мин бу кешене белмим.

- Мин беләм, ул - аның ире.

- Шулаймыни?

- Син аның белән эшләдеңме?

- Күргәнем дә юк.

- Сез договорны кем белән төзедегез?

- Э.С.белән.

- Давай-ка, син аңлатма яз әле...

Идриттри... Әсәр язам - аңлатма язам. Әсәр язам - аңлатма. Нигә барысы да миңа?

Яздым. "Р.И.дигән кеше белән үз гомеремдә очрашканым юк", дидем.

Икенче көнне нәшриятта, директор секретаре Сәлимә янында юан гына, авыруларча таза берәү миңа дәште.

- Мин, - диде, - Р.И. булам. Слушай, ник инде тышлыктан минем фамилияне сыздырасың? Мин дә бит эшләштем. Кара инде син, анда синең Әлтафи дигән героең "падла" дип сүгенә тәрҗемәдә. Шәп бит! Аны Э. каян белсен! Ул бит бик культуралы семьядан! "Падла" - минеке...

Күреп торам - авыру. Марс янына кердем. Әллә, дим, риза булыйммы?

- Риза булсаң шул: И. бүген үк, Союзга әгъза итеп алыгыз, дип, икенче этажга заявление белән төшеп китәчәк... Графоман..

Мин ике ут арасында калдым. Тәрҗемәне тагын укып чыктым - бик начар иде. Тагын бер кәгазь яздым. "Мондый тәрҗемәгә мин риза түгел", дидем.

Ниһаять, мине директор Гарәф Шәрәфетдинов чакыртты. Мин әлегә аның белән таныш түгел. Ул, әллә кайчангы дуслар кебек, болай диде:

- Р.тан баш тартуың дөрес. Ул тәрҗемәче түгел. Авыру кеше. Әмма Э.ны батырмыйк. Көч куйган бит. Гаиләсенә ярдәм булыр, ире дә авыру. Әйбәт хезмәткәр.

Мин риза булдым, тик корректурасын гына миңа укытырсыз, дидем. Икенче көнне мин Коктебельгә иҗат йортына китәсе идем.

Аэропортка китәргә ярты сәгать кала - телефон. Э.С.

- Мөхәммәт! Мин автоматтан. Үтенеп сорыйм, Р.ның исемен калдырыйк. (Елый). Хочешь, менә хәзер будка эчендә тезләнеп сорыйм! Зинһар!

Мин ярты сәгатьтән юлга чыгасымны әйттем.

Ул тагын да кызды:

- Хәзер такси алам да өегезгә киләм. Тезләнеп... сорыйм: (Елый). Үтермә Р.ны! Үтермә! Ул - үләчәк...

Мин бер генә җөмләмне хәтерлим:

- Ах, ире өчен тырышкан хатыннар җир йөзендә күбрәк булса иде...

Мин риза булмадым. Шул елны Р. үлде. Китапның корректурасын миңа күрсәтеп тормадылар. Чыккач кына күрдем. Анда хаталар байтак иде. Озак та үтми, И.Ахунҗановның "Советская Татария"дә "Автора надо уважать" дигән мәкаләсе чыкты. Ул рецензиядән соң Э.озак срок белән больницага кереп ятты.

Менә шулай итеп, без Э. белән һәм редактор Л.Жаркова белән очрашканда исәнләшмичә гомер кичерәбез...

Батулла баганасы

Ялындыру

Фатыйма Ильская бер генә режиссерны да санламаган, диләр. Бөтен театр аның ихтыярыңа буйсына икән. Ләкин, ни холыксыз булса да, Ильская Кәрим Тинчура белән беркайчан да телгә килмәгән. Иртәгә премьера уйналасы көнне Фатыйма ханым:

- Уф, башым авырта, иртәгә мин уйный алмам, ахрысы. Спектакльне күчерегез! - дип, артистлар күңеленә шом сала.

Директор, администратор, артистлар, режиссерлар, вахтерлар, каравылчылар Фатыйма ханым янына килеп ялына башлыйлар:

- Харап итмә, билетлер сатылып беткән! - диләр.

Юк! Фатыйма ханым уйнаудан баш тарта.

Шуннан соң Кәрим Тинчура Фатыйма ханымның өенә китә.

- Юк-юк, Кәрим абзый, мин уйный алмыйм, кәефем юк! - дип чат каршы тора артистка.

Кәрим дәшми, Фатыйма ханымның чәпчегәнен байтак кына тыңлап утыра да әйтеп куя:

- Ярар, Фатыйма ханым. Алай хәлегез бик авыр булса, уйнамассыз. Ләкин спектакльне өзәргә ярамый. Шуңа күрә башка берәр артистканы әзерләрмен. Сезнең репетицияләрне баштанаяк караучылар бар анда. Галия ханым Булат та рольне тиз ала...

- Ю-ук, юк! - дип кычкыра Фатыйма ханым. - Үзем уйныйм. Аларга бирәмме соң мин үз ролемне! Үзем уйныйм!

Шулай итеп, спектакль өзелми кала.

Сөендерү

Ачлыкка чыдый алмыйча, Кәрим Тинчура татар театрын Ташкентка алып китә. Барып җитүгә үк Кәрим бөй тиф белән авырый башлый. Тәне кызышып, урынга егыла. Нәкъ шул көннәрне татар артистлары ачлар файдасына "Таһир-Зөһрә"не уйнарга тиеш була. Тинчура янында утырып, карап, ярдәм итеп торыр өчен бер шәфкать туташын яллыйлар. Артистлар уйнап кайталар. Кыз чыгып китә. Кәрим артистларны ачулана башлый:

- Нигә сез мине шушындый мәгънәсез кешегә калдырып киттегез? Мине үтерәсегез киләмени? - ди.

- Саташа бугай! - диләр артистлар.

- Саташмыйм! - дип кычкыра Кәрим. - Бу кыз монда кич буе тифтан үлгәннәр турында тәфсилләп сөйләп утырды. Сез фәлән кешене беләсезме? ди. Беләм, дим. Ул да кичә тифтан үлде. Сез төгән кешене беләсезме? ди. Беләм дим. Ул да тифтан гүр иясе булды. Теге кешене белә идегезме? ди. Юк, дим, белмим. Ул да тифтан аяк сузды, ди. Ул да сезнең кебек тифтан үлде, дип теңкәмә тиде. Шулай итеп, Кәрим Тинчура тифтан чак кына үлми кала.

Көлсәң – көл, көлмәсәң – ела!

Казалы тел

(Памфлет)

Татарларыбызны әйтәм әле, нигәдер тынып калдылар бу араларда, "Милләтле паспорт!", "милләтле паспорт!" - дип чәпчемиләр. Тиздән Русиядә булачак Президент сайлаулары куркыттымы үзләрен, әллә башка сәбәпләре дә бармы?

Әнә, яһүдләр, Гитлер белән Сталин каһәреннән милләтләрен яшереп, исемнәрен үзгәртеп кенә котылып калдылар. Алар әле тышкы кыяфәтләрен дә үзгәрттеләр,урысларның җен ачуларын чыгара торган "р" авазын да тулы канлы итеп әйтә башладылар. Ленинннан соң Русия империясендә сакаулык тулысынча бетте, Кавказ акценты модага керде. Бер елны - бүдәнә, бер елны тартар симерә дигәндәй, зато хәзер бөтен власть башында гел әпә теллеләр. Халык сөйләгәннәрен аңлый алмый иза чигә. Хәер, төп башына утырып калгач, сөйләгәннәренең мәгънәсенә төшенәсең икән ул. "Пвиватиация"нең "прихватизация" икәнен төшендек, ваучер дигән шымытыр тотып калгач. Тартай симерде, ләкин татар мантый алмады. Ә шулай да, "Милләтле паспо-орт!" дип сөрән салырга җөрьәт итеп алды. Телчекле (вкладкалы) паспорт булса-булсын, тик милләтле паспорт булсын аңа!

Минем үземнең моңа бер дә исем китмәде. Милләтле паспортмы ул, әллә милләтсезме - барыбер котылып булмаячак! Безне, җәмәгать, барысыннан да элгәре, телебез сатачак. Ничекме? Шулай! Бөтен халык ике күзле, ике колаклы, ике куллы, ике аяклы, ике борын тишекле, бер телле! Бездә исә, ташка үлчим, икетеллелек! Авызны ачтың исә япьле тел килә дә чыга. Безне менә шул батыра да инде. Телчексез паспорт алсаң да котылдым юк. Казалы телгә әйләнде ул безнең өчен. Татарның акылы төштән соң, хәзер агай-эне бик пошаманда, бу бәладән ничек котылырга белми, менә шушы әхвәлне төшенеп, тынып калды күк. Ике телен дә тешләде. Юк бит, ишәйткәч-ишәйткәч шунда башка бер, күзгә-башка әлләни чалынып тормый торган, тормышта кирәгрәк әгъзаны ишәйтмәдек бит, шайтан алгырысы! Бар бит әле, югыйсә, телдән башка да арттырырга мөмкин әгъзалар.

Дамир АСЫЛОВ.
Бөгелмә шәһәре.

Шаман мәзәкләре

Иптәш майор

Бу хәл моннан 30 еллар элек була. Ул чакта Рәфкать Кәрами төзелештә электрик булып эшли, тулай торакта 4 кешелек бүлмәдә яши, хикәя-повестьлар яза, ике китап та бастырып чыгарырга өлгерә. Бервакыт аның янына язучы Барлас Камалов килеп керә.

- Энекәш, сиңа йомыш төште бит әле, - ди ул.

- Тыңлыйм, - ди Кәрами.

- Бер бәндә миннән шактый сумма да акча алып торган иде. Ярты ел узды инде, кайтарып бирми.

- Нәрсә, егетләр белән барыйкмы? - дип кинаяли Кәрами.

- Юк. Икебез генә барсак та җитәр. Синең буй-сын - Аллага шөкер, кыяфәт тә җитди. Сезне таныштырганда мин сиңа "иптәш майор" дип эндәшермен.

- Аңлашылды.

Барлас Камалов белән Рәфкать Кәрами Восстание урамындагы бер йортка баралар. Керәләр кирәкле фатирга.

"Иптәш майор" сүзен ишетүгә, йорт хуҗасы шыр җибәрә һәм тиз генә Барлас Камаловны кухняга дәшә. Бераздан, авызы колагына җиткән әдип, китәргә җыенып, ишек катында басып торган каләмдәше янына килә.

Аның артыннан чыккан йорт хуҗасы, иелә-бөгелә:

- Иптәш майор, берәр чынаяк чәй эчмисезме? - дип сорый.

- Юк, - ди Рәфкать Кәрами салкын гына. - 15 минуттан отделда совещание. Икенче вакыт керербез.

Урамга чыккач, Барлас Камалов шаркылдап көлеп җибәрә.

- Ну, энекәш, рольне оста уйнадың. Алай-болай тагын шундыйрак ситуациягә эләксәм...

Рәфкать Кәрами, аның сүзен кырт бүлдереп, әйтеп куя: - "Майор" чагында йөрермен, ә "полковник" итеп күтәрсәң, мине андый вак-төяк операцияләр белән борчымассың, - ди.

Җилкәме, иңбашмы?

Тәнкыйтьче-галим Тәлгат Галиуллин, күп еллар тәнкыйть йөген тартканнан соң, тукта әле, мин сезгә үзем язып күрсәтим, дипме, "Тәүбә" исемле роман иҗат итеп, аны "Казан утлары" журналында бастырып чыгарган. Ә юморист Әхәт Сафиуллин, әлеге әсәрне укып чыккач, андагы кайбер сүзләргә төртелеп, уйга калган. Җөмләдән берсе: "Җилкәме, әллә иңбашмы? Ягъни мәсәлән, адәм баласы дөнья йөген җилкәсендә күтәрәме, әллә иңбашына салып барамы? Автор бу ике төшенчәне бутый түгелме?.." "Тәүбә" романындагы шушы ике сүзне бер капчыкка төяп, гәзиттә бомба итеп шартлата Әхәт Сафиуллин. Кыскасы, "Тәүбә" романы авторын бүтәнчә болай язмаслык итеп тәүбә кылдырмакчы булгандыр, күрәсең.

Ә Тәлгат Галиуллин, тәнкыйтьне аны җилкәң белән күтәрдең ни дә, иңбашың белән күтәрдең ни - барыбер, минем җилкәм дә, иңбашым да нык әлегә, дигәндәй, "Элмәк" дигән яңа романын иҗат итеп куя.

Кредитка алган

Шагыйрь Мәннаф эш хакын алган чагында бухгалтер аның бер өлеш акчасын һаман тотып кала икән. Бервакыт иптәшләре сорый моңардан:

- Ник тотып калалар соң синең сәмәнне? - диләр.

- Кредитка... алган идем, шуңа тоталар, - ди Мәннаф, уңайсызланып кына. Шулай шактый айлар уза.

- Нинди бетмәгән кредит ул синең? Күптән түлисең бит инде? - дип аптырыйлар моңа.

- Озак сроклы кредит ул, - ди Мәннаф. - Кредитка... хатын алган идем мин. Балалар үсеп җиткәнче түлисе...

Күршеләрнең эте бар

Ни генә әйтсәгез дә, зәвык - һәркемнең үз эше. Әнә шул зәвык дигәннәренә мин бер җай таптым: күңелгә ошап куйган җырларны үзгәртәм дә җырлыйм, үзгәртәм дә көйләп йөрим. Авыз эченнән генә. Кычкырып җырлар идем, кеше көләр дип куркам. Чөнки мин отып алган җырларны бик тә танылган, мәртәбәле җырчылар башкара. Мәсәлән, Салават Фәтхетдинов болай җырлый:

Су өстендә балык уйный,
Иртә дими, кич дими.
Ике йөрәк бергә тибә,
Таң атканын да сизми...

Мин исә, ошбу сүзләрне үз зәвыгыма көйлим:

Балыкчы җыры

Су өстендә балык уйный,
Таң атканын да сизми.
Шул балык шулпаларыннан
Күңелем бер дә бизми.

Су өстендә балык уйный,
Һәй, күңелле шул чакта.
Бер балык сикергән саен,
Таяк ташлыйм учакка.

Ике йөрәк бергә тибә,
Иртә дими, кич дими.
Утын бетте, учак сүнде,
Тешләрем тешкә тими.

Бу җырымны гыйбрәт итеп
Җырлап бирәм халыкка.
Бер олау утын алыгыз,
Барган чакта балыкка!..

Хәния Фәрхинең җырлавын да бик ошатам. Ул болай мактана:

Әллә мине үпмәгәннәр дисезме?
Ялгышасыз...

Мин исә болайрак көйлим:

Сырган бишмәт көе

Әллә мине текмәгәннәр дисезме,
Әллә мине тетмәгәннәр дисезме?
Җөйләремне сүтмәгәннәр дисезме?
Ялгышасыз!
Әллә мине сырмаганнар дисезме,
Ямау салып тормаганнар дисезме?
Кадеремне белмәгәннәр, дисезме?
Башсызмы сез, әллә инде мисезме?..

Илфат ФӘСХИ.

Иҗатчы яклауга мохтаҗ

Иясез җырлар

Фәнис ЯРУЛЛИН





Мин җыр текстлары язучы шагыйрь түгел. 40 ел иҗат итү дәверендә нибары 60-70 җыр язылган икән - моны күп дип булмый. Шушы 60-70 җырның да чама белән өчтән бере генә (бәлки, бераз артыграктыр) радио фондларында саклана. Ләкин минем бүгенге язмам җырларның әзлеге яки күплеге турында түгел, ә иясез җырлар хакында. Иясез җырлар булмый, диярсез. Әйе, булмаска тиеш. Ләкин, ни кызганыч, бар андый җырлар. Укучыга аңлаешлы булсын өчен, нинди җырларны "иясез" дип атавымны әйтеп үтим. Иясез җыр - авторлары аталмаган җыр. Мин башка шагыйрьләр турында сүз алып бармыйм, үземнең "иясез җырларым"ны гына яклап язам. Кеше, үзенең тавык чебеше генә югалса да, эзли чыга, әгәр ул чебине берәрсе үзләштереп куйса, моның өчен тавыш кубарга мөмкин. Минем, мәсәлән, шактый гына "чебиләрем", ягъни шигырьләрем кеше ишегалдында адашып йөри. Иясез малны - эт ашар, диләр бит. Эт авызындагы корбанга әверелгәнче, кайбер "чебиләрем"не коткарырга кирәк таптым. Бу эшкә тотынырга күптән җыенсам да, һаман кул җитми иде. Беркөнне Ризван Хәмиднең "Көзнең соңгы яфраклары" дигән әсәре буенча куелган спектаклен Әлмәт театры артистлары уйнавында радиодан тыңларга туры килде. Радио аша бирелгән спектакльләрне бик үк өнәп бетермим мин, әмма Ризван Хәмидне чын күңелдән ихтирам иткәнлектән һәм аның пьесаларында һәрвакыт кискен конфликт ятканлыктан, бу спектакльне тыңларга булдым. Тыңлый башладым һәм ни ишетәм: спектакльнең башында ук бер героиня минем "Чын мәхәббәт бармы?" дигән шигырьне, бер сүзен дә үзгәртмичә, җыр итеп җырлый башлады.

Чын мәхәббәт юк ул, дисәм әгәр,
Үпкәләрләр бик бәхетле парлар.
Ә бәхетле парлар күпмелеген
Әйтә ала бары җәйге таңнар.

Чын мәхәббәт юк ул, дисәм әгәр,
Бик күпләрнең хәтере калыр кебек.
Әзмени соң кайнар күз яшьләрен
Яшәүчеләр тик мендәргә түгеп.

Бу шигырь 1983 елда язылган һәм Татарстан китап нәшриятында 1988 елда чыккан "Тозлы тамчы" дип исемләнгән китапта басылган иде. Тикшереп карарга теләгән кешегә аның 240 нчы биттә икәнлеген һәм әлеге шигырьнең югарыда атап кителгән ике куплет белән генә бетмәвен әйтеп үтәргә телим. Драматург әлеге әсәренә бу шигырьне үзе керткәнме, әллә ул режиссерның җиңел кулы белән кереп киткәнме - анысын әйтә алмыйм. Билгеле, һәрбер драматург шагыйрь була алмый. Пьесаларына җыр кирәк чакта алар шагыйрьләргә мөрәҗәгать итәләр. Әйтик, Гариф Ахунов Шәриф Камалның "Акчарлаклар" повесте буенча сәхнә әсәре эшләгәндә шагыйрь Рәшит Әхмәтҗановтан "Акчарлаклар" дигән шигырь яздырып ала. Тора-бара бу җыр бик популярлашып китә һәм Рәшит Әхмәтҗанов шигырьләренә язылган иң әйбәт җырларның берсенә әйләнә. Кайбер спектакльнең уңышы бер җырдан торуы мөмкин. Ничек кенә булмасын, фәлән спектакльдәге җырларның текстлары фәлән шагыйрьнеке, дигән хәбәр укучыга яки тамашачыга җиткерелергә тиеш. Бәлки, Ризван Хәмид аны үз кулъязмасында күрсәткәндер, ләкин тамашачыга, радио тыңлаучыларга бу нәрсәнең әйтелмәве күңелдә канәгатьсезлек хисе калдыра.

Пьесалар турында сүз чыккач, тагын бер вакыйганы искә алып китәргә булдым. Монысы үзем язган "Ак яфрак" пьесасы. Ул иң беренче булып моннан 5-6 еллар элек Чаллы яшьләр театрында куелды. Анда җырлар бик күп. Бу спектакльгә музыканы кем язганын хәтерләмим. Тик шунысы истә: спектакльдән соң ук андагы бер җыр популярлашып китте. Аны Чаллыда бер яшь җырчы кыз телевидение аша еш башкарды. Шигыре минеке икәнен әйтмәгән килеш, әлбәттә.

Ул җырны спектакльдә Батырша белән Айтуган (пьесадагы персонажлар) үзләренең сөйгән кызлары аларга чәчәк бәйләме биргәч җырлыйлар.

Кайсыгызга карарга да белмибез гел,
Сез үзегез болындагы иң гүзәл гөл.
Рәхмәт сезгә, рәхмәт матур булган өчен,
Йөзегезгә таң нурлары җыйган өчен.

Җыр шулай дәвам итә. Соңгы ике юлы кушымта булып бара. Ә беркөнне Татарстан радиосын тыңлап ятканда (нинди тапшыру икәнен хәтерләмим) Зөлфия Шакирова башкаруында "Рәхмәт сезгә, рәхмәт матур булган өчен, йөзегезгә таң нурлары җыйган өчен", дигән сүзләр кергән бер җыр ишеттем. Җырның калган өлеше минеке түгел, шулай ук авторы да башка. Икенче автор җырның образын, интонациясен һәм кушымтасын алган да үзенеке иткән.

Шундый ук язмышка дучар булган икенче бер җырны да Зөлфия белән Җәүит Шакировлар башкаруында еш биләләр. Ул "Һәркөнне керәсең төшемә" дип атала. Зөлфияләр аны дуэт белән башкара. Бик матур җырлыйлар. Шигыре аның Акбашевныкы, музыкасы Роза Сәхаветдинованыкы санала. Чынында исә, бу җырны минем 1977 елда ук язылган "Гел шулай керәсең төшемә" дигән шигырьнең бер варианты диярга мөмкин. Аңа көйне атаклы баянчы Кирам Сатиев язган иде һәм ул Рафаэль Җаббаров башкаруында күп мәртәбәләр радиодан яңгырады. Менә аның сүзләре:

Гел шулай керәсең төшемә:
Кулыңда чәчәкләр бәйләме.
Каядыр ашыккан җиреңнән
Карыйсың әйләнеп-әйләнеп.

Карыйсың, кулларың изисең,
Йөзеңдә ниндидер үпкәләү
Һәм сагыш бар сыман тоела.
Нәрсәдер әйтергә телисең,

Тик җилләр өзгәли сүзеңне.
Тирбәлә һавада бер аваз:
"Без инде... Без инде... Без инде..."

Гел шулай керәсең төшемә,
Кулыңда яшьлекнең гөлләре.
Гөлеңне йолкыйлар кулыңнан
Тормышның аяусыз җилләре.

Бу шигырь 1988 елда чыккан "Танышлар арасында" дигән китапта басылган иде, 58 нче биттә. Язылу вакыты - 1977 ел.

Җыр сөючеләр Зөлфия һәм Җәүит Шакировлар башкаруындагы "Һәркөнне керәсең төшемә"не минем шигырь белән чагыштырып карасалар, шигырьнең җаны булган образ гына түгел, миндәге бөтен интонация, хәтта кайбер куплетларның да кабатлануын күрерләр. Ә шигырьнең образы, эчке моңы, поэтик детальләре булгач, әз-мәз каләм тибрәтә белгән кеше өчен яңа вариант тудыру берни тормый. Шуңа күрәдер, ахры, хәзер игезәк җырлар бөтен дөньяны басты.

Кеше ишегалдына кереп китеп, үз хуҗасын оныткан "чебешләр"ем бик күп минем. Мәсәлән, Зәйнәп Фәрхетдинова җырлый торган "Яратып бер кара әле күзләремә" дигән җыр. Аны мин Татарстан радиосы аша шактый еш тыңладым. Көе матур. Зәйнәп Фәрхетдинованың лиризмга бай, үзенчәлекле аһәңе, җырга аерым төсмер һәм мелизмнар биреп җырлавы бу җырчыга карата күңелемдә күптән мәхәббәт уятып өлгергән иде. Шуңа күрә, аның башкаруында үз җырымны ишеткәч, сөенеп куйдым. Тик сөенечемә бер нәрсә күләгә төшерде: бу җырны ничә башкарсалар да, авторларын атамадылар. Дөрес, әлеге җыр музыкаль тапшырулар редакциясе аша түгел, йә "Дөнья", йә "Татарстан авазы" тапшыруларында яңгырый. Мин, моның төбенә төшәргә тырыштым, Татарстан радиосының музыкаль тапшырулар редакциясенә шалтыраттым. "Безнең фондта Зәйнәп Фәрхетдинова башкаруында андый җыр юк", - диделәр. Шуннан соң мин З.Фәрхетдинованың телефонын эзли башладым. Телефонын тапкач: "Зәйнәп ханым, менә хәзер мин сезгә бер шигырь укыйм. Шуның кемнеке икәнен беләсезме?" - дидем.

Яратып бер кара әле күзләремә,
Карашыңнан ут йөгерсен йөзләремә.
Шушы утның очкынын да сүндермичә
Алып кереп китим әле көзләремә.

Көзләремнең озын, салкын кичләрендә
Соңгы күмер сүнгән чакта мичләремдә,
Шушы уттан, бәлки, җылы алырмын да
Бер талпынып алырмын мин хисләремдә.

Кабына алмам, табына алмам, беләм ансын.
Йодрык кадәр йөрәк тагын күпме янсын!
Ә шулай да, иң ахыргы җырым өчен
Күкрәгемдә бер булса да җырым калсын.

"Җан авазы" китабы. 1994 елда Татарстан китап нәшриятында чыккан. Шигырьнең язылу датасы - 1987 ел.

Мин шигырьне укып бетергәч, Зәйнәп: "Бу Ринат Фәттахов җыры бит", - диде.

- Моның шигыре минеке, - дидем мин һәм шигырьнең кайсы китапта, кайчан чыкканлыгын әйттем.

- Шулаймыни? - дип гаҗәпләнде Зәйнәп Фәрхетдинова. - Безгә аны Ринат Фәттахов биргән иде. Шигырьнең кемнеке икәнен күрсәтмәгәч, без бу җырны тулысы белән Ринат Фәттаховныкы, дип уйладык. Һәм ул безнең кассеталарга да шулай кереп китте. Ярый, без бу хатаны төзәтербез.

Мин, Зәйнәпкә рәхмәт әйтеп, трубканы Зөфәр Билаловка бирүен үтендем. Чөнки иясез бер җырны аның башкаруында да берничә тапкыр ишетергә туры килгән иде. "Китмә әле, мәхәббәт" дип атала ул. Мин аны Татарстан телевидениесе аша һәм "Дулкын" радиостанциясе тапшырулары буенча ишеткән идем. Ләкин бер җирдә дә ни композиторын, ни шигырь авторын атамадылар. Менә ул минем шигырь. Сайланма әсәремнең 3 нче томында, 90 нчы биттә басылган. Язылу датасы - 1991 ел. Исеме "Мәхәббәткә ялвару" дип атала. Мин монда, икеләнү-шикләнүләргә урын калдырмас өчен, барлык шигырь текстларын тулысынча китерәм. Һәм гәзит, "урын җитмәү сәбәпле" аларны кыскарту яки төшереп калдыру юлына бармас, дип уйлыйм.

Китмә әле, китмә, мәхәббәт,
Бик аз кунак булдың бит әле.

Хыял тулы минем йөрәккә
Тагын бер яз бүләк ит әле.

Ә аннары китсәң китәрсең,
Өметләрне киссәң кисәрсең.
Озатырмын үзем кул болгап,
Йөгерерләр гөлләр юл буйлап.

Китмә әле, китмә, мәхәббәт,
Тагын бер җәй бүләк ит әле.
Кабызырга сүнгән учакны
Тагын бер җай бүләк ит әле.

Китмә әле, китмә, мәхәббәт,
Тагын бер көз бүләк ит әле.
Бакчамдагы соңгы гөлләрне
Өзәселәр бардыр бит әле.

- Бу җыр Фәнир Галимовныкы, - диде Зөфәр Билалов һәм аны яратып җырлавын әйтте. Шигырь минеке икәнлеген белгәч, ул бик аптырады. Хәтта кыенсынып калды. Бу очракта, билгеле, җырчылар гаепле түгел иде. Гаеп шигырьләргә көй язган композиторларда. Алар бит кем шигыренә көй язганлыкларын яхшы белә. Чөнки шигырь алар кулына гәзит-журнал аша, йә китаптан килеп керә. Ә гәзит-журналларда яки китапта бер генә шигырь дә авторсыз чыкмый.

Бу җырларның язмышы ачыклана төшкәч, мин авторларның хокукын яклаучы орган - ТАИСка шалтыраттым. Анда җырларның минеке икәнлеген теркәп куйдылар. Ләкин аннан соң да җырлар исемсез яңгырауларын дәвам итте. Чөнки кассеталар халыкка таралып өлгергән. Ә анда бердәнбер автор итеп композитор гына күрсәтелгән. Билгеле булганча, Зәйнәп Фәрхетдинова, Зөфәр Билаловларны халык бик ярата. Алар җырлаган җырлар тиз популярлаша һәм аларны үзешчәннәр дә үз репертуарларына кертә. Хәзер үзешчән һәм ярымүзешчән артистлар нык үрчеде. Ә концертларны элеккечә конферансье алып бармый. Җырны тамашачыга йә җырчы, йә концертны алып баручы ролен үтәүче берәрсе игълан итә. Күп очракта авторларны әйтеп тә тормыйлар. Җыр арты җыр агыла, акыл томалана. Тамашачыга җырның авторы кирәк түгел. Ул үзе яраткан җырчының тавышына, кыланышына, көлмәкләренә мөкиббән китеп утыра. Гадәттә, ят чебеш кемнеңдер ишегалдында озак йөрсә, йә аны суеп ашыйлар, йә үз тамгасын салалар.

Кайвакыт иясез җырлар тууга без үзебез дә сәбәпче булабыз. Сүзләремне раслар өчен, моннан 8-9 еллар элек булган вакыйганы сөйләп үтим. Көннәрдән бер көнне безгә мин бик хөрмәт иткән артистка белән Таһир Әбдершин атлы үзешчән композитор килеп керде. Таһир Әбдершин Ырынбур каласыннан булып, ул чакта Казанда җырчы сыйфатындамы, баянчы сыйфатындамы эшләп йөри иде. Сөйләшә торгач, җырчы, баянчы булуы өстенә, аның әле композитор да икәнлеге ачыкланды. Ул үзе белән магнитофонын да алып килгән, ә магнитофон тасмасында бик күп көйләр язылган иде.

- Болар минем яңа җырларым, - диде Таһир Әбдершин, - аларның әле сүзләре юк. Мин үземнең аудиокассетамны чыгарырга җыенам. Шушы көйләргә шигырьләр яза алмассызмы икән?

Мин, әзер көйләргә текст язмавымны әйтеп, аның тәкъдимен кире кагарга тырыштым. Ләкин артык кыстый башлагач, көйләрен тыңлап карарга һәм, минем рухыма туры килгән очракта, берничәсенә шигырь язарга вәгъдә биреп, магнитофонын алып калдым.

Көйләр магнитофон тасмасына Таһирның үзе башкаруында, баян белән язылган иде. Өйдә ялгызым гына калган вакытларда кабат-кабат тыңлый торгач, болар миңа ошый башлады. Һәм мин уннан артык көйнең алтысына шигырь яздым. Бераздан Таһир Әбдершин аларны бик яратып, рәхмәтләр әйтә-әйтә алып китте. Ниндидер килешү төзү турындагы фикер ни аның, ни минем башыма килмәде. Мин үз "чебешләр"емне үз кулларым белән аның кочагына тутырып җибәрдем.

- Болай булгач, һичшиксез, кассета чыгарам, - диде Таһир, шатланып.

Һәм мин аның кассета чыгарганын ишеттем. Миңа ул кассетасын китерергә вәгъдә иткән иде, ләкин үзе Казаннан Ырынбурга кайтып китү сәбәплеме, кассетасын китерергә өлгермәде. Билгеле, теләгән очракта аны почта белән дә салырга мөмкин иде. Ләкин аның сәбәбе тирәндәрәк, дип уйлыйм. Шигем мондый: мөгаен, ул кассетасында шигырьләрнең минеке икәнлеген күрсәтергә "оныткан". Шигемне раслаучы дәлилләр дә бар: берничә тапкыр төрле тапшыруларда үземнең әлеге шигырьләремә язылган җырлар ишеттем. "Курай", "Дулкын" кебек радиостанцияләр, гомумән, авторларны атап мәшәкатьләнми. Ләкин бит аларны халык тыңлый. Кайберләрен кемнәрдер отып ала, үзе дә җырлый.

Таһир Әбдершинга биреп җибәргән шигырьләр "Яну", "Сау бул, авылым", "Таңчулпан", "Тик мәхәббәт бирәү генә", "Өзмим әле алларын" дип аталган иде. Ана турындагы шигырьнең исә тексты үземдә дә калмаган. Кайвакыт шигырьләрне дәфтәргә күчереп өлгермисең, каралама хәлендә кемгәдер биреп җибәрәсең. Бу җырлар җырланамы, җырланса кем көенә җырлана - кистереп әйтә алмыйм. Минем, мәсәлән, "Яну" һәм "Өзмим әле алларын" дигәннәрен ишеткәләгәнем бар. Бу икесенә Гөлнара Беляева да музыка язган иде. Ләкин, профессиональ җырчылар җырламаганлыктан, һәм ниндидер тапшыруларда музыкаль бизәлеш итеп кенә файдаланганлыктан, кайчан, кем башкарганлыгын әйтү кыен.

Тагын бер "чебешемнең" "Бишек җыры"ның хәбәрсез югалу ихтималы бар. Анысының тулы текстын китереп үтәм.

Мин сине күкләрдән эзләп,
Йолдыздан таптым.
Шуңа күрә йөзләрең ак,
Йөзләрең якты.

Коендырдым ай нурында
Төннәр буена
Ай нурлары кереп тулган
Синең куеныңа.

Былбыллар бәхет теләде
Сиңа таңнарда.
Агып китте сагышларың
Сары салларда.

Җәйге кояш битләреңә
Ал нурын якты.
Шуңа күрә йөзең якты,
Телләрең татлы.

Бу җыр телевидениедә "Әлли-бәлли-бәү" тапшырулары аша яшь җырчы Гөлнара Тимерҗанова башкаруында шактый еш яңгырый. Ләкин бу тапшыруда, ни өчендер, ни шигырь, ни көй авторын атамыйлар. Дөрес, кайбер җырларның авторлары титрга языла. Тик бу сирәк. Ә бит "Әлли-бәлли-бәү" тапшыруы - бик популяр тапшыру. Аны күп кеше карый. Бәлки, кайбер яшь аналар анда җырланган җырларны отып алып үз сабыйларын йоклаталардыр. Ләкин алар сабыйларын кем күчтәнәче белән сыйлаганнарын белмиләр. Шулай итеп, җыр үз иясен югалтырга мөмкин.

Телевидениегә кагылгач, тагын бер фикер әйтеп китү урынлы булыр. Концертлар биргән вакытта, гадәттә, җыр исемен, кайчакта авторларны да аска язалар. Бу исемне укырга өлгермисең, "Бегущая строка" дигән нәрсә нәкъ теге язу өстенә йөгереп килеп менә дә, бөтенесен каплап китә. Җыр исемнәрен күрсәткәндә "Бегущая строка"ны берничә секундка туктатып торырга, ә инде туктатып булмый икән, концерт турында мәгълүмат бирүче язуны югарырак менгерергә мөмкиндер, минемчә.

Гомумән, җырлар турында язасы фикерләрем бик күп әле. Мин шигырьләремә көй язган композиторлар ниндидер усал ният белән боларны үзләренеке итәргә телиләрдер, дигән фикердән ерак торам. Бу - игътибарсызлык һәм бер-беребезнең иҗатына хөрмәт белән карамау бәласе. Җырларны башкаручылар да, аларны төрле тапшырулар аша халыкка таратучылар да, авторларын ачыкламаган килеш, былбыл-җырларыбызны эфирга очырмасыннар иде. Җырлардагы, шигырьләрдәге һәр образ күп уйланулар, эзләнүләр нәтиҗәсендә туа. Авторларга үзенең йөрәгендә кайнап чыккан һәр юл кадерле, газиз. Шигырьләрнең бер генә юлын үзләштерсәләр дә җан әрни. Бер-беребезнең иҗатына кул сузмыйк, дуслар. Бу бит безнең иң кадерле байлыгыбыз.

Казанның 1000 еллыгын каршылап

Борынгы Казан күренеше.

Тарихка төбәлеп карасаң...

Казан урамнары буйлап атлаганда, минем күңелемә еш кына шундый уйлар килә: менә шушы урамнардан, шушы юллардан йөз ел элек тә, мең еллар элек тә кемдер атлап йөргән бит. Чынлап та, Казаныбыз үзенең 1000 еллыгын каршыларга әзерләнә, ә аның катлаулы һәм данлы тарихы үзеннән-үзе зур кызыксыну уята...

"Казан" милли мәдәният үзәгендә ачылган "Борынгы Казан" исемле күргәзмәне карарга махсус бардым. Бу күргәзмә өч залны биләп тора. Аларның һәрберсенә тарихыбыз өртелгән. Әнә, кульязмалар, төрле документлар, фәрманнар, сугыш кораллары... Хәрби кием киеп алган манекеннарны күргәч, сискәнеп тә китәсең хәтта. Алар чын булып тоела, алар сине үзләренә ияртеп ерак тарихка алып кереп китәр кебек. Әнә, борынгы савыт-сабалар, хатын-кызларның бизәнү-ясану әйберләре. Имештер, бер акыл иясе болай дип әйткән: татар хатын-кызларының атлап килүен башта ишетәсең, аннан соң гына үзләре күренә, дигән. Чыннан да шулай: чулпы-тәңкәләрен-алкаларын чыңлатып атлап йөргән алар. Хатын-кызларыбыз өчен генә түгел, борынгы ювелирларыбыз-осталарыбыз өчен дә горурланасың бу күргәзмәдә.

Әлбәттә, мондый чакта янәшәңдә экскурсовод булса, мәгълүматны да күбрәк аласың, тарихны да тирәнрәк тоемлыйсың. Минем бәхеткә дә шулай туры килде, күргәзмәдә экскурсовод Йолдыз апа Бурнашева бар иде. Аның үзе турында мин элегрәк тә ишеткән идем инде: белүемчә, аларның нәсел-нәсәбе бик тә укымышлы, күренекле кешеләрдән. Йолдыз апа үзе дә галим кеше, Казан дәүләт университетында лекцияләр укый. Аларның нәселендә чит телләрне өйрәнүчеләр-белүчеләр дә күп. Ә менә Йолдыз апа болай дип тә сөйләде безгә:

- Бер экскурсия вакытында укучы балаларга "Нәрсә ул моң?" дигән сорау бирдем. Шунда бер малай әйтте: "Моң - көйнең, җырның җаны, һәр халыкның үз моңы була", - диде. Үзенең бу фикерен әле менә монда, экскурсиядә чакта гына аңлап өлгерүен дә әйтте.

Бу күргәзмәне чит илләрдән килүчеләр дә карый икән. Французлар, немецләр, әзәрбәйҗаннар... Моң мәсьәләсендә Йолдыз апа аларга сорау биргән, хәтта үз телләрендә үз җырларын көйләп-җырлап та күрсәткән. Французча да,немецчә дә, әзәрбәйҗанча да матур, чиста итеп. Әле безгә дә ул үз телебездә "Сандугач" җырын җырлап күрсәтте, моңның ни булуын шулай итеп тә аңлатып бирде.

Ә мин исә борынгы үткәннәребез өчен, бүгенге көндәге талантлы кешеләребез өчен, тарихыбызның зурлыгы өчен горурландым.

Безнең телебездә "тарих тузаннары" дигән гыйбарә бар. Әгәр күңел күзе белән баксаң, "тарих тузаннары" аша бик күп хәлләрне-вакыйгаларны күреп, тарихның үзенә төбәлеп карап була икән. Әлеге күргәзмәдә мин моңа тагын бер кат ышандым...

Фәридә КАМАЛ,
"Логос" студиясе әгъзасы.

Асылыбызга кайтып барышлый

Асыл таякта корт булмас, уч төбендә йон булмас

Соңгы вакытта милли үзаңыбызны күтәрү, ата-бабаларыбыз гасырлар буе саклап килгән гореф-гадәтләребезне саклауның ни дәрәҗәдә мөһим икәнлеген аңладык инде. Шул ук вакытта милли киемнәребез саналган түбәтәй, читек-кәвеш киеп йөрү, хатын-кызларыбызга яулык бәйләү, мөселман ир-атларга сакал-мыек йөртүнең мөһимлеген аңлап бетерә алмыйбыз, моны күп кешеләр искелек калдыгы диебрәк кабул итә. Кайбер зыялыларның: "Татар читек-кәвештән ары китә алмады инде", - дип мыскыллавын да ишеткәләргә туры килә.

70-80 ел дәвамында берничә буын динсезлек-имансызлык рухында тәрбияләнде, һәм аның нәрсәгә илткәнен әле генә аңлый башладык. 30 нчы елларда хатын-кызлар чәч кистереп, башларыннан яулыкларын гына салды, ә хәзер кызларыбыз бөтенләй диярлек чишенеп ташлады. Яулык белән бергә оят та качты. Хәзер инде кайбер өлкән яшьтәге кешеләр дә кыска җиңле күлмәк киеп, марҗаларча кыска чәч йөртәләр, яланаяк йөриләр.

Татар халкы XXI гасырга әхлаклы, инсафлы халык булып керсен, ике аягында да нык басып торсын иде. Бер яктан иманлы, чиста кальбле, икенче яктан - дөньяви гыйлемле, һөнәрле һәм тырыш булсын иде.

Дин - юл дигән сүз. Иң саф юл - Аллаһ юлы. Ә шайтан кешеләрне туры юлдан яздыру өчен күңелләренә мәгънәсез фикерләр сала, төрле ялган идеяләргә табындыра, ягъни "өмния" сала. Кеше буш идеаллар белән саташып гомер уздыра. Инде яңадан читек-кәвеш, түбәтәйләргә кайтыйк. Ни өчен үзләрен мөселман дип атаучы кайберәүләрнең йөзләрендә нур юк? Чөнки кальбләре, кылган гамәлләре дөрес түгел. Ашаган ризыклары харам, намаз уку, ураза тоту юк. Теләсәгез нәрсә әйтегез, җәмәгать, әмма иманга кайту милли киемнән башлана. Ак яулык, ак шәл бөркәнгән ханымнарның йөзләрендә нур балкый. Башына түбәтәй кигән ир канауда исереп аунап ята алмый, аның болай эшләргә хакы юк. Татар халкы борын-борыннан читек-кәвеш киеп йөргән, чөнки алар аякка йомшак һәм бик чыдам булганнар.

Болгарның үзендә җитештерелгән күннән тегелгән итек, читек, кәвешләр аякны тирләтмәгән, бернинди кычыту авырулары булмаган. Саф күн сулый ул. Болгар итеге, читек, сафьян - болар телдән-телгә күчеп, даннары төрле илләргә таралган һәм дәмәшкъ корычы, иран келәме кебек иң югары сыйфатлы дигәнне белдергән. Хәзер кайда икән ул болгар күнен эшкәртүче һөнәрчеләр? Ат дирбияләрен - йөгән, ыңгырчак, иярләрне күпләп эшләүчеләр бар микән?

Үткән ел миңа Аллаһының ярдәме белән хаҗ кылырга насыйп булды. Согуд Гарәбстанында берьюлы дүртәр-бишәр млн мөселман хаҗ кыла, ләкин берсе дә 60-70әр градус эсседә ашказаны-эчәк авырулары белән интекми: Ислам дине сәламәтлегебезне үзе үк кайгырта. Тәһарәт алуны гына карыйк. Без баш түбәсендә урнашкан биологик актив нокталарга кагылып, су тидерү, сыпыру нәтиҗәсендә бөтен организмны сәламәтләндерәбез. Һәм ул зоналарны каплап йөрү - яулык бәйләү, түбәтәй кию бик тә әһәмиятле. Бу хәл бәндәнең йөзен дә нурландыра. Ә ни өчен мөселман ир-егетләр сакал-мыек үстерергә тиеш? Бу хакта 3-4 сәгатьлек лекция укып булыр иде. Сакал-мыек ир-егетне яман күз, кирәкмәс энергиядән саклый. Раббыбыз ирләрнең нәкъ менә шушы урыннарына сакал-мыек биргән дә инде.

Тәгам җыйганнан соң дога кылуның да хикмәте бар. Дога укып битебезне сыпырганда чигә, яңакта урнашкан биологик нокталарны үзебезнең кул энергиясе белән дәвалыйбыз.

Кайберәүләр әйтә, яулык бәйләп, түбәтәй киеп йөрер идем дә, тышкы кыяфәтем белән кылган гамәлләрем тәңгәл килми шул, диләр, ягъни тышкы кыяфәтем матур булса да, эчке дөньям ямьсез, ди. Бу дөрес фикер түгел. Ак яулык (түбәтәй) үзе үк начар энергиядән саклый, күп кенә кирәксез гамәлләрдән тыеп кала.

Суфия ГАЛИЕВА,
табибә.

Шәриф Камал музей-фатиры ачылуга 50 ел

Тыңлый белсәң, сөйли тынлык та...

Риза ШӘФИ

Үзен сүзнең кыскасы

* * *
Сарык куып, тотсаң бәрән,
Сарыф кылган вакыт әрәм.
* * *
Симез ташбаш булса җимең,
Чуртан тоту ифрат җиңел.
* * *
Сереңне сал агым суга -
Күлдәге ләм калкып чыга.
* * *
Син, дип, кайсы милләттән -
Сорамыйлар икмәктән.
* * *
Булса да каты токымнан,
Имән дә тамырга тотынган.
* * *
Акыл икән күңел төбең -
Алтын итәр телең төбен.
* * *
Сынды кылыч - булыр хәнҗәр,
Сынды чалгы - икмәк теләр.
* * *
Өреп тормасалар этләр
шом салып,
Бүреләрдә дә бетәр осталык.
* * *
Ашаганы тары гына -
Куркыныч юк сарыгыңа.
* * *
Хөрлектән туйган имән
Өрлектә аңга килгән.
* * *
Үз юлын үзе табар -
Күл булмас, ары агар.
* * *
Белсәң агудан төзәләсең,
Еланга да тезләнәсең.
* * *
Башка булса да корычы,
Шул ук кала кармак очы.
* * *
Баткак бирсә шифасын -
Акча түләп чумасың.
* * *
Тотып бетереп тычканны,
Тырыш мәче ач калды.
* * *
Биш акылсыз кыекланса,
Акыллы да кыек баса.
* * *
Картлык бәясез тауар -
Акчасызны да табар.
* * *
Гүзәлләрдәме өмет -
Сиксәндәге дә егет.
* * *
Билгеле киләчәгең -
Без мизгел үләчәгең.
* * *
Иң соңгы кирәгең -
Кабрең казыр көрәгең.
* * *
Кайтып булмаслык ерак -
Ындыр артында зират.
* * *
Чыбыркы шартлатмаган
көтүче -
Көтүен җыялмый интегүче.
* * *
Керем эзләп йөрисең -
Йә төлке, йә бүресең.
* * *
Каплаганы булса черек,
Яшерә ялмый бүрек...
* * *
Килгән саен кәнфит бирсә,
Иң шәп түти - Хәерниса.
* * *
Карун карунны буган -
Берсендә алтын булган.
* * *
Бүректәге мехның ялтыравы
Акыллы итә алмый аңгыраны.
* * *
Кем кулында алтын комы -
Барча комсыз аның колы.
* * *
Әдәпле булса да мөгезле,
Сүз таралыр: "Ул сөзде!"
* * *
Куянны куркак дигән -
Капкасын бикләп кергән.
* * *
Бүре эзенә юлыккан -
Куян эзен оныткан.
* * *
Күршең булса тол кодача,
Кодагыйдан йокы кача.
* * *
Тол ягына койма койган,
Бер тактасын какмый куйган.
* * *
Толның капкасы бикле,
Димәк, коймасы ипле.
* * *
Ярың булса тундра,
Тропиклар кундыра...

● Музей-фатирның тышкы күренеше.

Казанның Островский урамында бер йорт бар. Галиҗәнап Вакыт, әйтерсең, монда үзенең ачышын туктата да, бер мәлгә, сине тормыш ыгы-зыгысыннан аерып, Ерак Тарих, Зур Әдәбият сәхифәләре эченә алып кереп китә, Хәтернең тирән почмакларына барып кагыла.

Кабатланмас архитектура истәлеге булган әлеге йортта әдәбиятыбыз классигы Шәриф Камалның музей-фатиры урнашкан. Шушы өч бүлмәле җыйнак һәм тыйнак итеп җиһазландырылган фатирда язучы үзенең гаиләсе белән 15 ел яши. Шунда гомеренең соңгы сәгате дә суга.

1944 елның 2 июнендә, дәһшәтле сугыш барган көннәрдә, РСФСР Совнаркомы әдип яшәгән фатирны музей итеп оештырырга дигән карар чыгара. 1950 елның 29 гыйнварында инде ул, әдәбият музее буларак, үзенең ишекләрен ача, тәүге тамашачы-укучыларын кабул итә. 1980 елда музей, кайбер үзгәрешләр кичереп, Дания Баһаветдинова авторлыгында, мемориаль музей итеп торгызыла. Шулай итеп, Шәриф Камал музей-фатиры, татар язучысы хөрмәтенә ачылган беренче музей булып, тарихка кереп кала.

Нәкышләп эшләнгән борынгы мәһабәт ишекнең иңрәп ачылуыннан сискәнеп куясың. Идән сайгакларының баскан саен шыгырдап куюы да шомлы уйларга сала. Бар да, тарих катламыннан саркып чыккан кизләү кебек, ниндидер таныш көй көйли - моңланып та, ачынып та, тетрәнеп тә, пышылдап та...

Бер акыл иясе әйткән: "Музейда һәрбер нәрсә үзенең яшәвен дәвам итә. Алар безнең белән күзгә-күз карап сөйләшәләр. Гүя, Вакыт катламын тишеп, Кояшка мәңге яшел үсенте үрмәли. Музей - ул Хәтер утравы".

Әйе, музейдагы һәр экспонат язучы тормышының якты истәлеге, өнсез шаһите.

30-40 нчы елларда әлеге фатир татар мәдәниятенең кечкенә генә учагы булган. Монда еш кына кызыклы очрашулар, кичәләр үткәрелә. Шәриф Камалның фатиры нинди генә гали затларның изге рухын үзендә кадерләп сакламый да, нинди генә шәхесләрнең эзләрен хәтерләми?!

Сәүдәгәр Ивановның 1905 елда төзелгән йортындагы баскычның сырлап эшләнгән култыксасына таянып, икенче катка, кунакчыл хуҗа янына, кемнәр генә күтәрелмәгән?! Нимес драматургы Ф.Вольф, урыс язучысы А.Фадеев, К.Тинчурин, К.Нәҗми, М.Җәлил, Ф.Кәрим, Х.Әбҗәлилов, виртуоз гармунчы Ф.Туишев... Бүлмәнең түрендәге рояльнең клавишаларына нинди генә мәшһүр композиторларыбызның бармаклары кагылмаган?! С.Сәйдәшев, А.Ключарев, Җ.Фәйзиләрне әле дә булса хәтерлидер рояль. Рояльне комиссион кибеттән сайлап алышырга әдипкә С.Сәйдәшев ярдәм итә.

... Еш кына, кичләрен, каршы яктагы йорттан кемдер рояльдә уйный. Көннәрдән бер көнне, Ш.Камалның кызы - 9 нчы сыйныф укучысы - Зәйнәп ачык калган тәрәзәдән сихри авазлар ишетеп ала да, тәрәзә янәгына сөялеп, хыял диңгезенә чума. Ә бармаклар, әйтерсең, рояль клавишаларында йөзәләр. Әйтерсең, Зәйнәп үзе уйный. Серле уйлар урманында адашып, ул хәтта әтисенең аны читтән генә күзәтеп торуын да сизми калган. Икенче көнне ул, мәктәптән кайтып керсә, өй түрендә рояль басып тора, ә рояль артына С.Сәйдәшев утырган да, илһам агачыннан әле яңа гына өзелеп төшкән әсәрен уйный. Клавишаларга баскан саен үзенең тирән соклануын белдереп, әйтеп куя: "Бәллүр кебек яңгырый ич, бәллүр кебек!.." Шәриф Камал исә: "Ике кышны тунсыз чыксам чыктым, ләкин, барыбер, кызыма рояль сатып алдым", - дип тыйнак кына елмая.

Язучы үзе дә музыкага битараф булмый. Ул рояльдә дә, скрипкада да уйнаган. Замандашларының истәлекләренә караганда, аеруча халкыбызның "Каз канаты", "Ком бураны", "Шахта" көйләрен, "Амур дулкыннары" дигән урыс романсын да яратып башкара.

Ә менә скрипка?.. Яраткан скрипкасын, язу машинкасы белән бергә, Ш.Камал, Бөек Ватан сугышы башлангач, комиссион кибеткә куеп сатарга мәҗбүр була. 1950 нче еллар башында, экспозицияне экспонатлар белән баету максатыннан, әлеге машинканы эзләү башлана. Күп тә үтми, кадерле ядкярне Казан янындагы Залесный бистәсендә яшәүче бер гаиләдән музей хезмәткәрләре табып алалар. Аның Ш.Камалныкы икәнлеген язу машинкалары остасы Алишев исбатлый. Чөнки оста заманында нәкъ шушы машинканың клавиатурасына татар алфавитындагы хәрефләр өстәгән була. Тик менә скрипка гына?.. Ә кем белә, бәлки әле ул бүген дә хуҗасын юксынып, кемнеңдер диварында эленеп торадыр.

Музей буйлап атлыйм. Язучының гомеръязмасын актарам. Гүя миңа үткәннәр аша үрелеп, Тынлык эндәшә.

● Музей кунаклары СССРның халык рәссамы Х.Якуповның "Шәриф Камал" картинасын тамаша кыла.

Әйе, "Тыңлый белсәң, сөйли тынлык та...", - дип бер шагыйрь хак әйткән. Тынлык сөйли... Шушы фатирга репрессия елларының өермәсе килеп кагылуы турында да, Бөек Ватан сугышының салкын җилләре үтеп керүе хакында да сөйли Тынлык.

1937 елның урталарында Шәриф Камалның иң якын дуслары К.Нәҗми дә, К.Тинчурин да, Ф.Кәрим дә кулга алына. "Халык дошманнары"ның күләгәсе Ш.Камалга да төшә. Өстәвенә, К.Нәҗмине: "Ул шуның кадәр дә кырыс хөкемгә лаек түгел", - дип ачыктан-ачык яклап та чыга. Әдипнең мулла баласы булуын да исәпкә алганда, тырнак астыннан кер эзләргә сәбәп җитә. Кемнәрнедер аның аз сүзле, характерының йомыкыйрак булуы да шиккә сала. Истәлекләргә караганда, 30 нчы елларның икенче яртысында бичара Шәриф Камал үзенең шушы фатирында һәр кичтә: "Мине кайчан алып китәрләр икән?" - дип, өстенә чиста кием киеп ята торган була. Өстәлдәге телефон ярты төн уртасындагы чылтырауларны әле дә хәтерли торгандыр. Ләкин чылтыратучылар гына эндәшми. "Шәриф Камал кулга алынмаган, Аллага шөкер!". Бәлки, аларга шуны белү дә бик җиткәндер... Өстәл өстендәге телефон бүген инде бөтенләй өнсез. Телефон уйда... Бүген инде ул Үткәннәрдән дә, Киләчәктән дә хәбәр китерми. Ул бары сөйли генә. Тынлык булып сөйли. Гүя Үткәндәге хатирәләрне тизрәк Киләчәккә ялгарга ашкына.

Түрдә язучының эш өстәле. "Әти шундый җайлы,иркен эш өстәлен булдыру турында Ырынбурда яшәгәндә үк хыяллана иде, - дип сөйли Зәйнәп ханым. - Ләкин анда яши торган фатирыбыз бәләкәй булганга, әти хыялын тормышка ашыра алмады. Казанга кайтып, яңа фатирга күчү белән, беренче җиһаз итеп, шушы өстәлне сатып алып кайтты".

Әдипнең "Матур туганда", "Таң атканда" романнары, "Таулар", "Ут", "Козгыннар оясында" кебек пьесалары әлеге өстәлдә иҗат ителгәннәр. Шәриф Камал, әйтерсең, менә хәзер генә өстәл янынннан торып киткән. Өстәл өстендә җәйрәп яткан ак кәгазь бите, бармаклары җылысы да суынырга өлгермәгән каләме аның кулы кагылуын көтәләр кебек.

Әйе, һәрбер экспонатның үз тарихы. К.Нәҗми белән С.Әдһәмова 1941 елда Ш.Камалның беренче оныгы туган көнне бүләк иткән пыяла вазасы, Ташаяк ярминкәсе ядкяре, К.Тинчурин белән бергәләшеп алынган керамик язу-сызу өчен кирәк-яраклар саклый торган әсбап - барысы да үткәннәрнең моңлы кайтавазы.

Кара дермантин белән тышланган репродуктор сугышның кара шаукымы булып керә бу фатирга. Чөнки Ш.Камал аны, нәкъ сугыш башланыр алдыннан 1941 елның июнь урталарында сатып ала. Ул инде өлкән яшьтә һәм авыру булуына карамастан, үзен сугышка җибәрүләрен сорап, хәрби комиссариатка бара. Ләкин, ничек кенә булмасын, аның теләген канәгатьләндермиләр. Сугыш кырына улы Йосыф (Рыбински авиация институтының 3 нче курс студенты) чыгып китә. Кызганыч, аларга очрашу бәхетен Ходай насыйп итми. Йосыф 1944 елда Ржев янында барган сугышларда башын сала.

Йосыфның үлем тырнагыннан язган саргаеп беткән хатлары өстәл тартмасында әле бүген дә саклана.

1941 елның зәмһәрир суыкларында сәүдәгәрдән калган зур чынаяк мичләрне җылытырга ягулык табу кыенлашкач, Ш.Камал өченче бүлмәгә үз куллары белән голландка миче чыгара. Әлеге мичнең җылысы үз тирәсенә караңгы озын төннәрдә язучының бик күп дусларын җыя. Яңа әсәрләр уку дисеңме, сценарийлар буенча фикерләр алышумы - мич бик күп вакыйгаларның шаһите. Сугыштан Казанга санаулы гына көннәргә кайткан язучылар да (Ф.Кәрим, Г.Кутуй, М.Садри, Н.Баян, Ш.Маннур) шушы мичтән җаннарына җылы алып, яңадан яу кырына чыгып киткәннәр. Музейда моннан 15-20 ел элек булучылар да очрашуларда, нишләптер, һәрвакыт шушы мичне искә төшерәләр...

Сугышның беренче көннәрендә үк Ш.Камал үзенең канат астына, беренче бүлмәгә, Ленинградтан күчеп килгән бер гаиләне сыендыра. Үзе исә голландка миче чыккан кечкенә генә бүлмәгә җайлаша.

Дивардагы сәгатьнең телләре ни өчен иртәнге дүртенче яртыда туктап калган соң? 1942 елның 22 декабрендә таң алдыннан Ш.Камалның йөрәге тибүдән туктый. Нәкъ шул вакытта туганнары сәгатьнең телләрен туктатып куялар. Вакыт тукталган, ләкин Вакыт яши. Тынлык булып яши...

Музейның дәвамы Островский урамы. Урам С.Маршак, С.Алышов, В.Бахметьев, Д.Джерманетто, В.Бредель исемнәре белән бәйле. Янәшәдә Тукайның соңгы көннәре үткән Клячкин хастаханәсе. Такташны да соңгы юлга шушы урамнан озаталар. "Ш.Камал музей-фатиры нигезендә татар әдәбияты музее ачарга һәм аның эшчәнлеген алып бару өчен 17 берәмлек штат билгеләргә кирәк", дигән карарны заманында тикмәгә генә кабул итмәгәннәрдер. Бүген музей, җәмәгатьчелек әнә шушы тарихи хатаны төзәтеп, әлеге йортта 20-40 нчы еллар татар әдәбияты музее ачу хыялы белән яши. Әдәби-музыкаль салон һәрдаим үзенең түренә әдәбият сөючеләрне чакыра - кызыклы очрашулар, кичәләр, күргәзмәләр оештыру күркәм гадәткә әйләнде. Музей каршында оештырылган "Акчарлаклар" әдәби берләшмәсендә яшь язучылар каләмнәрен чарлыйлар. Музей - яши. Музей - хәрәкәттә. Гомуммәдәни агымга кушылып, ул да үзенең сүзен әйтергә, фикерен үткәрергә омтыла.

Бәяләмәләр, теләк һәм тәкъдимнәр кенәгәсенә язылган җылы сүзләр дә музейның киләчәгенә якты өметләр уята. "Язучы яшәгән

● Шәриф Камал рухына бер дога.

өйнең бусагасыннан атлап кердек. Мондагы һәр нәрсә безнең өчен изге. Чөнки аларның һәркайсына Шәриф ага кагылган. Без монда әдипнең рухы белән очрашабыз", - дип яза күренекле актер Г.Шамуков 1980 елның 31 октябрендә.

Рәмис АЙМӘТ,
Шәриф Камал музей-фатиры директоры.

Игелек эшлә, игелек күр

Яшәрәсең, Бәкер, яңарасың

"Бәкер" курортына беренче мәртәбә аяк баскан кеше, "Моннан 70 ел элек шундый төзелеш эшләре алып барылды микәнни?" - дип гаҗәпләнер кебек. Чынлап та, курортның дәвалау бүлеге, "Тургай", "Сандугач", "Аккош" дип исемләнгән йоклау биналары әле генә файдалануга тапшырылган, дип уйларсың. Мондагы төзеклекне, чисталык-пөхтәлекне күреп күңел куана. Республикабызда даны еракларга билгеле булган шундый санаторий булу үзе бер бәхеттер. Беренчедән, иң кадерле һәм кыйммәтле ягы шунда ки, табиблары, шәфкать туташлары, барлык хезмәткәрләре үз эшләрен җиренә җиткереп, төгәл башкара, дәваланучыларның ихтирамын тоеп, олы рәхмәт сүзләрен ишетеп яши. Биредә 270 кеше эшли. Икенчедән, Бәкер ләменең һәм күптән түгел генә биредә табылган шифалы суның сыйфаты һәм составы буенча Кавказ һәм Кырым ял йортларындагыга караганда күпкә шифалы булуы ачыкланган.

Нәтиҗәле эшчәнлек курортның техник яктан нык булуына да бәйле. Бу очракта мин җылыту үзәген күздә тотам. Бу цехны курортның йөрәге дип әйтәләр. Чөнки кайнар сусыз монда бер генә тармак та эшли алмас иде. Ләм һәм ванналар белән дәвалауны, ашханә эшчәнлеген, йоклау биналарындагы тормышны кайнар судан башка күз алдына да китереп булмый. Ә җылыту үзәге табигый газга соңгы 4-5 елда гына тоташтырылган. Ә элек күпме мазут, күпме ташкүмер кирәк булган! Мондый шартларда эшләүчеләрнең сәламәтлегенә зыян килү белән бергә, никадәр уңайсызлык китереп чыгарган. "Ходайга шөкер, курорт андый олы мәшәкатьтән котылды", - дип сөенеп туймый баш табиб Фаяз Ибраһимов.

Курортта эшләүче яшьләр бик күп: шәфкать туташлары, аш-су осталары, аш таратучылар, клуб хезмәткәрләре. Бәлки, "Бәкер" курорты шуңа да яшь күренәдер.

Әлеге язмамны һич кенә дә реклама дип кабул итмәсәгез иде. Биредә берничә мәртәбә дәваланган, ял иткән кеше буларак, уй-фикерләрем белән уртаклашып, курорт хезмәткәрләренә олы рәхмәтемне җиткерәсем генә килә. Баш табиб үзе дә әйтә: "Безнең телевизордан, гәзит-журнал битләреннән башкарган эшләребезне мактап чыгышлар ясаганыбыз юк, - ди. - Коллективыбызның иң көчле рекламасы - хезмәт нәтиҗәсе. Бездә бер мәртәбә дәваланып киткән кеше тоташ берничә ел килеп сәламәтлеген ныгыта, үз кешебезгә әйләнә. Менә шундый очраклар бик еш булганга шатланабыз, дәвалану нәтиҗәле һәм файдалы булсын өчен көчебезне кызганмыйбыз. Киләчәктә тагын да уңышлы һәм нәтиҗәле эшләү өчен, берничә каттан торган яңа дәвалау үзәге төзибез. Сүз уңаеннан шунысын да әйтим, төзелеш бары тик үз көчебез белән башкарыла. 1998 елның август аенда нигез салынган дәвалау үзәген, дәваланучыларга уңай булсын, дип, тизрәк җиткерергә уйлыйбыз. Биредә ләм белән дәвалау бүлмәләре дә, ванналар да, массаж ясау, лаборатория эшләре дә башкарылачак, зур гына бассейн, спорт залы һәм башка уңайлыклар булдыру да күздә тотыла".

Бу көннәрдә баш табибның кәефе күтәренке кебек. Чөнки "Татнефть" берләшмәсенең генераль директоры Шәфәгать Тәхаветдинов әлеге төзелешне тиз арада файдалануга тапшыру өчен матди ярдәм күрсәтергә вәгъдә иткән. Бәкердә төзелеш эшләре моның белән генә чикләнми әле: дәваланучыларның ялын кызыклы итеп оештыру максатыннан, биредә кафе-бар, теннис, бильярд бүлмәләре, "Бәкер-су" дип исемләнгән кечкене ресторан эшли башлаган. Ял итүчеләр рәхәтләнеп туган көннәрен, бәйрәмнәрне билгеләп үтә алалар. Моның өчен кечкене ресторанда бөтен мөмкинлекләр бар: ял итүчеләргә үз һөнәрләренең осталары хезмәт күрсәтә.

Заманча зәвык белән төзелгән, якты, чиста һәм пөхтә итеп җиһазландырылган залда салмак кына музыка ишетелеп тора, ап-ак эскәтерләр җәелгән, өстәлләрдә алма, апельсин һәм төрле тәмле сулар бар. Теләгән кеше чәй, кофе сорап ала. Бу яңалыклар, дәваланучылар өчен өстәмә уңайлыклар тудыру белән бергә, курорт кассасына күпмедер күләмдә акча туплауда да нык ярдәм итә.

Төзелеш планнары моның белән генә чикләнми әле. Яшьләрнең торак проблемасын хәл итү өчен 48 квартиралы йорт салуга дәвалау үзәген төзүне тәмамлауга ук тотыначаклар икән. Җәй көннәрендә ял итүчеләр өчен курорттан бер чакрым ераклыкта гена су керү, кояшта кызыну өчен пляж һәм курорт территориясендә ясалма күл булдыру күздә тотыла. Материаль-техник база соңгы берничә елда уңай якка нык үзгәргән: кирәкле күләмдә техника, чистарту җайланмалары, йөк һәм ашамлык ташу машиналары, ялга килүчеләрне каршы алып, аларны озату өчен махсус автобуслар - болар барысы да курортның аягында нык басып торуын раслый.

Ничек кенә булмасын, Фаяз әфәнде курортның иң зур байлыгы, потенциаль көче итеп, биредә эшләүче хезмәткәрләрне мактап телгә ала. Аларның кайберләре белән таныштырып китим. Табиблар Наилә Галиева, Камилә Войкова, Җәмил Шәмсетдинов, Васил Әхмәтҗанов, алтын куллы теш врачы Ренат Саттаров, өлкән шәфкать туташы Раушания Ягъфәрова, ләм бүлеге шәфкать туташы Дилә Әюпова, ванна бүлегендә һәркемне елмаеп каршы алучы Венера Әхмәтҗанова, массаж ясау осталары Зөлфия Шакирова, Миләүшә Гыймаева, физиотерапия бүлеге шәфкать туташы Нәкыйбә Сәләхова, ләм бүлеге хезмәткәрләре Хаҗи Гыйләҗев, Рушан Бикчурин, җыештыручылар Миңниса Вәлиуллина, Әнисә Зәкмәнова, шеф-пешекче Миңнур Хамматова, пешекчеләр Заһира Хәкимова, Зәйнәп Фәррахова, диетсестра Халисә Латыйпова һәм башкалар курортның ышанычлы хезмәткәрләре. Курортка бер сменага җәй айларында 600, ә кыш көннәрендә 500 кеше килүен исәпкә алсак, мондагы хезмәткәрләрнең башкарган эш күләмен күзаллавы кыен булмас. Монда табиб билгеләгән барлык дәвалау күрсәтмәләре вакытында, төгәл һәм тиешенчә үтәлә.

Курортның клуб эшчәнлегенә тукталмасак, һич кенә дә килешмәс. Беренчедән, клубта Гөлшат Фәйзуллина, Рәхимә Әхсәнова, Рәфис Нуриәхмәтов кебек үз эшләрен яратып, вакыт белән санашмыйча, дәваланучыларның ялын кызыклы оештыручы белгечләр бар. Икенчедән, баш табиб, үзе дә сәнгатькә, җырга-моңга гашыйк кеше буларак (Фаяз Ибраһим улы оста гармунчы, җырчы, биюче һәм шигырьләр язу белән дә шөгыльләнә), клуб эшчәнлегенә тиешле игътибар итә. Клубка менә дигән ремонт эшләткән, яңа уен кораллары, тавыш көчәйтү аппаратлары сатып алган. Сәхнә бизәлеше дә мәртәбәле концерт залларыннан бер дә калышмый; кыйммәтле тукымалардан сәхнә пәрдәләре эленгән, сәхнә яктыртылган, киенү, грим бүлмәләре җиһазландырылган. Шуңа да, бирегә артистлар еш килә, ял итүчеләр дә җыр кичәләрендә бик теләп катнашалар.

Җыеп кына әйткәндә, биредә барысы да кеше өчен эшләнә, Бәкер курорты күзгә күренеп яшәрә, яңара. Шуңа да күренекле шагыйрәбез Гөлшат Зәйнашеваның "Яшәрәсең, Казан, яңарасың" дигән шигырендәге "Казан" сүзен "Бәкер" сүзе белән алмаштырып, "Яшәрәсең, Бәкер, яңарасың" дип көйгә салып җырлыйсы килә.

Рафаэль ИЛЬЯСОВ,
Татарстанның халык артисты.

● *"Бәкер" курорты капкасы.*
● *"Сихәт" чишмәсе.*
● *Баш табиб Фаяз Ибраһимов.*
● *Шәфкать туташлары Роза Җиһангирова, Рәхилә Фатихова, Оркыя Сөләйманова.*
Мидхәт ШАКИРҖАНОВ фотолары.

Әлеге дә баягы

Татар укучысына порно, секс-мекс кирәкме?

Гаврилов урамындагы азык-төлек кибетендә гәзит-журналлар сата торган почмак бар. "Мәдәни җомга" гәзитенә 2 нче яртыеллыкка язылмыйча калган идем. Моннан алып булмасмы, дип, сатучыдан: "Мәдәни җомга" бармы, дип сорыйм.

- Эта татарская газета что ли?

- Әйе, - дим.

- У нас татарские газеты в продаже не бывают, вообще их не берут.

Минем өчен бу җавап башка яшен суккандай булды. Әмма нәтиҗә ясарга ашыкмыйк.

Яшел Үзән шәһәренә барышлый электричкага билет алдым да "Ватаным Татарстан" яки булмаса "Шәһри Казан" гәзите укып кайту нияте белән киоскка юнәлдем. Вокзалның беренче каты гәзит-журнал, китап сатучылар белән тулган. Ник берсендә татарча гәзит-журнал булсын.

Вагонда да гәзит-журнал сатучылар йөреп кенә тора. Аларда да Мәскәүдә чыга торган, детектив, порно, секс турындагы басмалар. Буа, Яшел Үзән ягына күпме татар да кайта-китә. Татар кешеләре нәрсә укыйлар икән? Интим темага язылган материалларны укып утыралар.

Китап сату кибетләрен әле саклап кала алдык. Анысына сөенеп бетә алмыйм. Казанда шактый төгәл статуска ия булган китап кибетләребез бар. Әмма татар китабы бүлекләре бу кибетләрдә дә нибары 7-8 квадрат метр урын алып тора. Татар халкын үз өебездә дә кысу бара, дигән сүз түгелме соң бу? Без һаман иркен мәйданга чыга алмыйбыз.

Көчләү, урлау, детектив темаларга язылган китаплар безнең яшьләребезне тәрбияләүгә берниндә уңай тәэсир итә алмый. Ә бит элекке елларда, башкача әйтсәк, социализм чорында мондый хәл юк иде. "Ватаным Татарстан", "Татарстан яшьләре" гәзитләрен, "Сөембикә", "Казан утлары", "Чаян" журналларын Казанның һәрбер гәзит-журнал киоскыннан алырга була иде. Ә хәзер кайсы гына киоскка мөрәҗәгать итмә, җавап бер: "Татарча гәзит-журналлар юк", "Укымыйлар". Бу - сәер хәл. Аның белән берәү дә кызыксынмый.

Республикада татар телендә гәзитләр, журналлар күп чыга. Аларны халыкка сату да тиешенчә оештырылса ничек әйбәт булыр иде. Минемчә, Казанның һәрбер районында чын мәгънәсендә җиһазланган гәзит-журнал киосклары булдырырга кирәк. Анда республикада чыга торган барлык гәзитләр, журналларның да булуы зарури.

Татар телендә чыга торган көндәлек матбугатсыз аны дәүләт теле дәрәҗәсенә күтәрүгә ышаныч юк. Элекке депутатлар татар телен чын дәрәҗәдә дәүләт теле итә алмадылар. Дәүләт Советында ике телнең тигез дәрәҗәдә булырга тиешлеге турындагы сүзләр әлегә нәтиҗәсез кала бирә. Бәлки, яңа сайланган депутатлар туган телебезнең дәүләт теле булып күтәрелүенә ирешә алырлар.

Рафаэль САЛЬМУШЕВ.

Шагыйрь, прозаик, драматург, Татарстанның Г.Тукай исемендәге дәүләт бүләге иясе, республиканың атказанган сәнгать эшлеклесе Әхсән Баянның әле генә 33 нче китабы дөнья күрде. Исеме - "Кызыл ут". Ул хакта сөйли башлаганчы, әдипнең тәрҗемәи хәле турында бераз гына сүз әйтү урынлы булыр.

Булачак язучы 1927 елның 8 декабрендә Башкортстанның Илеш районы Әшмән авылында туган. Урта белемне туган ягында ала. 1956 елда Казан дәүләт университетының татар теле һәм әдәбияты бүлеген тәмамлый. Егетне редакцияләр эшкә кодалыйлар. Башта ул "Социалистик Татарстан" гәзитендә эшли, 1962 елдан алып 1981 елга кадәр "Казан утлары" журналында җаваплы секретарь, баш мөхәррир урынбасары вазифасын башкара.

Җирдә Прометей бар

Минемчә, укучыга Әхсән Баян турында әлләни тәфсилләп сөйләүнең кирәге дә юк. Драматик әсәрләреннән, мәсәлән, "Зәңгәр кыңгыраулар" дигән, ике бүлектән торган телеспектакльне, Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры спектакль итеп куйган "Күзләре нинди иде" исемле драманы искә төшерү дә җитә. Без аны "Һәйкәл", "Алтын кашлау", "Кара кош" трагедияләре, "Яшел мәйдан", "Диңгез шавы", "Мират", "Сез аңларсыз мине", "Сәяхәтнамә", "Кышкы чәчәкләр" кебек поэмалар авторы буларак та беләбез. Боларга "Ут һәм су", "Таш китап" романнарын да өстәргә кирәк.

Алдан ук шуны әйтик: Әхсән Баян әсәрләрен өстән генә, йөгертеп кенә укып булмый. Алар хакында кат-кат уйланырга,автор нәрсә әйтергә теләде икән, дип, шактый баш ватарга туры килә. Бу аның язу стиленә бәйләнгән: реалистик тормыш күренешләре романтик, символик образлар аркылы бирелә. Сюжет-композиция төзелешендә дә ул еш кына шартлы алымнарга мөрәҗәгать итә. Икенче төрле әйткәндә, бу әдипнең ижаты шул яклары белән башкаларныкыннан аерылып тора. Кайберәүләр өчен бу үзенчәлекләр ят булып тоелды бугай. Шуңадыр, бу киң колачлы талант иясенә үз вакытында тиешле бәя бирелмәде. Минем әле дә: "Ни өчен Әхсән Баянга әлегә кадәр Татарстанның халык язучысы яки шагыйре дигән исем бирелмәде икән?" дигән сорауга җавап таба алганым юк...

Бу хакта мин беренче мәртәбә генә язмыйм (чөнки башкача аңлаучылар бар): язучы, шагыйрь, гомумән, ижат кешесе, ул моны телиме-юкмы, сәясәт өлкәсенә "кагылырга" мәҗбүр. Мәсәлән, әдип татар яшьләрен татар менталитеты рухында, халкыбыз традицияләре үрнәгендә тәрбияләүгә өлеш кертә икән, бу сәясәт булмый ни булсын! Шуңа күрә коммунистлар партиясе язучылар эшчәнлеген даими рәвештә күзәтте генә түгел, "сыйнфый күзлек аша карап" ижат итәргә кушты...

Иң элек шундый бер "теоретик концепциягә" тукталыйк. Бу - шәхеснең нинди дә булса идеологиягә инануы. Сәясәт исә - идеологиянең бер өлеше һәм аны пропагандалаучы гына. Әхсән Баян ижатына мин әнә шул позициядән чыгып якын килергә тырыштым. Шагыйрь, "сәясәтче икәнен ачып салмас өчен", космик категорияләргә, дастаннарга мөрәҗәгать итүне кулай күрә. Мәсәлән, "Җирдә Прометей бар" дигән шигырьнең герое үзен богаулаучыларга, йөрәк итен кимерүчеләргә нәфрәт белән болай ди:

Ялчылыкта узган
шат гомереңә синең
Бер көнемне алмаштырмас идем!

Яктылыклар җирдә сүнмәс булса,
Кирәкми безгә берни.

Прометей кешеләргә ут биргән. Һәм, күпме генә газаплар кичермәсен, ул - бәхетле. Чөнки миллионнарны бәхетле иткән! Быелның 28 гыйнварында Мирсәет Солтангалиевнең тоталитар система тарафыннан юк ителүенә 60 ел була. Шул уңайдан миңа да гәзит-журналларда чыгыш ясарга туры килде. Мин шуны аңладым: әгәр бөек якташыбыз үз халкын, башка изелгән халыкларны яклап кискен чыгышлар ясамаса, һичшиксез, "Сталин обоймасында" йөрер яки чит илгә күчеп китәр иде.

Әмма ул, аңлы рәвештә, изелгәннәр өчен үзен корбан итә... Ә.Баянның "Җир - җиһанда берәү генә" шигыре дә бүгенге чынбарлык белән аваздаш. Шагыйрь Җир-анабызны яклый:

Уйлыйм: Җир янса, минем дә
Ут булып очар җаным...
Дөнья, сине шартлатырга,
Юк, мин ирек куймамын, - ди.

Моннан 40 еллар элек дөнья җәмәгатьчелегендә "Нейтрон бомбаны эшләргәме, әллә аны эшләүне тыяргамы?" дигән бәхәс купкан иде. Галимнәр, сәясәтчеләр, гомумән, алдынгы карашлы зыялылар андый бомба булдыруга нык каршы чыктылар. Сәбәбен күзаллау өчен кечкенә аңлатма китерик: атом бомбасы шартлаганда 1000 градус кызулык хасил була, радиация нык тарала. Водород бомбасы шартлаганда температура 26-30 мең градуска җитә. "Международная жизнь" журналында мондый сүзләрне укыган идем: әгәр Мәскәү белән Казан арасында - уртада 100 мегатонналы водород бомбасы шартласа, бу ике башкаладан хәрабәләр генә торып калыр, тереклек бөтенләй бетәр иде.

Ә нейтрон бомбага мәдхия җырлаучыларның "аңлатмасы" болай: Нейтрон бомба шартлаганда йортларга, каралтыларга һичбер зыян килми, тереклек, җан ияләре генә юкка чыга, икән. Янәсе, бу бомба бик гуманлы миссия башкарачак. Әхсән Баян исә "Нейтрон кояш" дигән шигырь язды. Анда мондый юллар бар:

Җиргә тормыш сипкән
Кояш урынын
Әгәр алса үлем чәчкән кояш,
Бәхәс, ярыш тынар:хаклы, хаксыз,
Гаепле һәм гаепсезләр булмас.

Бу да мәсьәләнең бер ягы гына. Икенчесе шул: соңгы елларда халык, яшәеш өчен экологик куркыныч алга килеп басты. Бу нәрсә Казаныбызны да читләтеп үтми. Ә бит анда миллионнан артык кеше, әллә никадәр башка җан ияләре яши... Бер караганда, яшәү урыныбыз, Ходайга шөкер, әйбәт. Башкалабыз ярларын Идел, Казансу елгалары юа. Кабан күле дә һаваны чистартуга өлеш кертә. Яшеллек тә бар. Мин дә шулай дип куанып йөри идем. Әмма шушы арада гына җирле бер гәзиттән укыдым, халыкара нормага җиткерү өчен Казанда яшеллекне тагын 5 тапкыр арттырырга кирәк икән!

Шагыйрь "Кызыл ут" әсәрендә, тирән борчылуын белдереп, болай ди:

Казан, Казан,
нишләттек без сине?!
Сулыш алу синдә ник читен?
Күзгә күренеп ага өстә сөрем,
Урамнарың тулы күк төтен.

Боларга өстәп, шуны гына әйтәсе кала: Мәскәүдә "Оргсинтез" оясы юк. Ә Казанда бар. Мәскәү уртасында нефть эшкәртү заводы юк. Ә Уфада - бар. Ярый әле, Аллаһ саклагандыр, "Тататом" станциясен төзеп өлгермәдек. Югыйсә, эшләр харап иде бит...

Җыентыкта урын алган "Ике башлы бөркет" шигырен Ә.Баян 1993 елда иҗат иткән. Бу тема, яшермик, бик күпләребезне борчый, йокыбызны ала. Патша заманыннан калган бу кош, беркемнән дә, депутат әфәнделәрдән дә сорамый гына, күз алдында Кремль атрибутына әйләнде, байракларга, акчаларга кунды. Кем өчендер бу, бәлки, әлләни баш китәрлек нәрсә түгелдер, әмма без моңа һич тә битараф кала алмыйбыз. Чөнки, шагыйрь сүзләре белән әйтсәк:



Ике башлы - гарип кара бөркет
Татар бәгърен күпме чукыды!

Шулай да, мәсьәлә тәреләр, эмблемаларда гына түгел. Кызыл байраклы, кызыл йолдызлы, урак белән чүкечнең берләшүен девиз иткән совет чорында милләтебез юкка чыгу алдына басты. Чынлыкта ике башлы кара кош 400 елга якын йөрәк итебезне ашап-чукып торса да, татар милләте яшәүдән туктамады, иң кыен шартларда да үз йөзен саклап калды, ә кызыл әләмле режим 50-70 ел эчендә бик күп халыкларны йотты. Чират безгә дә җиткән иде. Һәм бу һич тә арттырып әйтү түгел...

Демократия җилләре бераз исә башлагач, милләтнең үсүенә, терелүенә юл ачылды. Шактый санда милли балалар бакчалары, мәктәпләр, лицейлар, гимназияләр эшли башлады, татар матбугатының үсү, киңәюенә мөмкинлек туды. Әмма "ассимиляция афәте" шулкадәр көчле булган ки, халыкның милли үзаңын тиешле дәрәҗәгә күтәрү өчен озак еллар таләп ителәчәк. Мөгаен, һәммәбезнең тырышлыгы, шагыйрьнең догалары милләтебезне тарих аренасында саклап калыр дигән өмет бар. Шагыйрь болай ди:

И син, Тәкъдир,
кодрәтләрең киңдер,
Бир син безгә, бир хәерле гомер.
Оялмаслык булсын үзебез өчен,
Оялмаслык булсын илебез өчен.
Бир абруйлы гомер.
Кем әйтмешли, бирсен Ходай!

Үз чиратында, урыс шовинистларының иң яраткан "монологы" шул иде: "Безнең артта сөйрәлүебезгә, үзебез түгел, татар, нимес, швед һ.б. гаепле". Җыентыктагы "Гаеп эзләмәгез бездән" (империя тарафдарлары зары), "Урта гасыр авазы", "Җиңелү парады", "Сугыш фәрештәсе", "Без - тарихта эзлебез", "Саклый алсак" кебек шигырьләр әнә шул хакта...

Күп шагыйрьләрнең төп иҗат лейтмотивы булып мәхәббәт, илаһи хисләр дөньясы тора. Кайчак мин, беркатлы гына итеп, мәхәббәт темасы булмаса, шагыйрьләр нәрсә турында язарлар иде икән? - дип уйлап куям. Бәхәскә керү кирәкми, В.Белинский, мәхәббәт ул - тормышның поэзиясе, дигән. Әмма болай әйтү генә "мәхәббәт" төшенчәсенең эчтәлеген ачмый. Л.Толстойның, мәхәббәт ул яраткан кешең өчен яшәү, дигәне дә гомуми сүзләрдән узмый... Бу аңлашыла да кебек, чөнки һәркемнең мәхәббәте үзенчә ич. Һәм юкка гына безне индивидуумнар дип атамыйлар да инде. Әхсән Баянның югарыда әйтелгән җыентыгына килгәндә, анда "рафинадлаштырылган мәхәббәт" турында шигырьләр юк. Бу минем өчен үзенә күрә бер ачыш булды. Кем белә бит, бәлки бу - артык тыйнаклыктандыр, "интим хисләр капчыгын ятлар алдында чыгарып селкергә" теләмәүдәндер...

Чыннан да шагыйрьнең мәхәббәте башкачарак бит. Ул:

Язгы һава сөю белән тулы,
Шул сөюне сулый табигать.
Карлыгачлар бәйрәм итә күктә -
Җирдән күчкән бугай бу гадәт,

- ди...

Шагыйрьнең мәхәббәте иң элек туган халкына, газиз иленә багышлана һәм "Шагыйрь сүзе" шигырендә ул болай яңгырый:

Мин җәядән сиңа ук атмадым,
Авыртмасын, диеп, йөрәгең.
Өзелерлек тартып
күңелем кылын,
Сөюемне сиңа җибәрдем.

Ә.Баянның проза әсәрләре, аларның теле турында миңа узган елда сокланып язарга туры килгән иде. Әйе, әдип сүз сайлаганда гаҗәеп талымлылык күрсәтә, бу исә поэтик образлар тудыруга ярдәм итә. Шагыйрьдә ясалма патетика да, "сүз боткасы" да юк. Шул уңайдан аның бик күптәннән - 1953 елда язылган бер шигыреннән өзек китерик:

Гашыйк булма миңа,
чибәр кызый,
Каушап алай аска карама.
Йөрәгемә күптән ия бүтән -
Йөрәгем минем калган калада.

Образлы әйтемнәргә килгәндә, алар Ә.Баян өчен - гадәти хәл. Мәсәлән, "Көзге моңнар" шигыренең беренче строфасы болай "моңлана":

Көз йөри, йөри әйләнеп
Яланнар, кырлар аша.
Көз - минем җаным, талчыгып,
Урман эченә кача.

Җыентыкның "Бизәксез сурәтләр" бүлегенә тупланган шигырьләр юморга бай. Бер генә мисал китерик:

Бабаң булган Зарифулла,
Ә атаң - Гарифулла.
Ә үзең кяфер икәнсең
Син, әстәгыйфирулла.

Нәтиҗә. Җыеп кына әйткәндә, Әхсән Баянның "Кызыл ут" китабы укучылар өчен үзенә күрә затлы бер бүләк булып тора. Шагыйрьнең һәр әсәрендә күңелне тибрәндерерлек уй-фикерләр, хис-тойгылар бар. Шуңа күрә, алар безне битараф калдырмыйлар.

Мәхмүт ӘХМӘТҖАНОВ.

Бу баш ник авырта икән?

Баш авырту - бик күп авырулар юлдашы ул. Сәламәт кешеләрдә дә физик яктан арыганда яки нервлар какшаганда, стресс нәтиҗәсе буларак, баш авыртырга мөмкин. Халык медицинасы баш авыртканда түбәндәге дәвалау чараларын тәкъдим итә:

■ Җылы ваннада коену яки аякларны, йә кулларны җылы суга тыгып тоту;

■ Бер стакан кайнар бөтнек төнәтмәсе эчү;

■ Башка тыгыз итеп яулык бәйләп, аяклар һәм куллар (һәм баш та) тигез булырлык итеп чалкан ятып тору;

■ Эчәкләрне бушату;

■ Маңгайдан баш чүмеченә таба башка массаж ясау.

Мигрень булганда:

■ Камфара һәм нашатырь спирты кушылмасын иснәү;

■ Колакка суган яки чөгендер суында чылатылган (җылы!) мамык яки бинт кисәге тыгып тору;

■ Чигәләргә чүпрәккә салынган кәбестә куеп, башны сөлге белән урау;

■ Яңа гына өзелгән каланхое яфрагы суын сыгып, башка компресс ясау;

■ Кипкән мәтрүшкә чәчәкләрен иснәү;

■ Башның авырткан җиренә кәбестә яфрагын ябып тору;

■ Авырткан җиргә сирин яфрагын ябу;

■ Баш чүмеченә һәм колак арты сөякләренә горчичник куеп тору;

■ Шул ук җирләргә уылган кара торма компрессы куярга да була.

Сарымсак — әлмисак дәвасы

Сарымсак берничә мең еллар буе халык медицинасында кулланыла. Төрле авырулардан сакланыр өчен полководец Александр Македонский үз гаскәрләрендәге сугышчыларга һәр көн 1-2 сарымсак тараттыра торган булган.

Сарымсакта кан юлларына тромблар, кан юллары стеналарына холестерин утыруны булдырмый торган матдәләр бар. Шуңа күрә йөрәк-кан юллары авыруларын булдырмау өчен сарымсак иң сыналган чара булып тора. Бүген Русиядә һәм чит илләрдә сарымсак нигезендә ясалган күпсанлы дарулар эшләп чыгарыла. Ләкин һаман дару йотып тору һич мәҗбүри түгел. Америкалылар, мәсәлән, көн саен сарымсакны "тере килеш" су белән йоталар, болай иткәндә аның әчесе авызны яндырмый.

ТАЗАРЫРГАМЫ, ЯБЫГЫРГАМЫ?

Диета тотып интеккәнче, ачлыкны сиздермәүче табигый ризыклар ашау хәерлерәк. Өстәвенә, алар кешенең физик һәм психик халәтенә уңай йогынты ясыйлар.

Банан. Бу тропик җимештә триптофан, аминокислота бар. Алар организмда серотин эшләп чыгаралар. Ә серотинны "бәхет наркотигы" дип йөртәләр. Ул сырда, эремчектә һәм солы ярмасында да бар.

Кузаклылар, борчак һәм чикләвек. Аларда аппетитны йөгәнли һәм кәефне күтәрә торган матдә - альбумин бар.

Йод. Ул калкансыман бизнең нормаль эшләве өчен кирәк. Өстәвенә, матдәләр алмашуны да юлга сала. Йод суганда, диңгез балыгында, йодлы тозда була.

Углеводлар. Икмәктә, яшелчәләрдә, җиләк-җимештә була.

Шикәр. Җимешләрдә, балда һәм өрәңге яфрагы сиробында була. Мондый табигый шикәр канда шикәр артуга йогынты ясамый, әмма кеше организмындагы шикәргә булган ихтыяҗны канәгатьләндерә.

ВАСЫЯТЬНЕ ничек язарга?

Өлкән яшьтәге кеше бакый дөньяга якынлашуын, хәләл хезмәт белән табылган мал-мөлкәтен балаларына, якыннарына васыять итеп калдырырга вакыт җиткәнен белә. Ә менә аны ничек язарга? Васыять ничек язылырга тиеш соң? Мәсәлән, авырып, хастаханәгә кергән кеше язарга теләсә?

Бу гамәлне тормышка ашырганда нотариуска мөрәҗәгать итәләр. Нотариаль конторада нотариус бу эшне ничек башкарырга кирәклеген аңлатып бирә һәм рәсмиләштерергә булыша. Ә инде хастаханәдә яткан кеше васыять язарга ниятли икән, ул хастаханәдә дә төзелә ала. (Әлбәттә, әгәр кеше үзенең алдагы язмышы өчен борчылса). Мондый очракта васыятьне раслау хокукы баш табибка, дәвалау буенча баш табиб урынбасарына һәм дежур табибка бирелә. Болардан тыш, васыятьнең төрлечә төзелүен дә белү мөһим.

Беренчедән, васыятьтә бөтен мал-мөлкәтне берәмтекләп санап чыгып, шәхси имза куеп раслап була. Икенчедән, бөтен мал-мөлкәтне санап чыкмыйча, "Мин үлгәнче минеке булып саналган бөтен мал-мөлкәт, ул нәрсә генә һәм кайда гына булса да", дигән гомуми сүзләр белән дә чикләнергә мөмкин. Васыять менә шушы соңгы формада язылса, варислар нотариуска теге яки бу мал-мөлкәтнең чыннан да нәкъ менә сезгә мирас ителүен һәм сезнеке булуын раслаучы документлар китерергә тиеш була.

Һәм, өченчедән, васыять аерым бер мөлкәт өчен генә, мәсәлән, фатир яки машина өчен генә дә язылa ала. Башка төр мал-мөлкәтне васыятькә кертмичә дә калдырып була.

Почмакка басмагыз

Биофизик һәм биоэнергетик галимнәр бушлыкларның сызыкларын тикшергәннән соң, шундый нәтиҗәгә килгәннәр: эш урыны да, карават та, ял итә торган кәнәфи дә почмакта булырга тиеш түгел. Почмакта, автоматик рәвештә, энергия "суырыла". Шуңа күрә, энергиясе ташып торган артык шук баланы почмакка бастырсаң, ул аннан инде уйнарга теләге тәмам суынып, суырылып чыга. Уйнарга аның хәле калмый - аны почмак "суырган, ашаган" була.

Җавап-сорау

Кайчак кибеттә авокадо дигән җимеш саталар. Чит илдә үскән бу җимеш турында мәгълүмат бирегез әле.

Сания С. Казан.

Авокадо - мәңге яшел тропик агач җимеше. Өлгергән авокадоның буе 20-25 см, 100 г җимештә 220 килокалория һәм А дан К га кадәр барлык витаминнар бар. Бу җимешнең кабыгы җиңел салына, ләкин ашарга ярамый. Аның ачык сары йомшагын гына ашыйлар. Җимешнең тәмам өлгергәне генә файдаланыла. Урталай ярылган авокадоны, төшләрен алгач, салат савыты итеп кулланырга да була. Мәсәлән, аңа балык, креветкалар яки сыр салып куярга мөмкин. Мондый савыттан ризыкны кашык белән аз-азлап, салат һәм җимеш йомшагы белән бергә алып ашыйлар. Салат беткәч, кабыгы өстәлдә кала.

Кәҗә сөте бик файдалы, диләр. Бигрәк тә туберкулездан. Шул дөресме икән?

З.ГАЛИЕВА.

Кәҗә сөте составы белән сыер сөтенә якын, ә кайбер күрсәткечләре буенча аны уздыра. Кәҗә сөтендә кальций, магний, тимер һәм җиз сыер сөтендәгегә караганда артыграк. А витамины сыер сөтендәгедән 2 мәртәбәгә, каротин - 3, аскорбин кислотасы - 1,5, РР витамины 3 мәртәбәгә артыграк. Кальций һәм фосфорның күп булуы рахит белән авырган балалар өчен кәҗә сөтен аеруча алыштыргысыз итә. Кәҗә сөтендә сөт шикәренең (лактоза) сыер сөтендәгегә караганда азрак булуы нәтиҗәсендә, эче кибә торган кешеләр аны җиңелрәк эчә.

АЙГА кырын карама

Кояш, Ай һәм башка планеталарның табигатькә, җан ияләренә, шул исәптән кешегә дә тәэсире бик борынгы заманнардан билгеле булган. Мисал итеп Айның су күтәрелешенә һәм чигенешенә тәэсирен искә алу да җитә. Кешедә дә байтак күләмдә су бар. Шунлыктан Ай кешенең сәламәтлегенә, халәтенә, эшчәнлегенә йогынты ясый. Шуны истә тотып, Айның кешегә тәэсиренә бәйле киңәшләрне күпмедер чагылдырган календарьне тәкъдим итә башлыйбыз.

5 февраль** (шимбә). 1420 нче һиҗри ел. **Шәүвәл аеның 29 нчы көне.

Кояш өлешчә тотыла (Мәскәү вакыты белән 15 сәгать 50 минутта).

16 сәг.05 мин. Яңа ай (Бата - 16.10, калка - 7.38). 30/1 нче ай тәүлеге (1 нче фаза). Ай Сукояр йолдызлыгында.

Көнчыгыш календаре буенча бүген Яңа - Ак аждаһа елы башлана. (Ел буена үпкәләрне һәм калын эчәкне уңышлы дәвалап була). Бу көнне мөһим эшләр башлау мәслихәт түгел. Әмма киләчәккә планнар кору хуплана. Чөнки күз алдына китергән уй-фикерләрегез тормышка ашуы бик ихтимал. Шуңа күрә начар-яман уйларыгызны, борчуларыгызны онытып торыгыз. Бу көнне туганнарыңа, дусларыңа кунакка бару уңай тәэсир итә. Әмма Яңа елны каршылаганда исерткеч эчемлекләр, әче һәм кайнар ризыклар белән мавыкмагыз. Чөнки бу ай көнендә биоритмик яктан актив булган ми эшчәнлегенә зарар килүе ихтимал.

Шулай ук бу көнне җитди операцияләр ясарга киңәш ителми. Кеше үзен хәлсез итеп сизә, әледән-әле йокыга тартыла, төшенкелек (депрессия), ялгызлык хисе кичерә. Шунлыктан көн буена күңел күтәренкелеген саклагыз һәм нерв-психик авыруларга аеруча игътибарлы булыгыз. Барлык хроник авырулар, сөяк һәм буыннар сызлавы, теш авыртуы көчәергә мөмкин. Кайбер әгъзаларда таш барлыкка килә. Организмның суынуына юл куймагыз. Өйне тәртипкә китерү, чистарту - бик күркәм эш. Шулай ук маңгай һәм гаймор куышлыгын (өске казналыкта борын янындагы сөяк куышлыгы) чистарту да файдалы. Кояш тотылганчы һәм аннан соң 2 сәгатьтән артык физик көч кулланмагыз.

***6 февраль** (якшәмбе). **Зөлкагдә аеның 1 нче көне.** 1/2 ай көне (яңа айның 1 нче фазасы). Ай Сукояр/Балык йолдызлыкларында).*

Бу көнне нерв системасы һәм күзләр йомшак-пассив була. Аяк буыннарына операция ясарга, кара кан тамырын киңәюдән дәваларга, сөялләрне кисәргә, электр-магнит тәэсирен файдаланып сәламәтләндерү ысулын кулланырга киңәш ителми. Тешләрне дәвалау өчен бик уңайлы көн. Йөрәк һәм кан тамырларын ныгыта торган физик күнегүләр ясау һәм су белән дәвалану, шулай ук психотерапевтик сәламәтләндерү ысулын куллану файдалы. Җиләк-җимеш, яшелчә, туклыклы бөртектән эшләнгән ботка ашлары файдалы. Майсыз һәм тозсыз диета кулланалар.

***7 февраль** (дүшәмбе). **Зөлкагдә аеның 2 нче көне.** 2/3 нче ай көне (яңа айның 1 нче фазасы). Ай Балык йолдызлыгында.*

Аяк бармакларына, сеңер һәм буыннар тоташкан урыннарга операция ясарга киңәш ителми. Тире авыруларга тиз бирешүчән була. Шуңа күрә тире авыруларын, кан әйләнеше һәм барлык лимфа системаларын дәвалауны кичектереп тору хәерле.

Грипп кебек күпләп таралган йогышлы авырулар белән зарарлану куркынычы көчәя. Гөмбәчек авырулары белән зарарлану ихтималы да бар. Баш арты, җилкә, колак яны авыртырга мөмкин. Җилкәгә горчичник куярга, буыннарны яза торган күнегүләр ясарга кирәк. Эчәк һәм ашказаны-эчәк трактына бәйле операцияләр ясарга һәм андый авыруларны дәваларга мөмкин. Сауна һәм мунча керү файдалы.

***8 февраль** (сишәмбе). **Зөлкагдә аеның 3 нче көне.** 3/4 ай көне (яңа айның 1 нче фазасы). Ай Балык йолдызлыгында.*

Бу көнне кан әйләнеше һәм барлык лимфа системалары йомшак-пассив була. Гөмбәчек авырулары белән зарарлану һәм аллергия көчәергә мөмкин. Аяк бармакларына һәм сеңерләргә, буыннар тоташкан урыннарга операция ясарга киңәш ителми. Шулай ук аякка каты басып йөрүне киметергә кирәк.

Эчәк һәм ашказаны-эчәк трактына операция ясарга һәм аларны дәваларга мөмкин.

Саунага һәм мунча керергә рөхсәт ителми.

Су буенда ял итү, урманда җәяү йөрү яхшы нәтиҗә бирә. Дарулар куллануны чикләгез. Аш-суга игътибарны көчәйтегез. Чөнки бу көнне организм азыкны аеруча яхшы үзләштерә.

***9 февраль** (чәршәмбе). **Зөлкагдә аеның 4 нче көне.** 4/5 ай көне (яңа айның 1 нче фазасы). Ай Балык/Кучкар йолдызлыкларында.*

Баш мие, күз һәм колак зәгыйфь-пассив чак. Шуңа күрә нейрохирург катнашындагы казналык-бит операцияләре, шул исәптән пластик һәм косметик операцияләр ясауны кичектереп тору хәерле. Иң яхшысы - теш һәм күз табибларына бармау. Күп укып һәм кампитрда озак эшләп үзегезне ялыктырмагыз. Чөнки кәеф бу көнне болай да начар була. Бөерләрне һәм бәвел чыгару юлларын дәваларга һәм аларга операция ясарга мөмкин.

Организм ризыкны тулысынча эшкәртеп бетерә. Ач тору зарарлы. Чәч алдыруны да кичектерергә кирәк.

***10 февраль** (пәнҗешәмбе). **Зөлкагдә аеның 5 нче көне.** 5/6 ай көне (яңа айның 1 нче фазасы). Ай Кучкар йолдызлыгында.*

9 февраль көнендәге киңәшләр үз көчендә кала. Шулай ук бронхлар, югары сулыш юллары авыруы көчәергә мөмкин. Шунлыктан сулыш алу күнегүләре ясарга, югары сулыш юлларын чистартырга, пульмонологка барырга киңәш ителә. Организмны яшәртү процедуралары файдалы.

Бу көн чәчтарашка бару өчен бик уңайлы.

***11 февраль** (җомга). **Зөлкагдә аеның 6 нчы көне.** 6/7 ай көне (яңа ай, 1 нче фаза). Ай Кучкар йолдызлыгында.*

Бу көнне җилкә, терсәккә чаклы куллар, үпкә, нерв системасы бик актив, әмма бугаз-тамакка, тавыш ярыларына һәм калкансыман бизгә операция ясарга, аңкау (гланда) һәм йоткылык (аденоид) бизләрен кисәргә киңәш ителми. Чөнки эндокрин системасы актив булмый. Ангина, фарингит авырулары борчуы ихтимал. Тамакны салкын тиюдән саклау аеруча мөһим.

Наркотик һәм галлюцинаген матдәләр катнашкан даруларны кулланырга ярамый. Теш алдыру өчен дә бу көн уңайлы түгел. Бәвел, җенси әгъзаларны дәваларга һәм аларга операция ясарга мөмкин. Муен тиресен дәвалау яхшы нәтиҗә бирә. Логопедия (сөйләү җитешсезлеген бетерү), үпкә ялкынсынуын дәвалау процедураларын алу, тамакны ромашка, шалфей төнәтмәләре белән чайкау файдалы.

Күңелсез рекорд

Узган 1999 елда Русия хокук саклау органнарында 3001748 җинаять теркәлде. Соңгы 10 ел эчендә (1999 елга кадәр) бер ел дәвамында җинаятьләр саны 3 миллионнан артмый иде. Ә 1999 елда җинаятьләр буенча рекорд куелды, диярге була.

"Виагра" харап итте

"Виагра" таблеткаларының файдасы бер генә тапкыр тия, диюләренең дөрес түгеллеген Кишиневта яшәүче бер ханым раслады. Ул әлеге таблетканы иренең бәйрәм өстәленә куеласы ашына өстәп биргән. Һәм гаҗәп хәл: соңгы елларда хатынына якын да килмәгән ир күз алдында танымаслык

булып үзгәргән. Гаилә парының мәхәббәт уеннары атна буе дәвам иткән. "Бәйрәм"нең 8 нче көнендә тәмам арыган хатын иренә серне ачкан. "Ашыгыч ярдәм" машинасы чакырылган, ир бер атна хастаханәдә яткан, тик... дәрте һич кенә дә сүрелми икән! Табиблар аңа: "Бары тик электрошок сеансы гына ярдәм итә ала", дигәннәр һәм кисәткәннәр: электрошоктан соң бернинди "Виагра" да ярдәм итмәячәк.

("Труд").

Менә, ичмасам, бәлеш!

Бразилиянең Сан-Паула шәһәренә 439 ел тулу уңаеннан шәһәр пешекчеләре "бәйрәм өстәленә" әкәмәт зур бәлеш пешергәннәр. Аны пешерү өчен ярты тонна он, 9 мең йомырка, йөзләрчә килограмм шикәр һәм май киткән. Бәлешне 9 пешекче төне буе пешергән. Аны өлешләргә кискәләп, урам буйлап өләшкәннәр. Бәлеш 15 минут эчендә таралып беткән.

("МЭ").

Ачылмаган сер юк

Американың Майами шәһәре (Флорида штаты) янында археологлар җир астыннан 12 метрлы түгәрәк таш багана казып чыгаралар. Багана серле тишекләр һәм сызыклар белән чуарланган. Багананың яшен галимнәр 4 мең ел дип билгелиләр, ул испан конкистадорлары кырып бетергән Текеста кабиләсенә карый икән. Җентекләп тикшергәч, галимнәр багананың әлеге кабиләгә йолдызлар һәм планеталар хәрәкәте календаре булып хезмәт иткәнен ачыклыйлар. Американың төп халыклары тарихын өйрәнүче галимнәр өчен табылдыкның әһәмияте зур: календарь - борынгы заманнарда Америкада яшәгән кабиләләрнең интеллектуаль һәм фәнни үсеш дәрәҗәсенең никадәр югары булуының ачык дәлиле. Америка ачылгач, анда көчеп килгән, җирле халыкларны буйсындырган, юкка чыгарган инглизләр аларның аң дәрәҗәсен түбән дип раслап килделәр. Хакыйкать ачылмый калмый.

("НЛО").

Могҗиза белән исән калган сабый

Американың Тампа шәһәреннән күптән түгел торнадо (көчле өермә) узды. Аның тизлеге сәгатенә 416 км иде. Торнадо бер йортның түбәсен, бетон стенасын каерып атты. Бүлмәдә йоклап яткан 18 айлык баланы урын-җире белән давыл очыртып алып китә һәм янәшәдә үсеп утырган агач башына илтеп төшерә. Йорт хуҗалары кайтып, туздырылган йортларын күргәч, сабыйлары да һәлак булгандыр, дип кайгыга төшәләр. Кинәт, югарыдан бала елаган тавыш ишетеп, агач башына карыйлар. Ашыгып, баланы алып төшәләр. Карасалар, аның тәнендә тырналган урын да юк икән!

("МЭ").

Балык ите йөрәккә файдалы

Галимнәр фикеренчә, ирләргә күбрәк балык ашарга кирәк. Балык яки диңгез ризыкларын ашау аларны кинәт үлеп китүдән саклый икән. Балык итендә йөрәк аритмиясен булдырмый торган матдәләр булуы ачыкланган. Соңгы елларда йөрәк өянәге яшь-яшь ирләрне дә теге дөньяга алып китә. Америкада йөрәк кинәт тибүдән туктау аркасында ел саен 250 мең кеше вафат була икән.

("24 сәгать").

Моннан 6800 ел элек...

Каһирә шәһәреннән 1000 километр көньяктарак түгәрәкләп урнаштырылган биек таш балбаллар табылды. Америка археологы Фред Вендорф фикеренчә, бу ташлар - кешелек тарихы башланганчы ук ясалган обсерватория. Алар Англиянең Стоунхендж тарихи обсерваториясеннән 1000 ел элгәрерәк яшәгән кешеләргә хезмәт иткән. Бу обсерватория моннан 6800 ел элек көн белән төн тигезләшкән көнне Кояш чыгуын күзәтергә мөмкинлек биргән. Аны Борынгы Мисыр цивилизациясеннән алда яшәгән хайван асраучы күчмә кабиләләр куйган дип уйланыла.

("Наука и жизнь").

Джунглида алтын хәзинәсе

Бер төркем Перу галимнәре Перу джунглиләренең кеше аяк басмаган бер җирендә моннан 400 ел элек Америка индеецлары яшереп калдырган алтын хәзинәсе урынын таптылар. 1978 елда Перу антропологы Фернандо Апарисио борынгы легендар шәһәр Эльдорадоны эзли. Максаты - алтын хәзинәләрен табу. Ул моңа ирешә дә кебек: спутниклар аша алынган фотосурәтләрдә бу урын шәйләнә. Анда 8 пирамида күренә. Алар 4әр итеп 2 рәткә тезелгән. Апарисио вертолетта ул җиргә барып төшәргә дә уйлаган, ләкин джунглиләрнең үтә алмаслык булуы аны бу фикереннән кайтырга мәҗбүр итә. Җирле индуслар да якында борынгы шәһәр хәрабәләре булуын раслый. Галим химаячеләр ярдәменә өметләнә. Шәһәрне өйрәнү инклар империясенең яшәешен һәм аның ничек юкка чыгуын аңларга ярдәм итәр иде.

("Труд").

К.МАЛЬЦЕВ рәсеме ("НГ").

Дөньядагы иң зур вулкан

Бу вулканның атамасы - Мауна-Лоа ("Озын тау") һәм ул Гавай утрауларының берсендә урнашкан. Вулкан авызының (кратеры) диаметры 10 километрдан артык мәйдан били, тирәнлеге 150-180 метр. Диңгез тигезлегеннән ул 4168 метр биеклектә. Шунысы да кызык: гадәттә вулкан һәр өч ел ярым саен "телгә килә".

(Гиннесс рекордлар китабыннан).

Ясалма күзләр

Япониянең "Мицубиси дэнки" фирмасы белгечләре уникаль ясалма күзләр чыгара башларга тора. Бу күрүне көчәйтү җайланмасы сурәтләрне элекке шундый приборлардан 100 тапкыр тизрәк аера ала. Конструкторлар әйтүенчә, яктылык дулкыннарын мизгел эчендә спектр сигналларына әйләндерергә сәләтле бу җайланма робот ясау техникасында киң кулланыш табарга мөмкин. Мәсәлән, ясалма күз ярдәмендә роботны "күрә торган" итсәң, ул сукыр кешеләрне "җитәкләп" йөртә һәм шуның өчен махсус өйрәтелгән этләрне алыштыра. 2 квадрат метр мәйданлы шакмактан гыйбарәт бу прибор үтә дә вак 4096 фотоэлементтан тора, нәкъ менә шулар аңа "күрергә" мөмкинлек бирә. "Мицубиси дэнки" инженерлары алга таба 1 млн фотоэлементтан торган тагын да "үткеррәк" күзле прибор ясап булыр, дип ышаналар.

("МЭ").

Хезмәт хакы урынына бүрәнә

Воронеж өлкәсе укытучылары хезмәт хакларын алалмыйча тәмам гаҗиз булдылар. Бигрәк тә авыл укытучылары акчасызлыктан интегә. Мәсәлән, Хохол районы укытучыларына күптән түгел эш хакы урынына бүрәнә тараттылар. Анысы да иске авыл мәктәбеннән сүтеп алынган. Панин районында исә эш тагын да кыенрак. Көлсәң көл, көлмәсәң, ела, дигәндәй,эш хакын укытучыларга... кабер ташлары белән түләделәр. Алар: "Инде үләсе генә калды", дип шаярта.

("Для вас").

Куркыныч, әмма акчалы

Таиланд илендә 27 яшьлек Сом Содано крокодил фермасында эшли. Ул тере крокодил авызына башын тыгып, акча эшли. Аны карарга йөзләгән тамашачы җыела. Хезмәте хәтәр булса да, акчаны мул төшерә ул. Тәвәккәллеге дә шуннан.

("СР").

Санаторий... 300 метр җир астында

Закарпатьедагы Солотвино бистәсендә 25 ел инде җир асты санаторие эшли. Аны аллергия белән интегүчеләр хастаханәсе дисәк дөресрәк булыр. Анда 260 авыручы дәвалана: өлкәннәр, балалар бүлекләре, 40 палата, табиблар, лаборатория бүлмәләре, китапханә һәм ял итү бүлмәләре бар. Хастаханәдә җылылык даими 23 градус, дәвалау чарасы - чиста, аэрозол белән баетылган хлорлы-натрийлы һава. Биредә радиация дә, электромагнит кырлары да юк. Җир асты хастаханәсендә күкрәк бакасы, хроник бронхит һәм башка үпкә авыруларын дәвалыйлар. Хастаханәдән авыручыларның 95 проценты тәмам сәламәтләнеп чыга. Күптән түгел 55 меңенчә авыручы, рәхмәт әйтеп, хастаханәдән терелеп чыкты.

("Для вас").

Татар энциклопедиясе битләреннән

МӘҢГӘР Әхмәтвәли Ибраһим улы *(1891-1978), сәүдәгәр, эшмәкәр, җәмәгать эшлеклесе. 1909-1925 елларда Русиядә һәм 1925-38 елларда Кытай Төркестанында сәүдә иткән. 1939 елдан Төркиядәге ике сәүдә-сәнәгать фирмасы хуҗасы, Төркиядә автомобиль сәнәгатен нигезләүчеләрнең берсе. Төркиядәге татар җәмгыятьләренең көнкүреш-мәдәни эшләре һәм "Казан" журналын чыгару аның иганәсенә таянып алып барыла. Варислары Төркиядә татарларның милли-мәдәни мирасын барлауга юнәлтелгән "Мәңгәр фонды"н оештырдылар.*

МӘРДИХАНОВ Рәшит Мәрдихан улы *(1930-1996), артист, ТАССРның халык артисты (1991). 1951 елдан Минзәлә татар драма театрында эшли. К.Тинчуринның "Зәңгәр шәл", Б.Шоуның "Иблис шәкерте" спектакльләрендә Җиһанша, Суиндон рольләрен башкара.*

МӘРҖАНИ Шиһабетдин *(1818-1889), дин белгече, тарихчы, философ, мәгърифәтче. Казан өязе Ташкичү авылында, Бохара, Самарканд шәһәрләре мәдрәсәсендә белем алган. 1850 елдан Казанның Беренче җәмигъ мәчете имамы, 1867 елдан Казанның мөхтәсибе булып сайланган. Бер үк вакытта 1876-1884 елларда Казан татар укытучылар мәктәбендә дин дәресләрен укыткан. Казан университеты каршындагы Археология, тарих һәм этнография җәмгыяте әгъзасы, мөселман галимнәреннән беренче булып аның эшендә актив катнашкан. Дини һәм фәлсәфи хезмәтләрендә дини үзгәртеп кору һәм мәгърифәтчелек идеяләрен үстергән. Аның хезмәтләре татарларда тарих фәннәре үсешенә башлангыч сала һәм мөселман Шәрекъ илләрендә мәгълүм фәнни мәктәпләр традицияләрен дәвам итә. "Вафийат әл әслаф вә тахийа әл әхләф", "Нәзурателхак", "Мөстафад әл Әхбар фи әхвали Казан вә Болгар" (1-2 т., 1897-1900) һәм башка 30 дан артык фундаменталь хезмәтләр авторы.*

МӘСӘГУТОВ Рафаэль Зәйнур улы *(1934), график. Украинаның халык рәссамы (1993). Киевта "Днипро" нәшриятының баш рәссамы (1965-67). 400 китапны бизәү рәссамы, шулар арасында Казанда нәшер ителгән "Муса Җәлил" һәм "Г.Тукай" юбилей басмалары бар. 200гә якын станлы график һәм нәкыш әсәре иҗат итә. Украинаның Н.Островский исемендәге (1981), В.Касиян исемендәге (1989) дәүләт бүләкләре иясе. Киевта яши.*

МӘУЛА Казый Мөхсин *(14 нче йөз), Алтын Урда чоры төрки-татар шагыйре. Кульязма "Китабе Гөлстан бит-төрки" җыентыгында килеп җиткән газәл жанрындагы бер шигыре белән мәгълүм.*

МӘУЛА КОЛЫЙ *(17 нче йөзнең 2 нче яртысы), татар шагыйре. Кайбер әдәбият тарихчылары раславынча, тумышы белән Казан төбәгендәге Чита авылыннан. Югары мәдрәсә белеме алып, 17 нче йөзнең 70 нче елларында борынгы Болгар һәм Биләр тирәләрендә, аннары хәзерге Татарстанның Лениногорск районы, Иске Иштирәк авылында төпләнеп яшәгән. Шагыйрьнең әдәби мирасыннан йөздән артык шигъри парчалары-хикмәтләре сакланып калган. Алар "Хикмәтләр" дип аталган кульязма җыентык буенча билгеле. Шигырьләрнең төп идея-тематикасы яшәеш һәм үлем турында дини-фәлсәфи уйланулар, әхлакый сафлыкка, камиллеккә, диндарлыкка чакыру, әйләнә-тирә дөньяны һәм табигатьне суфичылык рухында кабул итү. Аның иҗаты татар әдәбияты тарихында Ясәви һәм Бакыргани кебек суфи шагыйрьләрнең шигъри традицияләрен дәвам иттерүче һәм аларның язу стилендә чагылган поэтик тасвирлау чараларыннан чагыштыру, метафора, символлардан оста файдалануы белән үзенчәлекле.*

МӘҮЛӘНА Гыймад Мәүләви *(14 нче йөз), Алтын Урда чоры төрки-татар шагыйре. "Китабе Гөлстан бит-төрки" исемле кульязма җыентыкта теркәлеп калган газәл жанрындагы шигыре буенча мәгълүм.*

Дүшәмбе

7 ФЕВРАЛЬ

"ТАТАРСТАН"

7.00-8.00 "Чулпан".
18.00, 20.00 "Җиһан". Хәбәрләр.
18.10 "Күңел җыры". Б.Насыйрова.
18.30 "Замандаш".
19.00 "АДАШКАН МӘХӘББӘТ".
19.45 "Әлли-бәлли-бәү".
20.30, 22.50 "Яңалыклар".
21.00 "Карт-бланш".
21.30 "7 нче стиль".
22.20 Татарстанның теннис турниры.
22.40 "Грипп - җитди мәсьәлә".

"ЭФИР"

6.00, 2.10, 4.15 "ТВ музыкасы".
6.15, 19.45, 22.55, 4.00 Криминаль хроника: "Перехват".
6.30 "Уян һәм җырла!"
8.15 "Республика". Информацион-аналитик программа.
8.45 "БАГРОВЫЙ ПРИЛИВ".
10.35, 17.15, 18.40, 3.00 "Музыкага чикләр юк".
11.00 "Яңалыклар".
11.05 Мультфильм.
11.20 "Атна низаглары".
12.05 Атна һәлакәтләре".
12.55 "Динле кешенең тантаналы тавышы".
13.25 "Көн арты көн".
14.55 "Тамаша залы".
15.30 "НИКТО КРОМЕ ТЕБЯ".
16.15 "Кыска юл".
16.30 Мультфильм.
17.00, 19.00, 22.10, 3.15 "Шәһәр". Информацион программа.
17.20 "Я ШАГАЮ ПО МОСКВЕ".
20.00 "СОЛДАТ ДЖЕЙН".
23.10 "ПРОИСШЕСТВИЯ".
0.50 Д/ф: "Последний миф".
1.55 "Юл патруле".

1 НЧЕ КАНАЛ

6.00 "Хәерле иртә!"
9.00, 12.00, 15.00, 18.00, 0.20 "Яңалыклар".
9.15 "НЕЖНЫЙ ЯД".
10.15 "Бар да өйдә чакта".
10.45 Тимераякта шуу. Дөнья чемпионаты.
11.30 "НОВЫЕ ПРИКЛЮЧЕНИЯ СИНДБАДА".
12.15 "Хәерле көн" телеканалы.
12.55 "Знатоки" возвращаются. "Несчастный случай".
14.30 "Бергә".
15.20 Мультсериал.
15.45 "Нәрсә да ничек".
16.00 "Йолдызлы сәгать".
16.25 "16 яшькәчә һәм өлкәнрәкләр өчен..."
17.00 "НЕЖНЫЙ ЯД".
18.25 "Җиңел пар белән!" М.Евдокимовта кунакта.
18.55 "Без һәм вакыт".
19.50 "ДЕВУШКИ С ХАРАКТЕРОМ".
20.45 "Тыныч йокы, нәниләр!"
21.00 "Вакыт".
22.00 "СЕКРЕТНЫЕ МАТЕРИАЛЫ".
23.40 "Караш".
0.35 "МАЙК ХАММЕР: УБИЙСТВО НА ПАМЯТЬ".

"РУСИЯ"

6.30-9.20 "Хәерле иртә, Русия!"
7.00, 8.00, 9.00, 13.00, 17.00, 19.00, 21.00, 1.00 "Хәбәрләр".
8.15, 0.45 "Кизү бүлеге".
9.20, 10.00, 12.50 "Квант медицинасы".
9.30 "Спорт мәйданы".
10.10 "ЦЫГАНКА".
10.55 "ЛЕТО НАШЕЙ ТАЙНЫ".
11.45 Мультфильм.
12.00 "Көзге".
13.25 "Хатын-кызлар шәһәре".
14.10 "АНТОНЕЛЛА".
15.00 "ДИКИЙ АНГЕЛ".
15.45 Мультфильм.
16.00, 1.20 "Диванда кибет".
16.30 Мультсериал.
17.20 "Манара".
18.05 "ЖАРА В ЛОС-АНДЖЕЛЕСЕ-II".
19.30 "ПЕТЕРБУРГСКИЕ ТАЙНЫ".
20.25 "Шәмәхә томан".
21.45 "УМЕРЕТЬ, ЧТОБЫ ЖИТЬ".
0.15 "Спорт + ТВ".

"КУЛЬТУРА"

8.05, 12.30, 14.30, 0.00 "Мәдәният яңалыклары".
8.20 "Яңалыклардан соң..."
8.40 "БУЛЬВАР РЕВОЛЮЦИИ".
10.15 "Русия йомышчысы".
10.55 "Кинопанорама. Очрашулар".
11.35 "И ОГОНЬ, И ПЛАМЯ".
12.40 "ТРИ".
14.00 О.Басилашвили программасы: "Түшәмнән".
14.45 Дөнья музыка театры җәүһәрләре. "Лондонның фестиваль труппасы".
16.00, 18.30 Яңалыклар.
16.10 "ЖИЛ-БЫЛ ХОМЯК".
16.35 "Вакыт һәм сугышчылар". "Рим легионнары".
17.00 "Классика темасына вариацияләр".
17.35 "И ОГОНЬ, И ПЛАМЯ".
22.40 "ПРАЧЕЧНАЯ".
23.45 PRO MEMORIA. "Төрмә".

"НТВ"

6.00 "Бүген иртән".
8.55 "ОНА НАПИСАЛА УБИЙСТВО".
9.50 Мультфильм.
10.00, 12.00, 14.00, 16.00, 19.00, 22.00 "Бүген".
10.25 "Кичәге "Йомгаклар"да.
11.45 "Курчаклар".
12.30 "Иске телевизор" хәтерли: "КОРОЛИ И КАПУСТА".
14.30 Криминал: "Чын күңелдән анлату".
14.55 "УЛИЦЫ РАЗБИТЫХ ФОНАРЕЙ".
16.35 "ЛОИС И КЛАРК. НОВЫЕ ПРИКЛЮЧЕНИЯ СУПЕРМЕНА".
17.25 "Файда өчен".
17.40 "Кызык кино".
17.50 "ЛЮБОВЬ И ТАЙНЫ САНСЕТ БИЧ".
18.40 "Криминал".
19.40 "Көн каһарманы".
20.00 "СКОРАЯ ПОМОЩЬ".
20.55 "СОВЕРШЕННО СЕКРЕТНО. ИНФОРМАЦИЯ К РАЗМЫШЛЕНИЮ".
22.45 "Икәү".
23.30 В.Шендерович белән "Җәмгысе".
23.55 "Көн яңалыклары".
0.35 "Бүген төн уртасында".
0.55 Д.Дибров программасы: "Антропология".

Сишәмбе

8 ФЕВРАЛЬ

"ТАТАРСТАН"

7.00-8.00 "Чулпан". Информацион программа.
18.00, 20.00 "Җиһан". Хәбәрләр.
18.10 "Бер җырлап биеп алыйк әле".
18.30 "Шаян-шоу".
19.00 "АДАШКАН МӘХӘББӘТ".
19.45 "Әлли-бәлли-бәү".
20.30, 22.50 Яңалыклар.
21.00 "Таяну ноктасы".
21.10 "Авылның эш көннәре".
21.30 "ЭФИ" (икътисад, финанслар, мәгълүматлар).
22.00 Д/ф: "Одной судьбой с Казанью..."
22.25 ТРТ музыкасы.
22.35 "02 досьесы".

"ЭФИР"

6.00, 17.15, 1.50, 4.40 "ТВ музыкасы".
6.15, 19.45, 22.55, 4.00 Криминаль хроника: "Перехват".
6.30 "Уян һәм җырла!"
8.15, 17.00, 19.00, 22.10, 3.15 "Шәһәр". Информацион программа.
9.00 "СИБИРИАДА".
10.40, 0.30, 3.00 "Музыкага чикләр юк".
11.00 "Яңалыклар".
11.05 "САМАЯ ОБАЯТЕЛЬНАЯ И ПРИВЛЕКАТЕЛЬНАЯ".
12.35 "Динле кешенең тантаналы тавышы".
13.05 "Көн арты көн".
14.55 "Поза".
15.30 "НИКТО КРОМЕ ТЕБЯ".
16.20 "Кыска юл".
16.35 Мультфильм.
17.55 "ПСИ-ФАКТОР".
20.00 "ИСТОРИЯ ПРЕСТУПЛЕНИЯ".
21.55 "Казан блюзы".
23.10 "ЗОЛОТОЙ ТУМАН".
0.50 "Диск-канал".
1.15 "Юл патруле".
1.25 "Көн яңалыклары".
4.15 "Адымнар".

1 НЧЕ КАНАЛ

6.00 "Хәерле иртә!"
9.00, 12.00, 15.00, 18.00, 0.10 "Яңалыклар".
9.15 "НЕЖНЫЙ ЯД".
10.15 "Джентльмен-шоу".
10.45 "Бу ничек булды". "Әрмәнстан парламентын ату". 1999 ел.
11.20 "Тәмле тарихлар".
11.30 "НОВЫЕ ПРИКЛЮЧЕНИЯ СИНДБАДА".
12.15 "Хәерле көн" телеканалы.
13.00 "Знатоки" возвращаются. "Побег".
14.30 "Бергә".
15.20 Мультсериал.
15.45 "Барысы да булырга мөмкин".
16.00 "Тау патшасы".
16.25 "16 яшькәчә һәм өлкәнрәкләр өчен..."
17.00 "НЕЖНЫЙ ЯД".
18.25 "КВН".
18.55 "Сине эзлим".
19.50 "ДЕВУШКИ С ХАРАКТЕРОМ".
20.45 "Тыныч йокы, нәниләр!"
21.00 "Вакыт".
22.00 "ОПАСНО ДЛЯ ЖИЗНИ!"
23.40 В.Молчановның авторлык программасы: "Хәтерлим... Яратам..." Сигизмунд Кац.

"РУСИЯ"

6.30 "Хәерле иртә, Русия!"
7.00, 8.00, 9.00, 13.00, 17.00, 19.00, 21.00, 1.00 "Хәбәрләр".
8.15, 0.45 "Кизү бүлеге".
9.20, 10.00, 12.50 "Гомеопатия һәм сәламәтлек".
9.30 "Спорт мәйданы".
10.10 "ЦЫГАНКА".
10.55 "ЛЕТО НАШЕЙ ТАЙНЫ".
11.50 Мультфильм.
12.00 "Минем XX гасыр".
12.25 "Телеспецназ".
13.25 "Хатын-кызлар шәһәре".
14.10 "АНТОНЕЛЛА".
15.00 "ДИКИЙ АНГЕЛ".
15.50 Мультфильм.
16.00, 1.20 "Диванда кибет".
16.30 Мультсериал.
17.20 "Манара".
18.05 "ЖАРА В ЛОС-АНДЖЕЛЕСЕ-II".
19.30 "ПЕТЕРБУРГСКИЕ ТАЙНЫ".
20.25 "Полный Модерн".
21.45 "В ПОГОНЕ ЗА МИЛЛИОНОМ".
23.45 "К-2" тәкъдим итә: А.Когонның "Персона" программасы.

"КУЛЬТУРА"

8.05, 12.30, 14.30, 0.00 "Мәдәният яңалыклары".
8.20 "Яңалыклардан соң..."
8.40 "ПИВОВАР".
9.40 "Ромео и Джульетта из Сараева".
10.40 Скрипка белән оркестр өчен концерт.
11.10 "Максат күрәм!"
11.35 "И ОГОНЬ, И ПЛАМЯ".
12.40 "СКОРО БУДЕТ КОНЕЦ СВЕТА".
14.00 "Карт гайбәтче хикәяләре". А.Белинскийның авторлык программасы.
14.45 Мультфильм.
16.00, 18.30 Яңалыклар.
16.10 "ЖИЛ-БЫЛ ХОМЯК".
16.35 "Вакыт һәм сугышчылар" "Филдәге сугышчылар".
17.05 "Ортодокс".
17.35 "И ОГОНЬ, И ПЛАМЯ".
22.15 "ПИВОВАР".
23.15 Скрипка белән оркестр өчен концерт.

"НТВ"

6.00 "Бүген иртән".
8.55 "СОВЕРШЕННО СЕКРЕТНО. ИНФОРМАЦИЯ К РАЗМЫШЛЕНИЮ".
10.00, 12.00, 14.00, 16.00, 19.00, 22.00 Бүген.
10.25 "Галстуксыз көн каһарманы".
10.55 С.Шустер программасы: "Өченче тайм".
11.45 Мультфильм.
12.30 "Иске телевизор" хәтерли: "ТРАНЗИТ".
14.30 "СЕНТИМЕНТАЛЬНОЕ ПУТЕШЕСТВИЕ НА КАРТОШКУ".
16.35 "ЛОИС И КЛАРК. НОВЫЕ ПРИКЛЮЧЕНИЯ СУПЕРМЕНА".
17.25 "Файда өчен".
17.40 "Кызык кино".
17.50 "ЛЮБОВЬ И ТАЙНЫ САНСЕТ БИЧ".
18.40 "Криминал".
19.35 "Көн каһарманы".
19.55 "СКОРАЯ ПОМОЩЬ".
20.45 "АГЕНТ НАЦИОНАЛЬНОЙ БЕЗОПАСНОСТИ. НАСЛЕДНИК".
22.45 Е.Киселев программасы: "Халык тавышы".
0.05 "Көн яңалыклары".
0.45 "Бүген төн уртасында".
1.05 Д.Дибров программасы: "Антропология".

Чәршәмбе

9 ФЕВРАЛЬ

"ТАТАРСТАН"

7.00-8.00 "Чулпан". Информацион программа.
18.00, 20.00 "Җиһан". Хәбәрләр.
18.10 "Батулла дәресләре".
18.30 Татар халык җырлары.
18.50 "Ышаныч һәм иминлек".
19.00 "АДАШКАН МӘХӘББӘТ".
19.45 "Әлли-бәлли-бәү".
20.30, 22.50 "Яңалыклар".
21.00 Д/ф.
21.10 Турыдан-туры элемтә. "Наркомания белән көрәш".
21.45 "01 хезмәте".
21.55 Телефильм: "Медный всадник".

"ЭФИР"

6.00, 17.15, 1.55, 4.15 "ТВ музыкасы".
6.15, 19.45, 22.45, 4.00 Криминаль хроника: "Перехват".
6.30 "Уян һәм җырла!"
8.15, 17.00, 19.00, 22.00, 3.15 "Шәһәр". Информацион программа.
9.00 "СИБИРИАДА".
10.40, 15.20, 21.45, 3.00 "Музыкага чикләр юк".
11.00 "Яңалыклар".
11.05 "ЗАКЛЯТИЕ ДОЛИНЫ ЗМЕЙ".
12.55 "Динле кешенең тантаналы тавышы".
13.25 "Көн арты көн".
15.00 "Сәламәт булыйк!"
15.30 "НИКТО КРОМЕ ТЕБЯ".
16.20 "Кыска юл".
16.35 Мультфильм.
17.55 "ПСИ-ФАКТОР".
20.00 "КРЫША МИРА".
1.50 "Диск-канал".
1.20 "Юл патруле".
1.30 "Көн яңалыклары".

1 НЧЕ КАНАЛ

6.00 "Хәерле иртә!"
9.00, 12.00, 15.00, 18.00, 0.10 "Яңалыклар".
9.15 "НЕЖНЫЙ ЯД".
10.15 "КВН".
10.45 "Сине эзлим".
11.30 "НОВЫЕ ПРИКЛЮЧЕНИЯ СИНДБАДА".
12.15 "Хәерле көн" телеканалы.
12.50 "Знатоки" возвращаются. "Побег".
14.30 "Бергә".
15.20 Мультсериал.
15.45 "Шәп компания".
16.00 "Джунглилар чакыруы".
16.25 "16 яшькәчә һәм өлкәнрәкләр өчен..."
17.00 "НЕЖНЫЙ ЯД".
18.25 "Битлек-шоу".
18.55 "Кеше һәм закон".
19.50 "ДЕВУШКИ С ХАРАКТЕРОМ".
20.45 "Тыныч йокы, нәниләр!"
21.00 "Вакыт".
22.00 "ЕЕ АЛИБИ".
23.40 "Цивилизация".

"РУСИЯ"

6.30-9.20 "Хәерле иртә, Русия!"
7.00, 8.00, 9.00, 13.00, 17.00, 19.00, 21.00, 1.00 "Хәбәрләр".
8.15, 0.45 "Кизү бүлеге".
9.20, 10.00, 12.50 "Квант медицинасы".
9.30 "Спорт мәйданы".
10.10 "ЦЫГАНКА".
11.00 "ЛЕТО НАШЕЙ ТАЙНЫ".
11.50 Мультфильм.
12.00 "Минем XX гасыр".
12.25 "Телеспецназ".
13.25 "Хатын-кызлар шәһәре".
14.10 "АНТОНЕЛЛА".
15.00 "ДИКИЙ АНГЕЛ".
15.50 Мультфильм.
16.00, 1.20 "Диванда кибет".
16.20 "Медицина хәбәрчесе".
16.30 Мультфильмнар.
17.20 "Манара".
18.05 "ЖАРА В ЛОС-АНДЖЕЛЕСЕ".
19.30 "ПЕТЕРБУРГСКИЕ ТАЙНЫ".
20.25 "Үзенә-үзе режиссер".
21.45 "ПРЕЗИДЕНТ И ЕГО ЖЕНЩИНА".
23.30 "Мода + ТВ".

"КУЛЬТУРА"

8.05, 12.30, 14.30, 0.00 "Мәдәният яңалыклары".
8.20 "Яңалыклардан соң..."
8.40 "ПИВОВАР".
9.35 "Кузнецовтан ватык чынаяк".
10.20 "ДЭВИД".
11.00 С.Прокофьев. "Жиденче симфония".
11.35 "И ОГОНЬ, И ПЛАМЯ".
12.40 "МАСТЕР И МАРГАРИТА".
14.15 "Сарай серләре". Монплезир.
14.45 Мультфильм.
15.45 "Кояш кайда сирәк байый".
16.00, 18.30 Яңалыклар.
16.10 "ЖИЛ-БЫЛ ХОМЯК".
16.35 "Вакыт һәм сугышчылар". "Гуннар".
17.05 В.Родзянко. "СУДНЫЕ ДНИ". 3 нче фильм.
17.35 "И ОГОНЬ, И ПЛАМЯ".
22.30 "ПИВОВАР".
23.30 "Башка музыка".

"НТВ"

6.00 Бүген иртән.
8.55 "АГЕНТ НАЦИОНАЛЬНОЙ БЕЗОПАСНОСТИ. НАСЛЕДНИК".
10.00, 12.00, 14.00, 16.00, 19.00, 22.00 "Бүген".
10.25 Е.Киселев программасы: "Халык тавышы".
11.45 "Мохит".
12.30 "Иске телевизор" хәтерли: "ТРАНЗИТ".
14.25 "КОГДА ПЕСНЯ НЕ КОНЧАЕТСЯ".
16.35 "ЛОИС И КЛАРК. НОВЫЕ ПРИКЛЮЧЕНИЯ СУПЕРМЕНА".
17.25 "Файда өчен".
17.40 "Кызык кино".
17.50 "ЛЮБОВЬ И ТАЙНЫ САНСЕТ БИЧ".
18.40 "Криминал".
19.35 "Көн каһарманы".
19.55 "СКОРАЯ ПОМОЩЬ".
20.45 "АГЕНТ НАЦИОНАЛЬНОЙ БЕЗОПАСНОСТИ. МЕДУЗА ГОРГОНА".
22.45 "НЕЗАВИСИМОЕ РАССЛЕДОВАНИЕ" Н.Николаев белән.
23.35 "Көн яңалыклары".
0.25 "Бүген төн уртасында".
0.45 Д.Дибров программасы: "Антропология".

Пәнҗешәмбе

10 ФЕВРАЛЬ

"ТАТАРСТАН"

7.00-8.00 "Чулпан".
18.00, 20.00 "Җиһан". Хәбәрләр.
18.10 "Асия Галиева. "Пушкин - минем тормышымда".
19.00 "АДАШКАН МӘХӘББӘТ".
19.45 "Әлли-бәлли-бәү".
20.30, 22.50 Яңалыклар.
21.00 "Зур планда".
21.10 "Таяну ноктасы".
21.30 "02 досьесы".
21.40 "Экология йомышчысы".
22.10 "Тавышның кайтавазы". Ф.Бикчәнтәев.
22.30 В.Федотов уйный (баян).

"ЭФИР"

6.00, 17.15, 1.55, 4.45 "ТВ музыкасы".
6.15, 19.45, 22.55, 4.00 Криминаль хроника: "Перехват".
6.30 "Уян һәм җырла!"
8.15, 17.00, 19.00, 22.10, 3.15 "Шәһәр". Информацион программа.
9.00 "РОМАНС О ВЛЮБЛЕННЫХ".
11.10 "Теләңне йотарлык".
11.40 "Динле кешенең тантаналы тавышы".
12.10 "Мин үзем": "Мин гаепле түгел..."
13.15 "Көн арты көн".
15.00 "Бонус".
15.30 "НИКТО КРОМЕ ТЕБЯ".
16.20 "Кыска юл".
16.35 Мультфильм.
17.55 "ПСИ-ФАКТОР".
20.00 "Турыдан-туры элемтә". "ГТС: перспективалар".
21.00 Мини-сериал.
23.10 "NA".
23.40 "ДИКАРЬ".
1.20 "Юл патруле".
1.30 "Көн яңалыклары".
3.00 "Музыкага чикләр юк".
4.15 "Поза".

1 НЧЕ КАНАЛ

6.00 "Хәерле иртә!"
9.00, 12.00, 15.00, 18.00, 0.00 "Яңалыклар".
9.15 "НЕЖНЫЙ ЯД".
10.15 "Битлек-шоу".
10.45 "Кеше һәм закон".
11.30 "НОВЫЕ ПРИКЛЮЧЕНИЯ СИНДБАДА".
12.15 "Хәерле көн" телеканалы.
12.50 "Знатоки" возвращаются. "Свидетель".
14.30 "Бергә".
15.20 Мультсериал.
15.45 "Җиде бәлагә бер җавап".
16.00 "100 процент".
16.25 "16 яшькәчә һәм

өлкәнрәкләр өчен..."
17.00 "НЕЖНЫЙ ЯД".
18.25 "Каламбур".
18.55 "Процесс".
19.50 "ДЕВУШКИ С ХАРАКТЕРОМ".
20.45 "Тыныч йокы, нәниләр!"
21.00 "Вакыт".
22.00 "ПРИВЕТ ОТ ЧАРЛИ-ТРУБАЧА".
23.30 "Кара" программасының премьерасы.

"РУСИЯ"

6.30-9.20 "Хәерле иртә, Русия!".
7.00, 8.00, 9.00, 13.00, 17.00, 19.00, 21.00 "Хәбәрләр".
8.15, 0.45 "Кизү бүлеге".
9.20, 10.00, 12.50 "Гомеопатия һәм сәламәтлек".
9.30 "Спорт мәйданы".
10.10 "ЦЫГАНКА".
10.55 "ЛЕТО НАШЕЙ ТАЙНЫ".
12.00 "Минем XX гасыр".
12.25 "Телеспецназ".
13.25 Информацион-күңел ачу тележурналы: "Хатын-кызлар шәһәре".
14.10 "АНТОНЕЛЛА".
15.00 "ДИКИЙ АНГЕЛ".
15.50 Мультфильм.
16.00, 2.15 "Диванда кибет".
16.30 Мультфильмнар.
17.20 "Манара".
18.05 "ЖАРА В ЛОС-АНДЖЕЛЕСЕ-II".
19.30 "ПЕТЕРБУРГСКИЕ ТАЙНЫ".
20.25 "Ак попугай" клубы.
21.45 "ПРОЩЕНИЕ".
23.30 "Кино + ТВ".
1.20 "Кайнар уннык".

"КУЛЬТУРА"

8.05, 12.30, 14.30, 0.00 "Мәдәният яңалыклары".
8.20 "Яңалыклардан соң..."
8.40 "ПИВОВАР".
9.35 "Царица муз и красоты". Э.Волконская.
10.20 Д/ф: "Переселенцы "Ау, Вселенная".
11.00 "Ноу-хау".
11.15 "Российская камерата" оркестры уйный.
11.35 "И ОГОНЬ, И ПЛАМЯ".
12.40 "ЧЕЛОВЕК - НЕ ПТИЦА".
13.55 В.Верникның авторлык программасы: "Кем анда..."
14.45 Мультфильмнар.
15.05 "Патша ложасы".
15.45 В.И.Качалов театры легендалары.
16.00 Яңалыклар.
16.10 "ЖИЛ-БЫЛ ХОМЯК".
16.35 "Вакыт һәм сугышчылар". "Кельтлар".
17.10 "В.Родзянко. "ПЕРВАЯ ЛЮБОВЬ".
17.35 "И ОГОНЬ, И ПЛАМЯ".
22.05 "ПИВОВАР".
23.00 Мультфильмнар.

"НТВ"

6.00 "Бүген иртән".
8.55 "АГЕНТ НАЦИОНАЛЬНОЙ БЕЗОПАСНОСТИ".
10.00, 12.00, 14.00, 16.00, 19.00, 22.00 "Бүген".
10.25 "НЕЗАВИСИМОЕ РАССЛЕДОВАНИЕЕ" Н.Николаев белән.
11.15 "Олы ата-аналар".
11.45 Мультфильм.
12.30 "Иске телевизор" хәтерләр: "ТРАНЗИТ".
14.35 "ВЕЧЕРА НА ХУТОРЕ БЛИЗ ДИКАНЬКИ".
16.35 "ЛОИС И КЛАРК. НОВЫЕ ПРИКЛЮЧЕНИЯ СУПЕРМЕНА".
17.25 "Файда өчен".
17.40 "Кызык кино".
17.50 "ЛЮБОВЬ И ТАЙНЫ САНСЕТ БИЧ".
18.40 "Криминал".
19.35 "Көн каһарманы".
19.55 "СКОРАЯ ПОМОЩЬ".
20.45 "АГЕНТ НАЦИОНАЛЬНОЙ БЕЗОПАСНОСТИ. ШАНТАЖ".
22.45 О.Пушкинаның "Хатын-кыз карашы".
23.20 "Көн яңалыклары".
0.10 "Бүген төн уртасында".
0.30 "ОТЕЦ ДЖОН".

Җомга

11 ФЕВРАЛЬ

"ТАТАРСТАН"

7.00-8.00 "Чулпан".
18.00, 20.00 "Җиһан". Хәбәрләр.
18.10 "Канун. Парламент. Җәмгыять".
18.35 "Дин һәм тормыш".
18.55 Музыкаль тәнәфес.
19.00 "Иртә түгел, соң түгел".
19.45 "Әлли-бәлли-бәү".
20.30, 22.50 Яңалыклар.
21.00 "Эшмәкәрлек телевидениесе".
21.30 "Закон. Парламент. Общество".
22.00 Казанның милли-мәдәни җәмгыятьләре фестиваленең йомгаклау концерты.

"ЭФИР"

6.00, 17.15, 1.15, 4.15 "ТВ музыкасы".
6.15, 19.45, 22.45, 4.00 Криминаль хроника: "Перехват".
6.30 "Уян һәм җырла!"
8.15, 17.00, 19.00, 22.00, 3.15 "Шәһәр". Информацион программа.
9.00 "ЖЕНЩИНА В БЕЛОМ".
10.10 "Кабачок "О. С. П.-стулья".
11.10 "Сораусыз".
11.45 "Динле кешенең тантаналы тавышы".
12.25 В.Мережко белән "Минем кино".
13.05 "Көн арты көн".
14.55 "Үз кешеләр".
15.30 "НИКТО КРОМЕ ТЕБЯ".
16.15 "Кыска юл".
16.35 Мультфильм.
17.55 "ПСИ-ФАКТОР".
20.00 "ПОМЕНЯТЬСЯ МЕСТАМИ".
23.00 "ФОРМУЛА УНИЧТОЖЕНИЯ".
0.35 "Юл патруле".
0.50 "Көн яңалыклары".

1 НЧЕ КАНАЛ

6.00 "Хәерле иртә!"
9.00, 12.00, 15.00, 18.00, 0.10 "Яңалыклар".
9.15 "НЕЖНЫЙ ЯД".
10.15 "Каламбур".
10.45 "Процесс".
11.30 "НОВЫЕ ПРИКЛЮЧЕНИЯ СИНДБАДА".
12.15 "Хәерле кич" телеканалы.
12.55 "Знатоки" возвращаются. "Ответный удар".
14.30 "Бергә".
15.20 "ПРЕРИЯ".
17.00 "НЕЖНЫЙ ЯД".
18.25 "Джентльмен-шоу".
19.00 Документаль детектив: "Черная метка" Сильвестра. Дело 1998 года".
19.30 "Тәмле тарихлар".
19.45 "Могҗизалар кыры".
20.45 "Тыныч йокы, нәниләр".
21.00 "Вакыт".
21.40 "КРИЗИС ЛИЧНОСТИ".
23.30 Бөтенрусия такмаклар суперкубогы: "Эх, Семеновна!"
0.25 "СТРАНА ОТЦОВ".

"РУСИЯ"

6.30-9.20 "Хәерле иртә, Русия!"
7.00 8.00, 9.00, 13.00, 17.00, 19.00, 21.00, 1.00 "Хәбәрләр".
8.15, 0.45 "Кизү бүлеге".
8.35 "Мең һәм бер көн".
9.20, 10.00, 12.50 "Квант медицинасы".
9.30 "Спорт мәйданы".
10.10 "ЦЫГАНКА".
11.00 "КОВАРНЫЙ ОБОЛЬСТИТЕЛЬ".
12.00 "Минем XX гасыр".
12.25 "Телеспецназ".
13.25 Д/ф: "Операция Улусы".
14.00 Мультфильм.
14.10 "АНТОНЕЛЛА".
15.00 "ДИКИЙ АНГЕЛ".
16.00, 1.20 "Диванда кибет".
16.25 "Балык тоту турында әңгәмәләр".
17.20 "Акуна Матата".
18.05 "ЖАРА В ЛОС-АНДЖЕЛЕСЕ-II".
19.30 "ОГРАБЛЕНИЕ В МИЛЛИОН ДОЛЛАРОВ".
20.25 "Шәһәрчек".
21.45 "БРАТ".
23.35 "Атна манзарасы".

"КУЛЬТУРА"

8.05, 12.30, 14.30, 20.30, 0.00 "Мәдәният яңалыклары".
8.20 "Яңалыклардан соң...".
8.40 "ПИВОВАР".
9.40 "Царица муз и красоты". Э.Волконская.
10.25 "Русия йомшычысы".
11.05 "Классика темаларына вариацияләр".
11.35 "И ОГОНЬ, И ПЛАМЯ".
12.40 "НЕВИННОСТЬ БЕЗ ЗАЩИТЫ".
14.45 Мультфильмнар.
16.00 Яңалыклар.
16.10 "ЖИЛ-БЫЛ ХОМЯК".
16.35 "Вакыт һәм сугышчылар".
17.05 "Минем язмыш". В.Родзянко. "Миротворец".
17.35 "И ОГОНЬ, И ПЛАМЯ".
22.35 "ПИВОВАР".
23.30 В.Ерофеевның авторлык программасы: "Апокриф... һәм Яңа Театр"

"НТВ"

6.00 "Бүген иртән".
8.55 "АГЕНТ НАЦИОНАЛЬНОЙ БЕЗОПАСНОСТИ. ШАНТАЖ".
10.00, 12.00, 14.00, 16.00, 19.00, 22.00 "Бүген".
10.25 "Рецептсыз".
11.00 "Дог-шоу. Мин һәм минем этем".
11.30 "Коткару хезмәте".
12.30 Иске телевизор хәтерләр: "ТРАНЗИТ".
14.35 "ПО ДАННЫМ УГОЛОВНОГО РОЗЫСКА...".
16.35 "ЛОИС И КЛАРК. НОВЫЕ ПРИКЛЮЧЕНИЯ СУПЕРМЕНА".
17.25 "Файда өчен".
17.40 "Кызык кино".
17.50 "ЛЮБОВЬ И ТАЙНЫ САНСЕТ БИЧ".
18.40 Криминал.
19.40 "Көн каһарманы".
20.00 "КРУТОЙ УОКЕР: ПРАВОСУДИЕ ПО-ТЕХАССКИ".
20.50 "АГЕНТ НАЦИОНАЛЬНОЙ БЕЗОПАСНОСТИ. ТРАНЗИТ".
22.45 "Криминаль Русия".
23.15 "ОЖОГ"

Шимбә

12 ФЕВРАЛЬ

"ТАТАРСТАН"

8.00, 9.00 "Таң җилләре аша..."
18.00 Баскетбол. Русия чемпионаты. Суперлига. "УНИКС" (Казан) - "Урал Грейт" (Пермь). Тәнәфестә: "02 досьесы" (татар телендә).
19.30 "Сәлам юллыйм".
20.00 "Атна".
20.30 "Яңалыклар".
21.00 "Видеоспорт-авто".
21.30 "Таяну ноктасы".
21.40 "Симха"га - 10 яшь.

"ЭФИР"

6.00 "Радио-хит".
7.00, 8.05, 10.45, 14.50, 21.55, 3.00 "Музыкага чикләр юк".
7.15, 19.00, 22.00, 3.15 "Шәһәр". Информацион программа.
8.45, 22.55 Юл патруле.
8.55 Мультфильмнар.
9.40 "Диск-канал".
10.15 Юмористик программа: "Бис".
11.10 "Сәламәт булыйк".
11.30 Мультфильм.
11.55 "Телеңне йөтарлык".
12.25 "Сораусыз".
13.00 Яңалыклар.
13.15 "СВИНАРКА И ПАСТУХ".
15.00 "Үз кешеләр".
15.30 "Үз уены".
16.00 СВ-Шоу. С.Иванов.
17.00 "Таныш ят хатын".
17.30 "Адымнар".
18.00 "Исәнмесез!"
19.45 "Pret-a-porter".
20.00 "ПЛЕННИКИ НЕБЕС".
23.10 "КЛИНОК".
1.10 "Плейбой".
2.35, 4.00 "ТВ музыкасы".

1 НЧЕ КАНАЛ

8.00, 10.00, 15.00, 18.00 Яңалыклар.
8.10 "Пастырь сүзе. Митрополит Кирилл".
8.25 "ВСЕ ПУТЕШЕСТВИЯ КОМАНДЫ КУСТО".
9.15 "Ералаш".
9.25 "Уйна, сөекле гармуным!"
10.10 "Тәмле".
10.30 "Могҗизалар кыры".
11.30 "Иртәнге почта".
12.00 "ДОБРЯКИ".
13.50 "Хайваннар дөньясында".
14.30 "Бер җәүһәр тарихы". "Урыс музее".
15.10 "Тема".
15.55 "Җиденче сиземләү".
16.40 "БАБЬЕ ЛЕТО".
17.20 "Детектив-шоу" программасы.
18.10 "Ералаш".
18.30 "Үйлап тап".
19.10 "ТЕРНЕР И ХУЧ".
21.00 С.Доренконың авторлык программасы.
22.20 "КИТАЙСКИЙ ГОРОДОВОЙ".
23.10 "Ел җырлары".
0.00 "ВНЕЗАПНЫЙ УДАР".

"РУСИЯ"

8.00 Мультфильмнар.
8.10 "ЗОЛОТЫЕ ЧАСЫ".
9.30 "РТР почтасы".
10.00 "Хәерле иртә, илем!"
10.35 "Йөзгә каршы берәү".
11.25 "Үзенә-үзе режиссер".
11.55 "ДРУЗЬЯ".
12.25 "Эх, юллар..."
12.40 "Алтын ачкыч".
13.00, 21.00 Хәбәрләр.
13.20 Федерация.
14.00 "БЕЗОТЦОВЩИНА".
15.35 Мультсериал.
16.05 "Телеспецназ".
16.35 "Кизү бүлеге".
17.05 "Сәламәтлекка!"
18.00 "Минем гаилә".
19.00 "Ике рояль".
19.55 "Аншлаг" һәм Ко".
21.45 "БАРХАНОВ И ЕГО ТЕЛОХРАНИТЕЛЬ".
0.00 "КАРНОЗАВР".

"КУЛЬТУРА"

10.05 "Библияне укыганда". Ветхий Завет.
10.15 "Аистенок".
10.40 "КУКЛА С МИЛЛИОНАМИ".
11.55 "Шәп авыл".
12.10 Д/ф: "Гражданская война в Америке".
13.20 М.Равель "Вальс".
13.35 "Графоман".
14.00 "Карт гайбәтче хикәясе". А.Белинскийның авторлык программасы: "Телеэкранда Анатолий Эфрос".
14.30, 22.00 Мәдәният яңалыклары.
14.45 "КАРТОННАЯ СВАДЬБА".
15.40 "Цирк чемоданы".
16.05 "Ватан һәм язмышлар".
16.20 М.Плетнев уйный.
16.50 Телеспектакль: "Несколько капель".
22.20 "Блеф-клуб".
23.00 "СЕНТ-ЭКЗ".

"НТВ"

8.00, 10.00, 12.00, 16.00, 19.00, 22.00 "Бүген".
8.15 "АГЕНТ НАЦИОНАЛЬНОЙ БЕЗОПАСНОСТИ".
9.10 "ЗАКОН ДЖУНГЛЕЙ. ТРАНЗИТ".
9.55 "МИГО - ИНОПЛАНЕТЯНИН".
10.15 Криминал. "Чын күңелдән аңлату".
10.45 "Түгәрәк дата".
11.15 "Рецептсыз".
11.45 "Фитиль".
12.25 "Зур акчалар".
12.55 "НА СЕМИ ВЕТРАХ".
14.45 Э.Успенский программасы: "Безнең гаваньга корабльләр керделәр".
16.25 "ЛЮБОВНЫЕ ИСТОРИИ, КОТОРЫЕ ПОТРЯСЛИ МИР".
16.55 "ОНА НАПИСАЛА УБИЙСТВО".
17.50 Дог-шоу: "Мин һәм минем этем".
18.25 К.Набутов программасы: "Бер көн".
19.45 "Һөнәрем - репортер".
20.05 Телеуен: "О, счастливчик!"
20.50 "УЛИЦЫ РАЗБИТЫХ ФОНАРЕЙ - II". "НОВОЕ СЛОВО В ЖИВОПИСИ".
22.45 "ДЖЕЙМС БОНД-АГЕНТ 007".
00.50 Ток-шоу: "Шул хакта".

Якшәмбе

13 ФЕВРАЛЬ

"ТАТАРСТАН"

8.00-9.00 "Таң җилләре аша...".
16.00 "Милли хәзинәләрдән". Илһам Шакировка - 65 яшь.
17.45 Мультфильм.
18.00 Ф.Шаляпин исемендәге XIX Халыкара опера фестиваленең Гала-концерты.
20.30 "ТОН".
21.00 "Автокалейдоскоп".
21.20 "ТРТ музыкасы".
21.30 "Видеоспорт".
21.40 "Ханым".
22.10 "Зур концерт залы чакыра".

"ЭФИР"

6.00, 0.55, 3.45 "ТВ музыкасы".
6.45 "Адымнар".
7.15 "Шәһәр". Информацион программа.
8.05, 10.25, 13.00, 18.20 "Музыкага чикләр юк".
8.15, 0.35 "Юл патруле".
8.35 Мультфильм.
9.20 Мультфильм.
9.45 "Ле-Go-Go".
10.45 "Исәнмесез!"
11.45 "Автомобильдән саклан!"
12.00 "Поза".
12.35 Мультфильм.
13.15 "ВОЛЧЬЯ ЯМА".
15.55 "Сез шаһит".
16.45 "ОСП-студия".
17.45 "Атна һәлакәтләре".
18.30 "Тамаша залы".
19.00 "Fam TV".
19.30, 22.00, 3.15 "Республика". Информацион-аналитик программа.
20.05 "К-2 - ГОРА УБИЙЦА".
22.55 "СОБАЧИЙ ПАРК".
0.55, 3.45 "ТВ музыкасы".
3.00 Мультфильм.

1 НЧЕ КАНАЛ

8.00, 10.00, 15.00, 18.00 Яңалыклар.
8.10 "Русиягә хезмәт итәм!"
8.40 "Дисней клуб".
9.10 "Таң йолдызы".
10.10 Дм. Крыловның "Мәгънәсез язмалар"ы.
10.30 "Бар да әйдә чакта".
11.00 "АЛЬФ".
11.30 "Сәламәтлек".
12.00 "ДАЧА".
14.00 "Сәяхәтчеләр клубы".
14.40 "Бер җәүһәр тарихы". "Урыс музее".
15.10 "ГОРЕЦ".
16.00 "Акыллылар".
16.25 "Дисней клуб": "101 долматинец".
16.50 "Дисней клуб": "Новые приключения Винни-Пуха".
17.15 "Бу ничек булды". "Хоккей суперсериясе СССР - Канада". 1972 ел.
17.55 "Хатын-кыз тарихлары" программасы.
18.25 "Көлкеле манзара".
19.00 "Невзоров". Телевизион программа.
20.00 "КВН - 2000".
22.05 П.Шеремет белән информацион программа.
23.05 "ДРАКУЛА БРЭМА СТОКЕРА".

"РУСИЯ"

8.00 "Ватаныма хезмәт итәм!"
8.25 "Әти, әни һәм мин - спортны яратабыз".
9.20 "Сабый теле белән".
9.55 "Хәерле иртә, илем!"
10.30 "Аншлаг" һәм Ко".
11.30 "Ретро-шәһәрчек".
12.00 Урыс лотосы.
12.40 Мультфильм.
13.00 Хәбәрләр.
13.20 "Парламент сәгате".
14.05 "Иске фатир". 90 нчы еллар.
15.05 "Хайваннар турында әңгәмәләр".
16.05 "ЗАКОН И ПОРЯДОК".
17.00 Д/ф: "Свет его звезды".
18.00 "Көзге каршында".
18.20 "ЖЕНИХ ИЗ МАЙАМИ".
20.00 "Көзге".
21.00 "СОЛОМОН".
22.40 ГУБОПның 11 еллыгына багышланган бәйрәм концерты.
0.00 "УЖИН В ЧЕТЫРЕ РУКИ".

"КУЛЬТУРА"

10.05 "Библияне укыганда". Новый Завет.
10.15 "Аистенок".
10.40 "ПРИКЛЮЧЕНИЯ ИОАННЫ".
12.05 "Консилиум".
12.30 "Крылов мәсьәләрен уйныйбыз".
13.05 Мультфильм.
13.30 "Тормыш музыкасы". И.Архипова.
14.00 М.Пиотровскийның авторлык программасы: "Минем эрмитаж".
14.30, 22.00 Мәдәният яңалыклары.
14.45 "КАРТОННАЯ СВАДЬБА".
15.35 В.Божовичның авторлык программасы.
16.05 "Ватан һәм язмышлар".
16.30 "Әйберләр торышы".
17.00 "ГЕРОИ И ПРЕДАТЕЛИ".
22.20 "ДЯДЮШКИН СОН".
23.45 "Джаз концерты".

"НТВ"

8.00, 10.00, 12.00, 16.00 "Бүген".
8.15 "ЕЕ ЗВАЛИ НИКИТА".
9.20 "УЛИЦЫ РАЗБИТЫХ ФОНАРЕЙ-II". "НОВОЕ СЛОВО В ЖИВОПИСИ".
9.15 Телеуен: "О, счастливчик!"
10.15 "Коткару хезмәте".
10.40 "Мине аңла".
11.15 "Натуралистлар сәяхәте".
11.45 "Фитиль".
12.25 "Полундра".
12.55 О.Пушкинаның "Хатын-кыз карашы".
13.25 Телеуен: "Байяр фортлы ачкычлары".
15.00 "Криминаль Русия".
15.30 "Һөнәрем - репортер".
16.35 "Зур ата-аналар".
17.05 Документаль сериал: "Холодная война".
17.55 "ОНА НАПИСАЛА УБИЙСТВО".
19.00 "Йомгаклар".
20.35 "Курчаклар".
20.50 "УЛИЦЫ РАЗБИТЫХ ФОНАРЕЙ-II". "КОРОЛЕВА КРАСОТЫ".
21.50 В.Шендерович белән "Җәмгысе".
22.10 "ПОЛИЦЕЙСКАЯ АКАДЕМИЯ".
23.50 С.Шустер программасы: "Өченче тайм".
0.40 "ИЗВНЕ".

һәр көнне 21 сәгатьтән 22 гә, шимбә һәм ял көннәрендә 19.00 дән 20.00 гә кадәр "Азатлык" радиосы сөйли.

ДҮШӘМБЕ, 7 ФЕВРАЛЬ

6.00 "Татарстан авазы" информацион-нәфис каналы.
6.50, 7.58, 13.57 Һава торышы.
6.55, 7.50 Белдерүләр, реклама.
7.00-9.00 "Яңа көн". Вакыйгалар панорамасы.
19.10 Яңалыклар.
19.35 "Нинди матур минем туган җирем". Һәвәскәр башкаручыларның республика радиофестивале. Баулы районы. II тур.
20.20 "Үзеңнеке үзәктә".
20.35-20.55 "Язучылар балаларга".

СИШӘМБЕ, 8 ФЕВРАЛЬ

6.00, 7.00, 12.00, 19.10 Яңалыклар.
6.15 Б.Балтанов концерты.
6.53, 7.58, 12.57, 20.58 Һава торышы.
6.55, 7.50 Белдерүләр, реклама.
7.00-9.00 "Яңа көн". Вакыйгалар манзарасы.
12.00 "Татарстан авазы" информацион-нәфис каналы.
13.00 "Депутат каналы".
13.40-14.00 "Уйныйбыз да, җырлыйбыз да..."
19.35 Композитор Р.Билалов әсәрләреннән концерт.
20.10-20.55 "Яшьләр вакыты".

ЧӘРШӘМБЕ, 9 ФЕВРАЛЬ

6.00, 7.00, 12.00, 19.10 Яңалыклар.
6.15 "Көйдән-көйгә".
6.53, 7.58, 12.57, 20.58 Һава торышы.
6.55, 7.50 Белдерүләр, реклама.
7.00-9.00 "Яңа көн". Вакыйгалар манзарасы.
12.00 "Татарстан авазы" информацион-нәфис каналы.
13.00 Башкортстан артистлары концерты.
13.35 "Мәктәптән соң кич утырулар".
19.35 "Бүләккә - җыр".
20.35-20.55 "Өмет". Яшүсмерләр өчен.

ПӘНҖЕШӘМБЕ, 10 ФЕВРАЛЬ

6.00, 7.00, 12.00, 19.10 Яңалыклар.
6.15 "Бәянелхак". Публицистик тапшыру.
6.53, 7.58, 12.57, 20.58 Һава торышы.
6.55, 7.50 Белдерүләр, реклама.
7.00-9.00 "Яңа көн". Вакыйгалар манзарасы.
12.00-13.00 "Татарстан авазы" информацион нәфис каналы.
19.35 "Музыкаль очрашулар".
20.10 "Әйтер сүз". Икътисад темаларына.
20.25 "Җиде ачкыч" (чуаш телендә).

ҖОМГА, 11 ФЕВРАЛЬ

6.00-8.00 "Яңа көн". Вакыйгалар панорамасы.
7.00, 12.00, 19.10 Яңалыклар.
7.58, 8.55, 12.57, 20.58 Һава торышы.
8.10-8.50 "Агыла да болыт, агыла". Гыйбрәтле язмышлар.
12.00-13.00 "Татарстан авазы" информацион-нәфис каналы.
19.35 С.Йосыпов җырлый. Концерт-очерк.
20.10-20.55 "Яшьлек аланы".

ШИМБӘ, 12 ФЕВРАЛЬ

6.00, 7.00, 11.00, 18.00 Яңалыклар.
6.15 "Авыл офыклары".
6.58, 7.58, 12.57, 13.57 Һава торышы.
7.15 "Пар канатлар".
7.45, 13.50 Тапшырулар программасы.
7.50 Белдерүләр, реклама.
8.10 "Кыш илендә кунакта".
8.30 "Сезнең китап киштәгезгә".
9.00 "Театр афишасы каршында".
9.30-10.00 "Татулыкка ни җитә".
10.10-11.00 "Бөек Җиңүнең 55 еллыгына". Ә.Еники. "Бары бер генә сәгать". Радиопостановка.
11.20 "Әбүгалисина клубы".
12.00 "Татарстан авазы" информацион-нәфис каналы.
13.00-13.50 Татар халык көйләре.
18.15 "Бүләккә-җыр".

ЯКШӘМБЕ, 13 ФЕВРАЛЬ

6.00 "Иртәнге дулкында".
6.58, 12.57, 13.57 Һава торышы.
7.00 "Музыкаль редакция почтасыннан"
7.45, 13.50 Тапшырулар программасы.
7.50 Белдерүләр, реклама.
8.00-9.00 "Идел белән Урал арасында".
9.10-10.00 Т.Галиуллин. Хикәяләр.
10.10 "Үткәннәрнең сүнмәс яктысы".
10.40 "Көмеш кыңгырау".
11.00 "7 көн".
11.30 "Тел күрке - сүз".
12.00 "Татарстан авазы" информацион-нәфис каналы.
13.00-13.50 Ял концерты.
14.10-16.00 "Илһам". Язучы М.Мәһдиев юбилеена багышланган кичәдән язма.

Колагада төлке бар

Җинаятьчел төркем башында - хатын-кыз

Узган ел ахырында Чаллы милициясе үтерү, талау, көчләү кебек бик күп җинаятьләр эшләгән җинаятьчел төркемне кулга алды. Кулга алынганчы, шәһәрне шаулаткан канлы вакыйгалар булып, җәмәгатьчелек куркуга төште.

Яңа шәһәр районында 3 октябрьдә пычак белән кадап үтерелгән бер яшь ир-ат мәете табыла. Җинаять корбаны анадан-тума диярлек чишендерелгән була. Шул ук көнне Б.фамилияле хатын милиция бүлегенә мөрәҗәгать итә. Ул берничә билгесез ирнең үзен ят фатирга эчү мәҗлесенә чакырганнарын, чакырудан баш тартмавын әйтә. Шул фатирда ашап-эчкәннән соң Светлана исемле хатын, Б.ның бугазына пычак терәп, чишенергә кушкан, сумкасын, документларын алган һәм йодрыгы белән Б.ның башына суккан. Бу сугудан Б. егылган. Светлана дигәне Б.ны чәченнән сөйрәгән, башы белән берничә тапкыр идәнгә бәргән, ә аның әшнәсе Вадим Б.ны типкәләгән. Үзенең ничек урамга чыгуын Б. хәтерләми, үзен чишендергән, талаган, кыйнаган фатирны да, йортны да белми.

5 октябрьдә 15-16 сәгатьләрдә М. дигән кызны подъездда кыйнаганнар һәм көчләгәннәр. Көчләүчеләргә бер хатын булышкан: кызның сумкасын чистарткан һәм колагыннан алтын алкаларын йолкып алган.

6 октябрьдә үз фатирында пычак яраларыннан үлгән У.ның гәүдәсе табыла. Октябрь аенда Чаллыда менә шундый канлы вакыйгалар булып ала. Җинаятьләр буенча прокуратура суд эше кузгата, тикшерү өчен махсус оператив-тикшерү төркеме оештырыла, суд тикшерүе буенча план төзелә. Һәркөн иртән Чаллы прокуроры Йофар Шәйфетдинов бүлмәсендә була торган оператив киңәшмәдә бу җинаятьләр буенча тикшерү эшләренең барышы тыңлана.

Озакламый җеп очы табыла. Җинаятьчеләр кулыннан исән котылган ике кеше араларында берсе хатын-кыз булган өч җинаятьченең сурәтнамәсен язып калдыра. Хатынның Светлана исемле булуы да мәгълүм. Шаһитлар әйтүенчә, хатын-кыз җинаятьчеләрнең башында торган булырга тиеш, чөнки ул ике әшнәсенә гел күрсәтмә бирә икән. Төрмәдә утырып чыккан хатын-кызларның картотекасыннан ике "кандидат"ка тукталалар. Һәм шик, шундук Светланага төшә. Ул күптән түгел утырып чыккан. Кеше үтергән өчен аңа 4,5 ел биргән булганнар. Светлана И.ның фотосурәтен җинаять корбаннарына күрсәткәч, алар беравыздан җинаятьченең берсе нәкъ шул Светлана булуын әйтәләр.

Светлана И.ның торган урыны да билгеле була. 30 октябрьдә, агент күрсәткән адрес буенча барып, Светлана И.ны милиция хезмәткәрләре кулга ала. Аның белән бер үк вакытта диярлек "подельниклары" Вадим Ч., Игорь К. һәм Денис Ф.да тоткарлана. Арада иң өлкәне Игорь К. Аңа 25 яшь, ә калганнары 1-2 яшькә яшьрәк. Барысы да төрмә баландасын ашаган кешеләр, эшләргә дә, укырга да теләмиләр. Ләкин тәмле ашап, рәхәт яшиселәре килә. Ә болай яшәргә телисең икән, кара эшләр эшләми чара юк. Суд тикшерүе алар кылган бөтен җинаятьләрне ачты һәм җентекләп өйрәнде. Аларның беренчесе - Сергей исемле яшь егетне үтерү. 2 октябрь кичендә аны урамда бер чибәр генә хатын туктата һәм исерек хулиганнан яклавын үтенә. Сергей мәрхәмәтле егет була: хатынны култыклап, ул күрсәткән өйгә юнәлә. Алар каршына Вадим Ч. килеп баса һәм, пычак күрсәтеп, егеткә күн курткасын салырга куша. Сергей, аңа исе дә китмичә, хатынны култыклап баруын дәвам итә. Вадим Ч. егеткә арттан китереп суга. Сергей да җавапсыз калмый - йодрыгы белән В.ның чыраена китереп бәрә. Сугыш китә. Җирдә әүмәкләшеп сугышканда, Сергей Вадим Ч.ның пычагын ала һәм әлеге билгесез хатынның аяк астына ташлый. Ә Светлана (бу - нәкъ Светлана була да инде) нишли? Үзен якларга теләгән Сергейнең артыннан килеп, курткасын күтәрә һәм бил тирәсенә пычак кадый. Бер генә тапкыр түгел - 5 тапкыр! Сергей шундук үлә. Үле Сергей астыннан чыккан Вадим Светлананы мактый: молодец,янәсе, куртканы кисмәдең. Алар Сергейнең курткасын һәм аяк киемен салдырып алалар. Иртән Сергейның үле гәүдәсен урам себерүче табып, милициягә хәбәр итә.

Шул ук төнне, Сергейны чишендереп, күтәренеп кайтып килгәндә, Светлана белән Вадим урамда җилкәсенә сумка аскан, заманча киенгән ялгыз хатынны очраталар. Алар бу очраклы хатынны "мәҗлескә" - үзләренә чакыралар: "уңышны" юасылары килә. Хатын "аларның нинди уңыш"ны юарга теләүләре белән кызыксынып та тормый, әмма "мәҗлескә" бара. Иртән ул кыйналган, чишендерелгән хәлендә урамда исенә килә. "Халява"га эчү начар тәгәлләнә шул. Сыр тычкан тәбәсенә генә бушлай куела. Ләкин ул хатын суд тикшерүенә шактый ярдәм итә.

Светлананы Вадим Ч. һәм Игорь К. шәһәрдә йөрергә - "гулять итәргә" чакыралар. Светлана бик теләп риза була. Юлда бер кафега, бер ашханәгә керәләр, эчәләр һәм исерек килеш теләсә нинди әшәкелек эшләргә әзер булалар. Урамда 15-16 яшьлек бер кызны күреп, аның артыннан ияреләр, артыннан подъездга керәләр. Катлар арасындагы мәйданчыкта кызга бер-ике мәртәбә сугалар. Кызны куркытып, янап, котын алып, җирәнгеч ысуллар белән көчлиләр. Светланага да эш табыла, ул кызның сумкасын бушата, колагыннан алтын алкаларын йолкып ала.

Җинаятьчел төркем шул ук төнне танышлары Ирина У.фатирына килеп, "уңышларын" юа. Ирләр кәрт уйнарга утыра, хатыннар аш әзерли, кәефләре әйбәт. Өч көн эчендә 4 мәртәбә бик уңышлы "эшләделәр", табышка ия булдылар ич. Ашыйлар, эчәләр. Хуҗа хатын беренче булып исереп егыла, көч-хәл белән урынга барып ята. Ирләр бу хатынны үтерергә һәм фатирын таларга сүз куешалар. Һәм... эшкә керешәләр. Вадим йоклап яткан Иринага кухня пычагы белән китереп кадый. Караңгыда кая кадавын да шәйләми. Баксаң, пычак җилкә сөягенә эләккән икән - пычак шартлап сына. Авыртудан Ирина уянып, акырып җибәрә. Игорь аны кыйнарга тотына. Залда ут кабына. Светлана килеп керә. Ике ирнең бер хатынны үтерә алмауларын күреп, ул тизрәк ярдәмгә ашыга. Кухнядан пычак алып килә һәм хатынның йөрәгенә дүрт мәртәбә чәнчи. Хатын күзләрен ачып, куркыныч итеп Светланага карап ала да, сүнә.

Ирләр Светлананы мактыйлар. "Чиста эшләдең", янәсе. Әмма ул мактау сүзләрен колагына да элми (юкка гына төрмә шулпасын эчмәгән ич ул), нияте - күтәрә алган кадәр әйберне тизрәк җыештыру була.

Милициягә эләгер алдыннан гына Вадим белән Светлана арасында конфликт чыга: Вадим "мин кеше үтермәдем, миңа күп бирмәсләр, милициягә үзем барып әйтәм", дип ычкындыра. Светлана "бу мине эһ тә дими сатачак", дип уйлап ала. Һәм әшнәсенә яный башлый: "Кара аны, мин сине суярга да күп сорамам!.." - ди. Тегесе: "Мә, суй, сука!" - дип җикеренә. Светлана сумкасын ача, ләкин анда кнопкалы пычагы булмый. Пычак урынына ирен буявы тартып чыгара да: "Ярар, яшә, дурак, сине мочить итәргә вакыт бар әле!" - ди. Менә шундый низагтан соң алар милиция кулына эләгәләр.

Вадим изолятордан качып та карады, ләкин тиз тотылды. Хәзер ул Русия Җинаятьләр Кодексының 9 нчы маддәсе буенча гаепләнә. Шушы көннәрдә Светланага да, аңа да гаепләү акты игълан ителәчәк.

Миңнеәхмәт СИБГАТУЛЛИН,
Равил ХАҖИЕВ.



***КУЧКАР** (21.03-20.04). Гадәти хезмәт атнасы. Шимбә, якшәмбе көнне яңа проектларга керешә аласыз, уңарсыз. 8е көнне төзегән килешүләрегез яхшы нәтиҗәләр бирер. 9ы көнне спорт белән шөгыльләнегез, әмма бу көнне организмны чистартудан, ягъни ашамый торудан тыелыгыз, дүшәмбе көнне спиртлы эчемлекләр кулланмагыз.*

***ҮГЕЗБОЗАУ** (21.04-21:05). Сез уңышларга ия атнада яшисез. Гаиләгездә, эшегездә иминлек, керем булуы ихтимал. Кыска вакытлы сәфәргә чыгып, нәтиҗәле очрашулар үткәрерсез, дустанә мөнәсәбәтләр урнаштырырсыз, изге ниятләрегез гамәлгә ашар.*

***ИГЕЗӘКЛӘР** (22.05-22.07). Атна сезгә рәхимле. Илаһи серле көчләр канат җәя вә шәфкать кыла. Шул мөмкинлекне кулдан ычкындырмагыз. Рухи, физик гамәлләрегезне уйлап башкарыгыз, үзегезгә зарар килмәсен. Сишәмбе көнне төзегән килешүегез уңышлы булыр һәм бу көнне якын кешегез белән мәхәббәттә аңлашу шатлык китерер.*

***КЫСЛА** (22.06-22.07). 9, 10сын искә алмаганда, нигездә тыныч, эшчәнлек, иҗтиһат итү атнасы. Максатчан гамәлләрегез тормышка ашар, изге ният белән башланган эшләрегез яхшы нәтиҗә бирер, сөенеч кичерерсез, 9, 10ы көнне бәхәсләрдән сакланыгыз, сәламәтлегегез турында кайгыртыгыз.*

***АРЫСЛАН** ((23.07-23.08). Шактый сыный торган, борчулы атна. Юлда, транспортта, эш урынында куркынычсызлык кагыйдәләрен төгәл үтәгез, игътибарлы булыгыз. 7се көнне кампитрда башкарган эшләрегез канәгатьләнү бирер. Иң мөһиме - көндәлек вак-төяк мәшәкатьләргә игътибар итмәгез. Табигатькә чыгыгыз, ялгыз торуга өстенлек бирегез, ял итегез.*

***КЫЗ** (24.08-23.09). Нигездә, тыныч, сабырлыкка, тотрыклы эшчәнлеккә ия атна. Әмма шимбә, якшәмбе көнне якын, кадерле кешеләрегезгә бәйләнүдән, алар белән бәхәс, ызгыш-талаш куптарудан сакланыгыз. Алар сезнең таянычыгыз, ышанычыгыз, рәхимле була белегез.*

***ҮЛЧӘҮ** (24.09-23.10). 7, 8, 9, 10ы сезнең өчен уңай, уңышлы көннәр. Туганнарыгыз белән очрашырсыз, мул күчтәнәч алырсыз, керем булыр. 11, 12, 13е көнне сабырлык күрсәтегез, бәхәсләргә катнашмагыз. Сәламәтлек турында кайгыртырга туры килүе ихтимал.*

***ЧАЯН** 24.10-22.11). Атна сезгә рәхимле. Күңелле очрашулар булыр, дусларыгызның мактау сүзеннән канәгатьләнү алырсыз. Әмма дөньяда бар ялтыраган алтын түгеллеген онытмагыз, кылган гамәлләрегезнең кайсы яхшы, кайсы начар икәнен бәяләү хәерле булыр иде. Ялгызак тормышны тулыландыру, мәхәббәткә бирелү сезгә канәгатьләнү китерер.*

***УКЧЫ** (23.11-21.12). Сез югары уңышка ия, максатчан, эшлекле атнада яшисез. Изге гамәлләрегез яхшы нәтиҗә китерер, сөенеч кичерерсез. Шимбә, якшәмбе көннәрендә сезне данлау, хөрмәтләү көтелә.*

***КӘҖӘМӨГЕЗ** (22.12-20.01). Гадәти атна. Эштәге, өйдәге мәсьәләләр гади генә хәл ителә. Аның нигезен дуслык, ярдәмләшү тәшкил итә. Табигатькә чыгыгыз, рухыгыз күтәрелер, кышкы гүзәл мизгелләр хәтерегезгә уелып калыр.*

***СУКОЯР** (21.01-19.02). Бу сезнең атна. Аның кадерен белү кирәк. Гомумән, үзегезне дөньяга китергән айга карата рәхимле булыгыз. Сезне хөрмәтләү көтә, ихластан әйтелгән матур сүзләр җаныгызга тынычлык бирер, рухыгызны күтәрер.*

***БАЛЫК** (20.02-20.03). 7, 8, 9ы сезнең өчен уңайлы көннәр. Күңелле очрашулар шаһиты булырсыз, үзегезнең аш-су остасы сәләтен күрсәтерсез. Әмма сездән күп нәрсәдә сабырлык сорала, якын кешеләрегезне гафу итә белегез.*

Күргәзмә залларында

Казанга кар кешесе килде

В.ИСКӘНДӘРОВ фотолары.

Санкт-Петербургтан килгән кунакларыбыз безнең шәһәрдә инде бишенче тапкыр, һәм килгән саен алар безне яңа балавыз фигуралары белән гаҗәпләндерәләр. Былтыргы күргәзмә "Хөкемнәр һәм җәзалар" дигән темага багышланган булса, быелгысы "Мифлар һәм монстрлар, кино һәм әкият каһарманнары" дип атала. Бу образлар галереясы 32 фигурадан тора. Монда борынгы грек мифлары каһарманнары - Зевс, Кентавр, гүзәл Елена Циклоп; куркыныч, дәһшәтлешомлы Үлем, Дракула, Фреди Крюгер һәм бик күңелле, кызык Карабас-Барабас, 7 гном белән Белоснежка, Карлсон; фантастик чит галәм затлары, Кар кешесе дә бар. Һәрберсенең үз холкы-фигыле, үзенчәлекле тән төзелеше, күз карашы... Кыскасы, чын сәнгать әсәре!

Бер фигура 1-3 ел буе эшләнә икән. Аның күзгә күренә торган җирләре Швейцариядән кайтарылган махсус ак балавыздан, ә бүтән өлешләре гипстан һәм пластиктан ясала. Күзләре - С.Федоров клиникасыннан. Чәчләре дә чын. Алар берәмтекләп кайнар балавыз эченә кертелә. Кайбер фигуралар хәтта хәрәкәтләнә дә әле.

Ә ул фигураларны иҗат итәр өчен күп кешеләр көч куя: рәссам, скульптор, архитектор, гример, пастижер (чәч остасы), механик, тарихчы, сәнгать белгече һ.б.

Күргәзмәгә килгән тамашачыларга борынгы мифларның эчтәлеген дә кабат искә төшерәләр. Шуңа күрә бу күргәзмә укучылар, балалар өчен аеруча мавыктыргыч. Билет бәясе олылар өчен - 20 сум, укучылар, пенсионерларга - 10 сум. Күргәзмә "Волга" күргәзмә залында 1 ай эшләячәк, ә казанлылар яратса, бәлки, 2 ай да дәвам итәр.

Гүзәл КАМАЛ.

Колагада төлке бар

Бибик кулга алынды

Узган атнада Идел буе халык суды карары буенча Казанның иң нык яманаты чыккан җинаятьчеләреннән берсе - 36 яшьлек Альберт Батров (кушаматы Бибик) гадәти режимлы төрмәләрнең берсенә озатылды. Ул "Перваки" төркеме лидеры булып, август азагында кулга алынган иде. Оешкан җинаятьчел төркем лидерын яшерен фатирда, хатынын көтеп утырганда эләктерделәр. Ул соңгы вакытта Санкт-Петербургта яши иде. Шул ук төнне, шул ук подъездда Бибикның тән сакчысы да тотылды. Аның кесәсеннән ТТ пистолеты алынды.

Бибик законсыз рәвештә утлы корал саклауда гаепләнде. Аңа башка гаеп тага алмадылар. Шуңа күрә җәза да аз бирелде - Бибик нибары 3 ел 8 ай төрмәдә утырачак.

Ишек төбендә ... шартлау көтә

Узган атнада Казанның Яңа Савин районында "Надежда" төзелеш фирмасы директоры урынбасары, 47 яшьлек Н.Платонов чак кына үлмичә калды. Ул эшкә барырга чыкканда, ишеген ачуга граната шартлый. Җинаятьчеләр гранатаны аның фатир ишегенә түгел, ә подъезд ишегенә бәйләп киткәннәр, дигән фикер дә бар. Ул 1 нче катта яши икән, андагы ике янәшә фатир - аларныкы.

Н.Платоновны фатирыннан йөкле хатыны озата чыккан була. Бәхеткә, Платоновлар яраланган гына. Әлеге җинаять буенча суд эше кузгатылды.

"Фатима" сертотмас үрдәк түгел

Хатын-кызның күп очракларда үз гаиләсендә җәберләнүе беркем өчен дә сер түгел. Ирләр хатын-кызны җәберли, көчли, рәнҗетә. Ләкин мондый вакыйгалар нигезендә җинаять эше кузгату - мөмкин булмаган хәл диярлек. Һәрхәлдә, безнең республикада андый суд эшенең каралганы юк.

Менә шундый рәнҗетелгән хатын-кызларны яклау максатыннан, Казанда "Фатима" дип аталган кризис үзәге оешты. "Фатима" - ышанычлы телефон хезмәте ул. Шәһәр хакимиятенең балалар һәм яшьләр эшләре буенча комитеты каршында оешкан бу үзәктә гаиләдә рәнҗетелгәннәргә Казан психологлары төркеме ярдәмгә килә.

"Фатима" хезмәткәрләре, алга таба, башка Русия өлкәләрендәге һәм чит ил хатын-кызларының кризис үзәкләре үрнәгендә, рәнҗетелгән хатын-кызлар өчен вакытлыча яшәү йорты ачуны күздә тота. Ә хәзергә "Фатима" шундый хатын-кызларга психологик, юридик һәм башка төр (матди булмаган) ярдәм күрсәтүне үзенә бурыч итеп куя. "Фатима" үзәге хокук саклау органнары хезмәткәрләре, аеруча участок инспекторлары өчен махсус программа төзегән. Шунысы да мөһим: "Фатима" үзәгендә хатын-кызларның шәхси сере ачылмый. Телефон шалтыравына да хатын-кызлар гына җавап бирә.

Бу үзәккә, шимбә һәм якшәмбедән кала, һәр көнне 54-40-23 телефоны буенча 9 сәгатьтән 14 сәгатькәчә шалтыратырга мөмкин.

Хөрмәтле укучылар!

"Мәдәни җомга"га теге яки бу сәбәп аркасында язылырга өлгермәгән таныш-белешләрегезгә киңәш итсәгезче: әгәр 16 февральгә кадәр почта бүлегенә барып рәсмиләштерсәләр, аларга гәзитебез 1 марттан килә башлар.

Дүрт айга язылу бәясе - нибары 32 сум.

"Мәдәни җомга"ны АКШта, Австралия, Германия, Төркия, Финляндия, Чехиядә, БДБ илләрендә дә укыйлар, Мәскәүдә, Башкортстанда, Мари Иле, Мордовия, Удмуртия, Чувашия республикаларында, Ханты-Манси автономияле округында, Краснодар, Приморье крайларында, Әстерхан, Киров, Свердловски, Самара, Пермь, Чиләбе, Ульян, Ырынбур, Түбән Новгород, Пенза, Сарытау, Смоленски, Калининград, Курган, Кемерово, Новосибирски, Төмән, Томски, Иркутски, Камчатка өлкәләрендә һ.б. төбәкләрдә дә алдыралар.

Урам себерүченең вазифалары

Ай саен фатир өчен түләргә һәр гаиләгә счет-фактура китерәләр. Урам себерүче хезмәте анда шактый кыйммәт бәяләнә. Узган ел республика Министрлар Кабинетының 784 нче карары нигезендә урам чистартучының вазифалары билгеләнгән. Баксаң, урам себерүчеләрнең тормышы бик мәшәкатьле икән! Ә без аны бик җиңел хезмәткә санйбыз. Урам себерүче (дворник) тәүлегенә кимендә бер мәртәбә яуган кардан юл-сукмакларны, тротуарларны чистартырга тиеш. (Яуган кар 2 см булса да). Әгәр кар күбрәк яуса, ул 2-3 сәгать үткәч тә кар көрәргә чыгарга, тәүлегенә 1-2 мәртәбә үз территориясендәге юл-сукмакларга ком-хлорид катнашмасы сибәргә тиеш. Моннан тыш, урам себерүче урналарны чүптән бушатып юарга, үз территориясендәге юл һәм башка төр күрсәткечләрне сөртеп торырга бурычлы.

Мәдәни җомга

Татарстан Республикасы Матбугат, телерадиотапшырулар һәм массакүләм коммуникация чаралары, Мәдәният министрлыклары химаясендә чыгарыла

Баш мөхәррир Зиннур МАНСУРОВ

Баш мөхәррир урынбасарлары Газинур МОРАТ, Миншәех ЗӘБИРОВ

Шалтыратыгыз:

92-41-79 – кабул итү бүлмәсе;
92-45-78, 92-06-76 – баш мөхәррир урынбасарлары;
92-57-76 – җаваплы сәркәтип урынбасарлары;
92-58-91 – әдәбият бүлеге;
92-57-36 – публицистика, игъланнар бүлеге;
92-30-11 – сәнгать бүлеге; яңалыклар, мәгълүмат һәм дөнья хәлләре бүлеге;
92-12-08 – хатлар, социаль көнкүреш бүлеге;
92-57-76 – рәссам;
92-69-26 – фотохәбәрче;
92-57-94 – бухгалтерия;
2-15-85 – үз хәбәрчебез (Апас).

Авторлар фикере редакция фикере белән муафыйк булмаска да мөмкин

Хатлар, кульязмалар, фотографияләр, рәсемнәргә бәяләмә бирелми һәм алар кире кайтарылмый

© Гәзиттә басылган язмаларны, фотографияләрне файдаланганда, шулай ук өземтәләр китергәндә, "Мәдәни җомга"дан алынганлыгын күрсәтү мәҗбүри

Реклама урнаштыру өчен заказлар кабул ителә

Реклама һәм белдерүләрнең төгәллеге өчен реклама бирүчеләр үзләре җаваплы

Безгә иганәлек ярдәме күрсәтергә теләүчеләр өчен редакциянең исәп-хисап счеты:
ИНН 1654013120
Каз.филиал АКБ "Ак барс"
ОКПО 27860682
р/с. 40602810645020000429
к/с 30101810000000000889
БИК 049205889

Гәзит Татарстан Республикасы Мәгълүмат һәм матбугат министрлыгында 423 нче таныклык белән теркәлде

Индекс 54129

Безгә языгыз:
420503, Казан, Бауман урамы, 19

Нәшрият адресы:
420066, Казан, Декабристлар урамы, 2

Басмаханә гаебе белән җибәрелгән сыйфат җитешсезлекләре булса, 49-36-62 номерлы телефон буенча шалтыратырга

Гәзит редакциянең компьютер үзәгендә эшләнде

Гәзитнең сатудагы бәясе килешү буенча

Татарстан гәзит һәм журналлар нәшрияты басмаханәсе

Тираж 9.000
Заказ 2181